PRESSA.RU

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№4 (316) – АПРЕЛЬ 2018

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан
нәшер ителә

Айдан хәбәр бир!

Сугыш сере: корбаннар һәм исемлекләр

Роберт Әхмәтҗановның «йөрәк канатлары»

4 612750 670011

PRESSA.RU

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская, Олеся Бондаревская,
Руфия Фазылова
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Владимир Мамонтов, Ксения Сёмина,
Фаяз Хуҗин
Фотографлар: Александр Ефремов, Ната Смирнова,
Лилиана Вәлитова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин,
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: Сугыш ветераны Касыйм Козлов.
Александр Ефремов фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж: **3500** дана,
шул исәптән татар телендә – 1000.

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № Е-904

Басарга кул куелды: 23.04.18

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Коммерция директоры урынбасары:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ВАКЫТНЫ НИГӘ ТУКТАТЫРГА?

Фэнни Флэгг исемле Америка язучысы китабында яшәгән мәртәбәле бер гаилә шулай бервакыт, рәхәтләнеп, тәмләп әбәт ашаганнан соң, вакытны ничек, ә аннан да бигрәк, кайсы мизгелендә туктатырга икәнлеге турында уйлана башлый. Әниләре аны нәкъ әнә шул – барлык гаилә әгъзалары да җыелышкан мәлендә туктатырга тели. Әтиләре исә – барысы да сау-сәламәт булган, бер-берсенә каршы көрәш ачмаган мизгелне сайлый. Яңа гына мәктәпне тәмамлаган кызлары вакытны узган елда, ул әле яшьрәк булган чакта, туктатуны кулай күрә… Бары әбиләре генә, барысын да дикъкать белән тыңлап чыкканнан соң, балалары белән оныкларына үз зирәклеге югарылыгыннан елмая: «Ә мин аны туктатырга кирәк дип тапмыйм, – ди ул. – Ничек тиеш, шулай ага бирсен».

Китап геройларының уйлары аларның башларына язучы тарафыннан урнаштырыла, онытмыйк. Нәкъ менә язучы ул сүзләрне әйттерә дә. Әнә шулай, киләсе буынга алдагы буынның серләрен җиткерә алу осталыгына ия булганга, каләм әһелләре уйлап чыгарган геройлар үлемсезгә әверелә дә инде. Чөнки серләр кабатланып тора, кешеләрнең хисләре кайсы чорда да хисләр булып кала бирә, ә китаплар аша белгәннәребезгә таянып, без ул хис-серләрне танырга өйрәнә алабыз. Бары тик һәр мизгелне хәтергә сеңдерергә генә кирәк: андый очракта теләсә кайсы вакытта китап киштәсеннән яраткан китабыңны алып, тиешле урынын табып укып, өр-яңадан кадерле мизгелләргә күмелергә була. Дулкынландыргыч та, соклангыч та, газиз дә, сөекле дә… – бу мизгелләрне бездән берәү дә тартып ала алмый. Китаплар аша без вакытның кайсы мәленә әләгергә теләсәк, шунда әләгә алабыз. Аны туктатып торуның хаҗәте дә калмый хәтта!

ЯРАТЫП,
СЕЗНЕҢ РЕДАКЦИЯГЕЗ.

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«Татмедиа» АҖ
Нәшер итүче:
«Татмедиа» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **900 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7076** – татар телендә
Индекс **П7077** – рус телендә

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ

Айрат Гайфуллин, «Яз килде».



АПРЕЛЬ

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

4. Айга ничек җитәргә. Айга төшүнең төгәллеген Казан галимнәре исәпли.

8. Галәм киңлеге серләре. Бер галактикадан икенчесенә ничек күчәргә.

12. Дәүләт хезмәткәреннән ничек супермен ясарга. Идеаль чиновник әзерләү кагыйдәләре.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

16. Робот биюләре. Кешегә охшаган машиналарны ничек төзергә.

20. Камыр ризыклары. Ачасыр кабартма пешерү серләрен ача.

24. Җиңү фәне. Татарстан волейболисткалары ничек дөнья дәрәҗәсендәге топ-клубка әверелде.

28. Тауларны кем күчерә… Чикле мөмкинлекләрне чиксез итү юллары.

32. Имин тормыш нигезләре. Балаларны ничек сакларга.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

36. Бөек Ватан сугышы музее. Сугыш сере: корбаннар һәм исемлекләр.

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: www.protatarstan.ru

40. Ветераннарыбыз. Утны кичкән «Әлмәндәр карт».

44. Самолёт-легенда. Төнге бомбардировщикны ничек коткарырга.

48. Кече ватан патриотлары. Роберт Әхмәтҗановны ни өчен «альбатрос» дип йөрткәннәр.

54. Татар тарихы. Алмыш хан һәм Ибне Фадлан.

58. ТАССРның 100 еллыгына. Татарлар – дәүләт төзү юлында.

62. Китап киштәсе. Кешеләрне кешегә илтүче юллар.

84. Татар авыллары. Чүти кемнәре белән данлыклы.

PRESSA.RU

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

26.03

Илсур Метшин, Казан мэры, – эшлекле дүшәмбедә, ТР башкаласының Ли Куан Ю дәрәҗәле премиясенә үткәрелгән конкурста катнашу нәтиҗәсен бәяләп:

– Зур шәһәрне агымдагы мәсьәләләр белән генә яшәгән хәлдә үстерү мөмкин түгел, һәрвакыт үзеңдә тирә-якны күзәтеп тору, дөнья хәлләреннән хәбәрдар булу өчен көч һәм энергия табарга кирәк. Шулай ук – ышаныч белән киләчәккә карарга, хыялланырга һәм күп эшләргә. Без моны үзебезнең халык, Казан кешеләре белән бергәләп эшлибез, моның өчен мин аларга рәхмәтле.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

05.04

Зиннәтулла Билалетдинов, «Ак Барс»ның баш тренеры, – команда Гагарин Кубогында финалга чыгу белән:

– Без тырышачакбыз һәм Гагарин Кубогын кире кайтару өчен барысын да эшләячәкбез.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

12.03

Чулпан Хаматова, актриса, «Тормыш бүләк ит» хәйрия фондын гамәлгә куючыларның берсе, – Камал театрында чыгыш ясаганда:

– «Тормыш бүләк ит» дип аталган бу искиткеч хәрәкәткә катнашу бәхетенә ия булган күп еллар дәвамында без бихисап балага, гаиләләргә ярдәм иттек. Бу эшне башкаручы сезнең каршыгызда басып торган мин генә түгел, әлбәттә. Фонд ул – йөз меңнәрчә битараф булмаган кешеләр дигән сүз, алар бу дөньяда нәрсәнедер үзгәртеп булуын аңлыйлар… Бу илдә – үзгәртеп булуын.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Айга **НИЧЕК** төшәргә

«Сукыр тычкан юлы» **КАЯ** илтә

Дәүләт хезмәткәреннән **НИЧЕК** супермен ясарга

Планетаара автоматик «Луна-Глоб» («Луна-25») станциясе.
Иллюстрация: С.А. Лавочкин ис. ФЖБ

АЙДАН ХӘБӘР БИР!

Җирдән Айга таба дөньяда беренче космик аппарат җибәрелүгә тиздән алтмыш ел була. Бу – «Луна-1» совет планетаара станциясе. Әлеге юбилейны россиялеләр Айга яңа миссия әзерләп каршылаячак. Бу масштаблы проектта Казан галимнәренең дә роле шактый зур.

Автор:
Ольга Туманская

СЕЛЕНАГА ТӨШҮ

«Луна-25» станциясе – Россиянең яңа меңьеллыкта Айга беренче миссиясе һәм, зурдан кубып әйткәндә, СССР 1976 елда ук туктаткан Ай программасының дәвамы. Асылда, «Луна-25» – разведка, күзәтү. Аппарат Айның ландшафтын һәм өслеген өйрәнергә тиеш булачак. Киләчәктә аңа берничә кешелек экипаж һәм фәнни-тикшеренү җиһазлары төялгән кораб җибәрелер, дип фаразлана. Җир иярченендә кеше яши торган база төзеләчәк.

«Луна-25» станциясен 2020 елда эшләтеп җибәрү планлаштырыла. Әлеге космик миссиянең төп бурычларыннан берсе – Айга төгәл төшеп утыруны тәэмин итү. Аны камилләштерү юнәлешендә шул исәптән КФУ галимнәре дә эшли.

– Ихтимал, кемгәдер бу бик гади тоеладыр – янәсе, кирәк урынга төштең дә утырдың. Чынлыкта исә Айда кирәкле урынга барып төшү – бик катлаулы процесс, – дип сөйли КФУ профессоры, «Астровызов» САБ (Стратегик академик берәмлек) Космик навигация һәм планеталарны өйрәнү фәнни-техник лабораториясе җитәкчесе, В.Энгельгардт исемендәге астрономик обсерватория директоры Юрий Нефедьев. – 2016 елда без совет аппаратының Айга төгәл төшеп утыруының 50 еллыгын билгеләп үттек. Ул чакта Королевтагы идарә ителәторган космонавтикага багышланган конференциядә мин Айга җибәрелгән миссияләрнең навигация белән тәэмин ителешенә багышланган доклад ясадым. Белгечләрнең берсе миннән: «Менә сез әле бүген дә Айга төгәл төшеп утыру шактый кыен, дисез, ә ул чакта америкалылар ничек төшкән соң?!» – дип сорады. «Кул идарәсе режимында билгеле, тиешле руль һәм рычаглар ярдәмендә!» – дип җавап бирдем. Совет станциясен исә 15 секундка соңарып утырталар: сигнал башта Җиргә җибәрелә, ә аннан инде төшүгә кагылышлы боерыклар бирелә. Процесс белән идарә итүче белгечләр нәрсә эшләргә кирәклеген кимендә 30 секундка алданрак әйтергә тиеш була. Һәм моның нәтиҗәдә гамәлгә ашырылуы халкыбызның зур җиңүенә әйләнә, чөнки Җир иярчененә совет «Луноход»ларын җибәрү бурычы катлаулылыгы ягыннан идарә ителә торган очыштан бер дә калышмый!

Сүз уңаеннан, Айга төшүнең координаталарын төгәл билгеләүдә казанлылар мөһим нәтиҗәләргә ирешкән. Хәтта дөнья фәне масштабларында да. Эш шунда ки:

Җир иярчене үзенең авырлыгы үзәгенә карата катлаулы тибрәнүле хәрәкәтләр ясый. Астрономиядә әлеге күренеш физик либрация дип атала. Моннан тыш, белгечләр арсеналында әлегә кадәр төгәл селеноцентрик динамик каталог – гадирәк әйткәндә, космик аппаратның координаталарын ачыклау, һәм шулай ук аны вакытлыча эшләтеп тору максатына ирешерлек исәп-расчетлар юк. Барлык бу параметрларның төгәл исәбеннән башка автомат станцияне Айга төшерү бик кыен – мәсәлән, «Луна-15» космик аппараты Ай тауларына бәрелеп ватылган.

Казан университетында селенодезия һәм Айның физик либрациясе мәсьәләләре белән инде йөз елдан артык шөгыльләнәләр. Һәм бу тәҗрибәне үзләренең космик миссияләрендә төрле илләр уңышлы файдалана. Бәхеткә, бу мәсьәләдә Казан бүген дә алда бара. Соңгы тикшеренүләрнең берсе – КФУ магистранты Алексей Андреев хезмәте. Юрий Нефедьев җитәкчелегендә ул космик корабльнең Айга төшү төгәлсезлеген дистәләрчә тапкыр киметергә мөмкинлек бирә торган яңа ысул уйлап тапкан!

Фото Юрий Нефедьев архивыннан

Юрий Нефедьев «Луноход №3» янәшәсендә.

– Бүген космик аппаратның Айга төшүен исәпләү эллипсы 30 га 15 километрны тәшкил итә. Бу вакытта Ай координаталарының үзләренең төгәллеге өч километрга җитә! – дип сөйли Юрий Нефедьев. – Сез шундый төгәллек белән самолёт утыртканны күз алдына китерә аласызмы? Без аны берничә дистә метрга җиткерергә тырышабыз, һәм бу бурыч хәл ителә язды инде.

Бүген КФУ галимнәре тагын бер катлаулы проблеманы – инде Ай орбитасында космик аппаратның үзен Ай координаталары системасына ничек бәйләүне хәл итү өстендә эшли.

БЕРЕНЧЕ ЛАЗЕРЛЫ «СӘЛАМ»

Күп тә түгел, аз да түгел, Айдагы ун кратер Казан галимнәре хөрмәтенә аталган! Казанлыларның Ай астрономиясен үстерүгә керткән өлеше шул рәвешле йолдызлар югарылыгында мәңгеләштерелгән. Өстәвенә, әлеге кратерларның күбесенең уникаль үзенчәлекләре бар. Мәсәлән, Айның тискәре ягындагы Лобачевский кратерында серле баганалар күзәтелә. Аларның килеп чыгышы әлегә ачыкланмаган. Американың Айдагы LRO орбиталь зонды Энгельгардт кратерын Айдагы иң биек нокта дип тамгалаган. Яки, менә мәсәлән, танылган астроном Анатолий Нефедьев хөрмәтенә аталган Нефедьев кратеры Көньяк полюста урнашкан һәм, ихтимал, Россия корабльләренең төшү урынына әйләнәчәк. Ә бәлки нәкъ менә шул «Казан» кратерында кеше яши торган беренче база урнашыр? Бик мөмкин, дип саный моны Юрий Нефедьев.

– Көньяк полюста зур боз ятмалары бар, дип фаразлана, – ди ул. – Без исә сусыз яшәп булмавын яхшы беләбез, кешенең турыдан-туры катнашуын таләп иткән фәнни экспериментлар өчен дә су кирәк. Шуның да искәртеп китү зарур – Айга су ташу иң кыйммәтле процедура булып тора!

Якын киләчәктә Көньяк полюска беренче булып әлеге дә баягы «Луна–25» космик станциясе төшәчәк. Бу аппарат лазерлы маяк белән дә җиһазландырылачак һәм аның яктылыгын без хәтта Җирдән дә күрә алачакбыз, дип фаразлана. Әлбәттә инде, телескоптан. Әлеге маяк югары төгәллектәге навигация системасын төзүгә беренче адым булачак. Айда гына түгел, аның орбитасында да. Һәм бу бурычны хәл итүдә Җир иярченендәге координата-вакыт мәсьәләләре белән шөгыльләнүче Казан галимнәренең роле кабат шактый зур булачак. Чөнки конкрет координаталарга бәйләнмәгән маяк ул – файдасыз металл өеме генә, төгәл урыны билгеләнгән очракта исә башка барлык космик аппаратларның Айга



Фото: Роскосмос. МКС 32/33 экспедициясе фотоотчеты

Әгәр бүген Җир халкы Марсны үзебезнең планетабыз һәлак булган очракта «запас аэродром» итеп күзалласа, Ай кешелеккә үз туган Җирендә тыныч яшәү өчен кирәкле гамәли бирәмлек санала.



Фото Юрий Нефедьев архивыннан

Айның тискәре ягындагы атаклы математик Николай Лобачевский хөрмәтенә аталган кратерлар комплексы. Кратерларның берсендәге баганаларның табигате галимнәр өчен бүген дә сер булып кала.

төшүе ансатлашырга тиеш. Ихтимал, вакытлар үтү белән әлеге проект Айдагы лазерлы маякларның тулы бер системасына әйләнер, һәм аларның һәркайсының үзенең Ай координатасы булыр.

– Киләчәктә Ай тирәли орбитада Россиядәге ГЛОНАСС яки Америкадагы GPS кебек навигация төркемнәре булдыру планлаштырыла, – дип сөйли Юрий Нефедьев. – Маяклар орбитаның төгәл урынын билгеләү мөмкинлеген бирәчәк һәм, шуңа бәйле рәвештә, космик аппаратның яки Ай тирәли әйләнә торган станцияләрнең (хәзер Җир тирәли әйләнгән ХКС кебек) координаталары ачыкланачак. Тәүге лазерлы маякның үзенең техник бурычын ничек үтәвен күзәтү кызык булачак. Айда атмосфера юк, шунлыктан ул шактый ерактан күренәчәк. Әмма Ай орбитасында һичшиксез күренәчәк. Космик корабльгә тиешле почмак үлчәгеч җайланма урнаштырылса, космик аппарат орбитасының халәтен генә түгел, Айның үзенең динамик параметрларын да билгеләп булачак. Бик күп бурыч хәл ителәчәк!

ҖИР ХАЛКЫНА АЙ НИГӘ КИРӘК?

Моннан бер-ике ел элек кенә Халыкара аэрокосмик конференциядә SpaceX хосусый космик компаниясе башлыгы Илон Маск кешенең Марсны колонияләштерү планнары турында сөйләгән иде. SpaceX исәпләүләре буенча, Dragon2 корабле Марска бер-ике елдан очарга тиеш иде. Ике ел үтте, ә Марс миссиясе әлегә һаман хыял һәм фантазия булып кала бирә – Кызыл планетага очуның төп проблемалы сораулары хәзергә кадәр хәл ителмәгән. Тик ни өчен Россия «бары тик» Айны гына үзләштерергә җыена соң?

Бу – мәсьәләнең асылына дөрес караш. Бүгенге технологияләр әлегә Марс проектларын тормышка ашырырга мөмкинлек бирми. Ә менә Ай исә – гамәлгә ашырырлык хыял! Моннан тыш, уңышлы Ай миссияләреннән соң Марс проектларына да алынырга була. Марска корабльне Җирдән түгел, бәлки аның табигый иярчененнән җибәрү җиңелрәк һәм нәтиҗәлерәк бит! Инде кирәкле исәпләүләр дә бар.

Әгәр бүген Җир халкы Марсны үзебезнең планетабыз һәлак бул-



Ай маягының эшләү схемасы.
РФА Астрономия институтының айдәп баручы фәнни хезмәткәре Александр Багров мәкаләсенә иллюстрация.



Фото Юрий Нефедьев архивыннан

ган очракта «запас аэродром» итеп күзалласа, Ай кешелеккә үз туган Җирендә тыныч яшәү өчен кирәкле гамәли берәмлек санала. Әйтик, экспертлар фикере буенча, Айда гелий-3 кебек элемент табу планетабыздагы энергетика кризисын булдырмаска булышачак. Сүз уңаеннан, Айдагы казылмаларның составын да Казан галимнәре өйрәнә.

– Айны күптән өйрәнүебезгә карамастан, табышмаклар әле һаман бик күп, – ди профессор Нефедьев. – Гелий-3 – шулардан берсе. Ул энергетик яктан нефтьтән йөз тапкырга нәтиҗәлерәк, дип фаразлана. Җирнең иярченендә исә ул хисапсыз. Әмма гелий-3 – анда табылырга мөмкин булган бик күп файдалы казылмалардан берсе генә әле. Эш шунда ки: Айда атмосфера булмаганга, аңа гаять күп санда астероидлар һәм метеоритлар төшә. Аларда бакыр, тимер һәм башка файдалы кушылмалар булырга мөмкин. Мәскәүдәге коллегаларыбыз белән без бу проблеманы да өйрәнәбез.

Айдагы тикшеренүләрнең тагын бер гамәли аспекты – анда кеше яши торган, күп максатлы космик база урнаштыру. Һәм бу проект икътисадый яктан ХКСка караганда күпкә файдалырак булачак. Фәнни аспектларда да Ай миссиясе безнең өчен яңа перспективалар ача.

– Профессиональ астрономия һәм космик техника турында сөйләгәндә, без фәннең иң заманча горизонтларын күз алдында тотабыз, – дип әңгәмәбезне йомгаклый Юрий Нефедьев. – Ай миссиясе өчен безгә алдынгы фәнни тикшеренүләр кирәк булачак, ә кайчандыр космос өчен уйлап табылган күп нәрсә хәзер кире Җиргә әйләнеп кайтты, яңа технологияләр рәвешендә гади халыкның тормышын яхшыртуда файдаланыла башлады. Һәм бу иң еш бирелә торган: «Нәрсәгә ул космос безгә?» – дигән мәгънәсез сорауга җавап булып тора.

Танылган астроном Анатолий Нефедьев хөрмәтенә аталган кратер. Көньяк полюста урнашкан һәм, ихтимал, «Луна–25» космик аппаратының Айга төшү урынына әйләнер. Ә бәлки, нәкъ менә шунда кеше яши торган беренче база урнашыр.

PRESSA.RU

Фото: Paramount Pictures (Парамаунт Пикчерз)

«СУКЫР ТЫЧКАН» ЮЛЫ КАЯ ИЛТӘ?

Башка галәмнәргә тоннель яисә вакыт буенча сәяхәт… «Хыялый!», – диярсез сез. Юк шул менә. Фантастика, акрынлап, әмма хак юлдан чынлык дәрәҗәсенә күтәрелә, дөрес, әлегә гипотетик рәвештә генә. Боларның барысына да галимнәрнең хезмәте нәтиҗәсендә ирешелә, сүз уңаеннан, алар арасында казанлылар да бар.

Автор:
Ольга Туманская

Кешелек дөньясы үлем куркынычы алдында кала: Җирнең магнит кыры әкренләп көчен югалта, бәла-казалар нормага әверелә, уңышның юкка чыгуы гомуми ачлык белән яный… Бәхеткә, бу безнең чынбарлык түгел – күпләргә таныш «Интерстеллар» фантастик фильмында сюжетның төенләнеше. Картина абруйлы кинопремияләрне күпләп җыйды. Шәхсән минем өчен аның кыйммәте бүтәндә: фильмның нигезенә гомуми чагыштырмалылык теориясе өлкәсендә дөньякүләм эксперт – атаклы физик һәм астроном Кип Торнның фәнни күзаллаулары салынган. Нәкъ менә шул күзаллаулар аркасында фильм геройлары кешелекне коткару ысулына юлыгалар – бик ерак галактикага иң кыска юлны ачучы пространство тоннеле – Сатурн орбитасында табылган «червоточина – корт юлы» бар икән…

Сүз уңаеннан, «червоточина» – wormhole инглиз терминының сүзгә-сүз тәрҗемәсе, ләкин рус телле әдәбиятта әлеге күренешне аңлату өчен башка төшенчә кулланыла – «кротовая нора». (Без аны үзебезчә «сукыр тычкан юлы» дип тәрҗемә иттек – ред.) Беренче тапкыр әлеге «юл» турында әле Альберт Эйнштейн әйтә, ә инде узган гасыр ахырында бу тема янәдән галимнәр арасында шау-шу уятып җибәрә. Популяр интернет-энциклопедия бүлеген ачып карыйм һәм «Теория үсешенә өлеш керткән кешеләр» бүлегендә күренекле физик-теоретиклар Джон Арчибальд, Уилер һәм Кип Торн фамилияләре янәшәсендә өч ватандашыбыз фамилиясен күреп аптырам калам. Алар арасында Казаннан Сергей Сушков та бар икән.



Фото: earthmysterynews.com

»Сукыр тычкан юлы» – галәмнең иң ерак нокталарына кыска юл ачучы пространство тоннеле. Бүген ул инде фантастик романнарда гына түгел, математик тигезләмәләр рәвешендә дә яши.

ЕРАК, ӘММА ЯКЫН

80нче еллар ахырында фәнни җәмәгатьчелек арасында Кип Торн һәм аның коллегасы Майкл Моррис мәкаләсе чын шартлау уята. Мәкаләнең ярым фантастик булуыннан бигрәк, авторларының дөнья галимнәре алдына куйган сораулары резонанс тудыра. Күз алдына китерик: безнең цивилизация физика законнары кысаларында бөтен нәрсәне эшли алырлык үсеш дәрәҗәсенә иреште, дип яза алар. Һәм алга таба сорау куялар: мондый цивилизация «сукыр тычкан юлын» төзи аламы? Проблеманың болай куелышы «сукыр тычкан юлы» белән кызыксынуның кинәт артуына китерә – теоретиклар аны чишү ысулларын эзләргә керешәләр. Америка галимнәренең әлеге соравына Казан университетын



«Сукыр тычкан юлы». «Интерстеллар» фәнни-фантастик фильмы кадрларын кайбер галимнәр үзләренең кара чоңгылларны һәм «сукыр тычкан юлларын» өйрәну өлкәсендәге хезмәтләрен визуальләштерүнең шактый уңышлы үрнәге дип саныйлар.

тәмамлаган яшь физик Сергей Сушков та битараф калмый.

Бүген инде фән докторы, Физика институтының чагыштырмалылык һәм гравитация кафедрасы мөдире, «Космология» лабораториясенең фәнни хезмәткәре Сергей Сушков үзенең фикерен шактый коры формалаштыра. Ул – галим, һәм, мәсәлән, «параллель чынбарлык» кебек фантастлар өчен шундый якын сүзтезмәләр аңарда бары тик ирония генә уята.

«Ну, «сукыр тычкан юл» сезгә нәрсәгә кирәк инде ул?» – дип сорый ул миннән. Ләкин берничә минуттан ук яраткан фәнни стихиясенә бирелеп, үзенең эзләнүләренең предметы турында мавыктыргыч итеп сөйли башлый.

– Кыскача әйткәндә, «сукыр тычкан юлы» – гипотетик астрофизика объекты, – дип башлый ул сүзен. – Әлеге урыннарны популяр әдәбиятта пространство һәм вакыт тоннельләре яисә төрле ике галәмне бәйләүче күпер дип йөртәләр. «Сукыр тычкан» конфигурациясенең үзәге юк, аның урынына, авыз куышлыгы дип аталган өлеше бар. Аның аша үтеп, без башка галәмгә эләгәбез. Менә шундый кызыклы топологик объект!

...Сатурн боҗралары астыннан үткәндә «Эндюранс» планетаара корабле, ниһаять, «сукыр тычкан юлына» барып җитә. «Син бер ноктадан икенчесенә эләгергә телисең, дип фаразлыйк. Әмма ул бик ерак», – дип аңлата «Интерстеллар» геройларының берсе икенчесенә. Ул кәгазь бите ала һәм аның капмакаршы кырыенда бер-берсеннән еракта ике нокта ясый. Аннан соң кәгазьне ике нокта тоташырлык итеп бөкли һәм шул урынны тишә: «Сукыр тычкан юлы» пространствоны син башка үлчәнеш аша юлны кыскарта алырлык итеп кәкрәйтә». Кыска космик тоннельне үтеп, «Эндюранс» очучылары, чыннан да, бик ерак галәмгә барып җитәләр...

Шундый тоннельләрнең тәүге модельләренең берсен чагыштырмалылык теориясе атасы Альберт



Сергей Сушков, Физика институтының чагыштырмалылык һәм гравитация кафедрасы мөдире, «Космология» лабораториясенең фәнни хезмәткәре, «сукыр тычкан юлы» теориясен үстерүгә зур өлеш кертә.

Фото: Александр Ефремов

PRESSA.RU



«Интерстеллар» картинасында Гаргантюа кара чоңгылы – әле һаман да серле булып калган күренешнең табигате турында галимнәрнең күзаллауларын чагылдыруда иң уңышлы һәм реалистик омтылышларның берсе.

Эйнштейн тәкъдим итә. Бу хәл 1935 елда була. Коллегасы Натан Розен белән бергә тигезләмәләр ярдәмендә ул гипотетик «сукыр тычкан юлы»ның классик мисалын чыгара, аны Эйнштейн-Розен күпере дип атыйлар. Дөрес, бөек физиклар аны хәрәкәт итү чарасы буларак карамыйлар, чөнки гипотеза мәгънәсендә дә аларның тоннеле үтә алырлык булмый. Аның авыз куышлыгы гаять зур тизлек белән үзгәреп тора – әле киңәя, әле киресенчә шундый тарая, космик корабль түгел, хәтта яктылык нуры да аның аркылы үтәргә өлгерә алмый кала! Сергей Сушков безгә галимнәрнең үз-үзен бер халәттә тотып тора алган яисә тотрыклы – «Эндюранс» очып үткән «юл»га охшаган «сукыр тычкан юлы»ның теоретик моделен төзеп карау омтылышлары турында да сөйләде.

ГАЛӘМ ҮЗӘГЕНӘ КҮЗ САЛЫЙК

– «Сукыр тычкан юлы» булсын һәм тотрыклы галәм объекты саналсын өчен, шактый экзотик матдә таләп ителә, – дип сүзен дәвам итте Сергей Сушков. – Эш шунда: «юл» авызы гравитация йогынтысы астында гел ябылырга омтыла, ә бу матдә моны эшләргә ирек бирмәскә тиеш.

Әле күптән түгел генә фәнни даирәләрдә «сукыр тычкан юлы» турында сөйләшүләргә елмаеп кына карыйлар иде. Бу гади күзгә күренмәгән материя – караңгы матдәнең яисә тагын бер төрле атамасы буенча – караңгы энергиянең барлыгы ачылганчыга кадәр дәвам итте.

– Һичшиксез, караңгы энергия экзотик үзлекләргә ия, – ди Сушков. – Әйтик, безнең өчен гадәти саналган материядән аермалы буларак, тискәре энергиягә (чөнки тискәре массалы) ия булганы өчен генә булса да.

Галимнәр караңгы энергиянең, дөрес, бик сибелгән-чәчелгән рәвештә генә булса да, галәмнең 70 проценттан артыгын тутырып торуын ачыклаганнар. Физиклар әлегә аның нәрсәдән гыйбарәт булуын төгәл белми, әмма шунысы анык билгеле: локаль масштабларда караңгы энергия концентрациясе шулкадәр кечкенә ки, аны лаборатория шартларында табу-ачу мөмкин түгел һәм, димәк, аның белән әлегә эшләп булмый, дигән сүз. Бу матдәне бары тик планк масштабларында, ягъни бик кечкенә, квант дәрәҗәсендә генә карарга була, аның белән чагыштырганда микродөнья гигант булып күренергә мөмкин.

– Бүгенгә без «сукыр тычкан юлы» ябылмасын өчен әлеге экзотик шартларны менә шундый микроскопик дәрәҗәдә генә булдырырга мөмкин, дип саныйбыз. Һәм галимнәрнең бүген булмаса, иртәгә сәяхәт өчен шундый тоннель төзеячәкләренә дип исәп тоту – акылсызлык, – ди Сушков.

– Ә бәлки табигатьтә «сукыр тычкан юлы» инде бардыр, – дип үземнекен бирмәскә тырышам мин. – Бу очракта сез аларны кайдан эзләр идегез?

– Мөгаен, моның өчен иң кулай урын – галәмнең үзәгедер, – ди әңгәмәдәшем.

Эш шунда ки: бүгенге күзәтүләргә карагана, теләсә кайсы галәм үзәгендә һәрвакыт кара чоңгыл (черная дыра) була. Безнең «Киек Каз юлы» галактикасы да чыгарма түгел. Аның үзәгендә массасы 4 миллион кояш массасыннан да зуррак массалы кара чоңгыл бар, дип күзаллана. Әлеге күренешне телескоптан күзәтеп булмый, чөнки ул инде актив түгел һәм үз тирәсендәге бөтен нәрсәне суырып һәм тартып, җете квазар булып яктыртмый. Бик ихтимал, ул бөтенләй кара чоңгыл түгелдер, бәлки «сукыр тычкан юлы»дыр, әлеге ике объект үзлекләре буенча бер-берсенә охшаш бит, аерма шунда гына: кара чоңгылда энергиянең тыгызлыгы һәм гравитация көче чиксезлеккә китә бара. Әгәр инде аңа озак вакытлар дәвамында экзотик матдә төшеп торган һәм аның туплануы тартылуны киметкән, дип күзалдына китерсәк, нәрсә?

КЕШЕЛЕККӘ КУЕЛГАН ТАЛӘПЛӘР

АКШтагы Брукхейвен лабораториясе галимнәре гигант тизләткечтә – канаты дүрт километрга җиткән авыр ион релятив коллайдерында алтын атомнары белән аталар. Алар шуны тикшереп карый: яктылык тизлегеннән 99,9 процент



Фото: Европа көньяк обсерваториясе (ESO)

Безнең галактиканың әлеге сурәте ATLASSAL «Киек Каз юлын» җентекләп карау кысаларында APEX радиотелескобы ярдәмендә алынган. Бүгенге күзаллауларга караганда, һәр галактикада һичшиксез кара чоңгыл бар. «Киек Каз юлы» үзәгендә 4 миллион кояш массасыннан зуррак массалы кара чоңгыл бар, дип фаразлана, әмма ул актив түгел. Ә бәлки ул нәкъ менә «сукыр тычкан юлыдыр». Галимнәр моны инкарь итми.

тизлектә субатом кисәкчекләрен бәрелештереп, ясалма рәвештә үтә тыгыз материя – микроскопик кара чоңгыл төзеп буламы икән? Әлегә нәтиҗә тискәре, әмма галимнәр, зур шартлаудан соң безнең галәм белән чынлыкта нәрсә булуын яхшырак аңлау өчен, әлеге бәрелешүләрне өйрәнүне дәвам итәләр.

Әлегә дөньяның иң эре лабораторияләре мондый экспериментларны үткәрә тора, ул арада физик-теоретиклар микроскопик «сукыр тычкан юлын» төзүне хәл итүнең математик ысулын тәкъдим итә. Сергей Сушков инде күптән микроскопик «сукыр тычкан юлын» тотып тору чыганагы сыйфатында материянең, караңгы энергия белән чагыштырганда фундаментальрәк һәм, һичшиксез, реалистик формасы – квант кырларын тәкъдим иткән. Әлеге тема буенча галим бастырып чыгарган мәкалә фәнни даирәләрдә өземтә буларак кулланылышы ягыннан югары рейтингка ия.

– Әйе, галимнәр әлегә ясалма рәвештә «сукыр тычкан юлын» эшләп буламы дигән сорауга җавап тапмадылар, – ди Сушков. – Ләкин бүген тигезләмәләрне чишү рәвешендә реалистик «сукыр тычкан юлы»ның табылганлыгы – факт.

Аның белән коллегасы – Михаил Волков та килешә. КФУның «Космология» Фәнни-тикшеренү лабораториясенең өлкән фәнни хезмәткәре һәм Тура Университеты (Франция) профессоры шулай ук «сукыр тычкан юлы»ның математик структурасын өйрәнә һәм ерак булмаган киләчәктә галимнәргә әлеге күренешне ачу мөмкин булачак, дип фаразлый. Ләкин әлегә бары тик микродөньяда гына. Һәм бу «теоретик физиканың иң төп максатларының берсе – квант механикасын гомуми чагыштырмалылык теориясе белән «дуслаштыруга» ирешү юлында бер адым» булачак.

Күптән түгел генә ул Кембридж университеты профессоры Гэри Гиббонс белән бергә фәнни басмаларда берьюлы өч мәкалә чыгара. Ләкин әлеге галимнәр интерпретациясендә «сукыр тычкан юлы» тоннель буларак түгел, экзотик материядән торган бик нәзек һәм чиксез авыр боҗра буларак күзаллана. Әйтик, мәсәлән, диаметры ике метрлы гына шундый боҗраның массасы якынча Юпитер массасына тәңгәл килә, тик минус тамгасы белән. Галимнәр әлеге вариантны очраклы рәвештә генә түгел, бәлки гомуми чагыштырмалылык теориясенең тигезләмәләре системасын чишү барышында табалар.

Шулай да, әйдәгез, күз алдына китереп карыйк: без теләгәнебезгә ирешеп, «сукыр тычкан юлын» таба алдык, ди. Димәк, без хәзер галәмнең иң ерак нокталарына сәяхәткә чыгып китә алачакбыз!

– Сәяхәткә генә түгел, – дип әлеге фикерне үстерә Сергей Сушков. – «Сукыр тычкан юлын» табу котылгысыз рәвештә вакыт машинасының пәйда булуына китерәчәк!

Эш шунда ки: хәзерге гравитация физикасы нигезендә пространство һәм вакыт аерылгысыз дигән күзаллау ята. Шуңа күрә гипотетик «сукыр тычкан юлын» ясаганда, без ул дүрт үлчәнештә ятачак, дип сөйлибез: шуларның өчесе – пространство, дүртенчесе – вакыт. Һәм безнең дүрт үлчәнештәге пространство-вакыт – тайпылышта, ә гравитация – әлеге тайпылышның чагылышы инде ул. Һәм әгәр без пространствода кыска юл таба алабыз икән, бу, димәк, вакыт өчен дә шундый мөмкинлек барлыгын аңлата. «Сукыр тычкан юлы» тоннеле аша без йолдызара сәяхәтләргә чыгу гына түгел, вакыт буенча да күчеп йөри алачакбыз, булып чыга. Дөрес, ул чакта сәбәп-нәтиҗә бәйләнешендәге күпләгән сораулар туа. Үткәннәргә китәргә ярамый – анда үз туган көнеңә кадәр «эз» калдырмас өчен.

«Кешеләр – идиотлар… Кешелеккә галәмне гизәргә мөмкинлек бирелгән, ләкин аның кулланучылык белән генә шөгыльләнәсе – сыра эчәсе, сериаллар карыйсы килә», – ди үзенең соңгы интервьюларының берсендә Рэй Брэдбери. Шулай да шәхсән мин үзем инде барысын да югалттык дип уйламыйм. Ә ул «галәм» менә биредә – без туган планетада төзелә – гади авторучка һәм кәгазь ярдәмендә. Физик-теоретиклар гадәттә нәкъ менә шул рәвешле фантастларның иң кыю идеяләрен тормышка ашыралар да. ■

PRESSA.RU

ТҮРӘ БУЛЫРГА ТЕЛИСЕҢМЕ?
Ә ХӘЛЕҢНӘН КИЛӘЧӘКМЕ?

XXI гасырда Россиядә идеаль дәүләт хезмәткәре суперменга тиң: бурычларының күләме гаять зур, хакимият һәм халык аның үзенә якынрак булуын таләп итә, шәхси һәм эшлекле сыйфатларына торган саен җитдирәк таләпләр куела бара. Мондый шартларда әлеге сферага яшьләрне һәм яхшы әзерлекле белгечләрне ничек җәлеп итәргә һәм, иң мөһиме, булганнарын ни рәвешле саклап калырга?

Автор:
Ксения Сёмина

Бу сорауга җавап бик гади һәм рациональ: яшьләрне өйрәтүдә инде үз эшләренең осталарына әйләнгән профессионаллар тәҗрибәсен мөмкин кадәр күбрәк файдалану зарур. КФУ Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе (ДМИЮМ) белгечләренә бу яхшы мәгълүм, һәм шунлыктан мәктәп быел гамәлгә кертергә җыенган берничә белем бирү проектының нигезенә нәкъ менә осталык принцибы салынган.

МИНИСТРЛЫКТА КУНАКТА

Бөтен район тормышының шактый зур өлешен көйли торган документларның хокукый төгәллеге муниципалитет юристына бәйле. Беренчедән, мондый белгеч квалификацияле булырга, икенчедән, ниндидер сорау яки проблема килеп туган очракта киңәш сорап республика идарәсендәге кайсы белгечкә һәм ничек мөрәҗәгать итәсен белергә тиеш. Боларны истә тотып, ДМИЮМ һәм Татарстан Юстиция министрлыгы белгечләре күптән түгел эшкә алынган район юридик хезмәткәрләре өчен ике көнлек стажировка әзерләде һәм үткәрде. Әлеге чара март башында Татарстан Юстиция министрлыгы базасында уздырылды һәм республика министрлык һәм ведомстволарындагы туры-дан-туры стажировкалар программасында беренче тәҗрибә булды. Татарстанның берничә районы юридик бүлеге вәкилләре министрлык эшчәнлеге белән таныштылар, актуаль кейсларга «кереп чумды» һәм остазлары белән проблемалы темаларны тикшерде.

– Министрлык хезмәткәрләре белән танышу, әңгәмә кору бик файдалы булды – кайвакыт сорау туа да, кемгә бирергә, моны ничек дөрес эшләргә икәнен белми аптырыйсың. Хаталана-хаталана, хәл итү юлларын үзеңә эзләп табарга туры килә. Мондый очракларда нишләргә тиешлегемне стажировкада мин яхшырак аңлый башладым, – дип тәэсирләре белән уртаклашты Татарстанның Буа муниципаль районы Советы аппаратының юридик бүлеге белгече Дамирә Хәкимова. – Дәресләр эчтәлеге тыгыз булып, без бик күп яңа мәгълүмат алсак та, бу чара мине илһамландырды.

Март азагында муниципаль хезмәткәрләр өчен шундый ук ике көнлек стажировканы Татарстан Финанс министрлыгында үткәрделәр.

– Программаның гамәли булуы бик куандырды. Мәсәлән, без бюджет формалаштырганда икътисадый фаразлау күрсәткечләренең нинди роль уйнавын җентекләп тикшердек. Безнең бүлек нәкъ менә шундый күрсәткечләрне җыю һәм әзерләү белән шөгыльләнә, дәрес материаллары буенча мин эшемдә кирәк булачак шактый нәрсәгә төшендем. Моннан тыш, стажировка вакытында алынган мәгълүмат миңа финанс-бюджет палатасы белән үзара хезмәттәшлегебезне тагын да нәтиҗәлерәк итәргә булышты, – дип сөйли Татарстанның Питрәч районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Альберт Хәбибуллин. – Министрлык белгечләренә стажировка оештырулары өчен мин бик рәхмәтлемен. Алар үзләренең гаять тыгыз графикларында безнең өчен вакыт таба алды, дәресләр үткәрде һәм күп кенә сорауларыбызга җавап бирде. Моны эленке-салынкы гына түгел, ихластан һәм бик тырышып эшләделәр, шуның өчен аларга аерым рәхмәт. Һичшиксез, мондый стажировкалар бик файдалы, бигрәк тә дәүләт хезмәтенә яңа гына керешкәннәр өчен.

ИДАРӘЧЕ РЕПЕТИЦИЯСЕ

Үзенең профессиональ язмышын дәүләт хезмәте һәм сәясәт белән бәйләргә генә җыенучылар Дәүләт идарәсе кече академиясенә (ДИКА-МАГУ) укырга керә ала. Идел буе федераль округының берничә субъектында гамәлдә булган әлеге белем бирү проектының инициаторы – Россия Президентының Идел буе федераль округындагы тулы вәкаләтле вәкиле Михаил Бабич. Татарстанда ДИКА проектын Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе тормышка ашыра. Академиягә ике елга бер тапкыр җыялар. Программаларда укытуның заманча форматлары – стажировкалар, тренинглар, шулай ук дәүләт идарәсе һәм сәясәт сферасындагы профессионаллар һәм танылган

Фотолар КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбеннән алынды

Реклама 16+

Владимир Путин, РФ Президенты:
«Остазлык хәрәкәтен үстерүне әһәмиятле бурычка саныйм. Бары тик шулай, алдынгы белемне һәм әхлак нигезләрен берләштереп, буыннарның чын хезмәттәшлеген һәм үзара аңлашуын тәэмин итеп кенә, без көчле була алабыз».

(2018 елгы Федераль Җыенга Юлламасыннан)

Рөстәм Миңнеханов, ТР Президенты:
«Һәр дәүләт яки муниципаль хезмәткәрнең үз база белгечлеге булырга тиеш. Бу вакытка кадәр аның билгеле бер юл үтүе, күнекмә һәм тәҗрибә туплавы бик мөһим».

(«Лидеры России» Бөтенроссия идарәчеләр конкурсы финалына үткән татарстанлылар белән очрашуда)

шәхесләр белән дискуссияләр оештыру кулланыла.

Март уртасында Академиянең тыңлаучылары һәм аны тәмамлаучылар РФ Дәүләт Думасы депутатлары Марат Бариев һәм Айрат Фәррахов, шулай ук РФ Федераль Җыены Федерация Советы әгъзасы Олег Морозов белән очрашты. Парламентарийлар сәясәтче булып җитлегүдә остазның роле зур булуы турында сөйләде. Олег Морозов үз вакытында аңа Минтимер Шәймиевнең сәяси харизмасының ничек көчле тәэсир итүен искә төшерде: «Ул бер караштан синең нинди кеше булуыңны чамалый. Мөмкинлекләре булып та, тәҗрибәсе җитенкерәмәгәннәргә һәрвакыт хәерхаһлы мөнәсәбәттә. Минтимер Шәрипович барлык карарларын да һәрчак бик уйлап кабул итә». Олег Морозов остазның һәрвакытта да үзеңнән өлкәнрәк булуы мәҗбүри түгел, дип саный. «Бүген минем өчен иң көчле үрнәкләрнең берсе – Рөстәм Миңнеханов. Аның эзлекле рәвештә алга омтылуы, һәрвакыт укырга, яңаны үзләштерергә әзер булуы таң калдыра. Ул – җитәкче, лидер, идарәченең искиткеч киң эрудицияле булырга, үзенең шәхес буларак үсешендә беркайчан да туктап калмаска тиешлегенә бик шәп мисал». Марат Бариев чыгышында вакытында үзләрен депутат ярдәмчесе сыйфатында сынап карарга теләүчеләр өчен стажировка оештыра алачагы турында сөйләде һәм мондый бурычларны үтәргә хәлемнән килә дип санаучылар белән әңгәмә үткәрергә вәгъдә бирде.

– Университетта укудан тыш, мин иҗтимагый-сәяси эшчәнлек белән шөгыльләнәм, «Молодая гвардия» активисты булып торам һәм «Политзавод» республика иҗтимагый-сәяси проектында катнашам. ДИКАга үземнең һөнәри мөмкинлекләремне һәм сәясәт сферасындагы белемемне арттырырга дип кердем. Биредә без төп белгечлек буенча укуыбызга зыян китермичә белем алабыз. Шартлары бик уңайлы, программасы – кызыклы. Дәресләр без дәүләт, муниципаль идарә һәм тулаем сәяси система турында күзаллау алырлык итеп төзелгән, – дип сөйли КФУ Психология һәм мәгариф институтының бишенче курс студенты Алсу Бикмөхәммәтова. – ДИКАда уку үземне сәясәттә сынап карау теләген тагын да ныгытты. Хәзер мин кем буласымны һәм моның өчен нишләргә кирәклекне төгәл беләм. Бу җәһәттән парламентарийлар белән очрашу бик мөһим булды. Мондый чаралар сәяси сферадагы белем дәрәҗәсен күтәрергә, идарәче сыйфатларын үстерергә һәм җәмгыятькә файдалы кеше булып җитешергә илһамландыра!

– Бер яктан караганда, дәүләт хезмәте кадрлар кытлыгы кичерә. XXI гасыр компетенцияләренә ия, стресска чыдам, адекват, ныгытып эшләргә әзер белгечләр булырга тиеш. Икенче яктан караганда, бездә амбицияле, мондый карьера ясарга кызыгучы, әмма чиновник эшенең нидән гыйбарәт булуын бик үк яхшы күзалламаучы яшьләр дә күп, – ди КФУ ДМИЮМ директоры Игорь Привалов. – Безнең фикеребезчә, остазлык – тормыштан алынган мисаллар һәм гамәлдәге сәясәтчеләр, җитәкчеләрнең казанышлары тарихы үрнәгендә акыллы һәм өметле яшьләрне профессиональ, карьера үсеше ягына юнәлтү ысулы ул. Теоретик белемне алар үзләренә база белгечлеге бирә торган уку йортында ала. Академиядә исә гамәлдәге әйдәп баручы белгечләр җитәкчелегендә дәүләт хезмәте сферасын эчтән өйрәнә һәм киләчәктә дәүләт хезмәткәре булып китәргәме-юкмы дигән сорауга җавап эзли. Без программаны тыңлаучыларыбызны әлеге карарны аңлап кабул итәрлек дәрәҗәгә җиткерерлек рәвештә формалаштырабыз.

PRESSA.RU

Реклама 16+

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Плазма томанында **НИЧЕК** адашмаска

Иң тәмле кабартмаларны **КАЙДА** пешерәләр

Чикле мөмкинлекләрне **НИЧЕК** чиксез итәргә

Балаларны хәвефләрдән **НИЧЕК** сакларга

PRESSA.RU

ПРИНТЕРДА ЯСАЛГАН **КЕШЕ**

Казан федераль университетының Инженерлык институтына үтеп кереп, «Татарстан» журналистлары плазма томанында адашып йөрергә, роботның кулын кысарга, шулай ук кеше башын эчке яктан тикшереп карарга да өлгерде... Бер сүз белән генә әйткәндә, якын киләчәктә, бәлки, дөньяны үзгәртмәсәләр дә, тормышны җайлаштырачаклары күзгә күренеп торган технологияләр белән таныштылар.

Автор:
Ксения Сёмина

Үзегезне бик ерак булмаган киләчәктә дип күз алдына китерегез. Урамда төн, ә өегездә су краны ага башлады – тыгызлагыч бөҗрасы чатнаган, имеш. Сез бер дә куркуга төшмисез, сантехникка шылтыратып тормыйсыз, су кранын да иске чүпрәк-чапракка урарга маташмыйсыз. Аның каравы, үтә күренмәле савытка махсус сыеклык саласыз да Интернетта теге бөҗраның сызымын табасыз. Шул экрандагы сызым булган смартфон белән сыеклыкка яктыртасыз һәм биш минуттан кирәкле бөҗра әзер!

Моны инде бүген үк эшләргә була, дөрес, әлегә лаборатория шартларында гына. Аддитив технологияләр (инглизчәдән additive – «өстәлә торган», объектны катлам-катлам итеп өстәп үстерүне күздә тота), ягъни өч үлчәмле объектларны лазер ярдәмендә полимерлардан яки металл порошогыннан принтерда «нәшер итү» фәндә һәм сәнәгатьтә күптән кулланыла. Фәкать элегрәк бу эш бик кыйммәт һәм озак иде. Хәзер исә вазгыять бик тиз үзгәрә бара.

Фото: Ната Смирнова

КЮВЕТАДАГЫ ТЕШЛӘР

– Бу фотополимер принтер, – ди прототиплаштыру лабораториясе мөдире Рамил Кашапов, үтә күренмәле кювета көйләнгән кызгылт-сары агрегатка күрсәтеп. Кюветада кеше артериясенең пластиктан ясалган өлеше ята. – «Нәшер итү» процессында контейнерга фотополимер салына, принтерга виртуаль сызым кертелә. Аннары катлам-катлам «яктыртып алу» эше бара. Һәр катлам саен контейнер яктылык чыганагына таба береаз күтәрелә бара. Шул рәвешле бик тиз генә полимер прототип яки әзер әйберне ясап алырга була.

– Бу принтерны Казан электротехника заводы заказы буенча ясадык. Ул серияле эшләп чыгарыла башлар дип планлаштырыла. Илебезнең оборона сәнәгате предприятиеләре белән хезмәттәшлек – өметле башлангыч, чөнки федераль программа нигезендә аларның яртысы продукциясе гражданлык кулланышы өчен булырга тиеш, – дип аңлатып уза Рамил Кашапов.

3D-принтерлар медицинада актив кулланыла. Мәсәлән, теш протезлары ясаганда. Россиядәге стоматология клиникаларының күбесендә протезның беренчел калыбы элеккечә балавыз белән кулдан ясала. Соңыннан шуның нигезендә металл эшләнмә коялар. Тешнең 3D сурәте нигезендә принтердан полимер каркас ясап чыгару берничә тапкыр тизрәк тә, төгәлрәк тә булачак. Бер кюветада төрле кешенең берничә дистә теш моделен берьюлы эшләп чыгарырга мөмкин.



БАРЫСЫ ДА ҮЗЕННӘН ҮЗЕ ЭРЕП ЮГАЛАЧАК

Бик-бик юка рәсем челтәреннән гыйбарәт көмешсу әйбер галәмнән килгән яки яңадан шунда очып китәргә җыенган гайре табигый нәрсә булып тоела. Юк икән. Бу – кешенең бер кисәкчеге, төгәлрәк әйткәндә, умырткалыкның муен өлеше.

– Бу имплантат – кейдж прототибы. Әлеге кейджны һәм аны куллану ысулын нейрохирург Илгизәр Вәлиев җитәкчелегендә Республика клиник хастаханәсе белгечләре әзерләгән. Сынган яки тайган умыртканы дәвалаганда, кейдж аны эләктереп куюъ өчен урнаштырыла. Аның сызымы умырткалыкның зыян күргән өлешен компьютер томографиясе белән сурәткә төшереп эшләнә, – дип сөйли Рамил Кашапов. – Табиблар белән бергә без кейдж җитештерүнең берничә ысулын сынап карадык. Башта беренчел калыпны фотополимердан ясап, шуны металлдан койдык, тик ул вакытта челтәрле структура барлыкка килми иде. 3D-принтер һәм лазерлы кыздырып укмаштыру ысулын файдаланырга карар кылдык. Кейдж металл порошокның калын катламында лазер нуры белән «пешереп» ясала. Берьюлы берничә дистә кейдж ясарга була. Илебез медицинасында заказга эшләнгән имплантатлар гадәттә бик кыйммәт тора, ә мондый ысул, беренчедән, җитештерү процессын шактый тизәйтергә, ә икенчедән, аны сизелерлек арзанайтырга ярдәм итәчәк.

Рамил эндопротезлар ясау өлкәсендә чираттагы проект турында сөйли: Республика клиник хастаханәсенең патанатомия бүлеге мөдире, профессор Иван Рагинов белән бергә КФУ инженерлары биорезорбтив (биотаркалучан) имплантат ясау юнәлешендә эш алып бара.

– Сөяк сынган очракларда, пациентка кайвакыт Илизаров аппараты кебек механик фиксаторлар куела. Аны салдыру өчен, яраны кабат ачарга туры килә. Ә 3D-принтер ярдәмендә ясалган безнең имплантат, акрынлап эреп, сөяк тукыма белән алышына башлаячак һәм икенче операция кирәк булмаячак, – дип аңлатма бирә Рамил Кашапов.

ТУЗАННАН – КҮККӘ

Өч үлчәмле принтер белән эш итү өстәвенә теге яки бу продуктны базарга чыгару вакытын тизәйтергә һәм прототиплар җитештерү процессын арзанайтырга мөмкинлек бирә.

– Әйтик, безгә самолет двигателенең яңа калаклары прототибын сынарга кирәк. Гадәткә кергән эш тәртибе мондый: прототип сызымнары буенча пресс-калып ясала, шуңа балавыз агызалар. Ул каткач, аны керамик тышча белән каплап алалар. Аннары балавызны эретеп, шул тышчадан бушаталар да барлыкка килгән куышлыкка сыек хәлдәге металл тутыралар. Шул рәвешле прототип барлыкка килә. Аны эшкәрткәч, камилләштергәч, пресс-калып яңадан эшләнә. Бу шактый хезмәт чыгымы таләп итә, – дип аңлата Рамил Кашапов. – 3D-басма технологиясе, бу очракта лазерлы кыздырып укмаштыру ярдәмендә двигатель калагы прототибын без полистирол порошогыннан ясыйбыз. Сызымга үзгәреш кертелгәндә, детальне яңадан «бастырып чыгару» өчен кирәкле матди чыгымнар һәм вакыт – минималь дәрәҗәдә. Пресс-калып исә бер генә тапкыр – детальне серияле җитештерү өчен генә ясала.

Эретеп кою технологияләрен үстерүдә институт күп еллар Яшел Үзәндәге А. М. Горький ис. завод белән хезмәттәшлек итә. Хәзер институт белгечләре, шул исәптән, 3D-принтерларны сәнәгый масштабта куллану өчен яңа полимерлар булдыру белән дә шөгыльләнә.

PRESSA.RU

ПРОФЕССОР БАШЫ, ТИК ДОУЭЛЬНЕКЕ ТҮГЕЛ

Күрше бүлмә өстәлендә кеше башы тора, анысы да принтерда чыгарылган. Инженер шул башның борынын һәм тирене алыштырган өсьяпмасын читкә алып куя. Мәрмәр төсмердәге баш сөяге шәрәләнеп кала. Сандыктан чыгаргандай итеп, аннан полимер баш мие, аннары – шулай ук полимердан ясалган чөйсыман сөяк алына.

– Шешне борын аша кисеп алганда, бу шешкә бик тәҗрибәле хирург кына тиз арада һәм төп-төгәл рәвештә барып җитә ала. Ә нейрохирургиядә мондый операцияләр шактый еш була. Бу баш студентлар һәм яшь белгечләр өчен үзенә күрә тренажёр булып хезмәт итә. Әлеге модельне Дельрусс ширкәте белән берлектә Төбәкара клиника диагностика үзәге нейрохирургы Бәхтияр Пашаев әзерләде, – дип сөйли Рамил Кашапов. – Шуңа охшаш проект буенча без Республика онкология диспансеры нейрохирургы Андрей Рудык белән бергә эшләдек. Баш мие томограммалары нигезендә макет ясала иде, шуның ярдәмендә операция планлаштырыла. Мондый модельләр хәзер Балалар республика клиник хастаханәсенең йөз-казналык хирургиясе бүлегендә кулланыла.

КИЛӘЧӘК КУЛЫ

Робот техникасы лабораториясенә керәбез. Бер өстәлдә пластик детальләрдән җыелган кул ята, ул детальләрне дә принтерда чыгарганнар.

– Без нигездә кешесыман роботлар белән эшлибез. Аларның адәм баласына охшашлыгын тернәкләндерү тренажёрлары һәм бионик протезлар кебек хезмәтләр өчен файдалана алабыз, – дип аңлатып уза бу кул турында инженер Рамил Хисаметдинов.

Башка проектлардан кала, хәзер лабораториядә био(мио)электрик протезлар базарындагы алдынгы ширкәтләрнең берсе – «RSL Steeper» компаниясе тәҗрибәсен өйрәнәләр. Әлеге компания BeBionic кул протезлары эшләп чыгара. Аларга миодатчиклар көйләнгән, карбоннан ясалган кул чугы һәм бармаклар шуңа күрә кеше кулы хәрәкәтләрен төп-төгәл диярлек кабатлый. Бу фантастика да кебек, шулай ук бик заманча да күренә.

– BeBionic протезларының бәясе Россия базары өчен бик кыйммәт. Без исә үз модельләребезне булдырырга, күпләр сатып алырлык бәядән ясарга телибез. Әлегә болар барысы да проект дәрәҗәсендә генә, әмма без аны тормышка ашыра алырбыз дип өметләнәбез, – ди Рамил Хисаметдинов.



Фото: Ната Смирнова



БИЕ, РОБОТ, БИЕ

Күрше өстәлдә зур булмаган бер роботка җан керә. Ул берничә адым ясый, егыла, аягына баса, идәннән этелеп китә. Боларның барысын да үзе эшли кебек, ләкин чынлыкта аның белән махсус программа идарә итә. Робот техникасына өйрәнергә теләге булган һәр мәктәп укучысы бу программаны шактый җиңел үзләштерә ала. Бу «җанлы» машина шуның өчен ясалган да.

– Россиядә бу проектның тиңдәшләре юк. Роботны без монда, Аддитив технологияләр үзәгендә принтерда чыгарылган детальләрдән җыйдык. Аның хисаплау-идарә итү үзәге робот техникасында киң кулланыла: Arduino (Ардуино) процессоры һәм Raspberry Pi (Распберри пай) микрокомпьютеры турында сүз бара. Ә менә контроллерларны үзебез эшләдек. Алар универсаль: башка бик күпләреннән аермалы буларак, робот төрлечә хәрәкәтләнә, бөгелә, атлый, шуыша ала һ.б. Моннан тыш ул бер кочак датчиклар белән җиһазландырылган, – дип сөйли Рамил Хисаметдинов.



Кечкенә кеше-машинаның маңгаена камера урнаштырылган. Уяу ата-ана әлеге робот ярдәмендә баласының өйдә ни белән шөгыльләнгәнен турыдан-туры вакыт режимында күзәтергә мөмкин.

– Бала кеше робот өчен үзе дә программа яздыра ала. Әйтик, роботның аягын күтәрәсез дә төймәгә басасыз һәм бу хәрәкәт аның хәтеренә кертелә. Аякны төшерәсез – янә төймәгә басасыз. Аннан икенче аягын шулай хәрәкәтләндерәсез. Соңыннан хәрәкәтләр санын билгеләп, программаны эшләтеп җибәрәсез – һәм робот атлап китә. Монысы – бик кечкенә балалар өчен. Студентлар исә, мәсәлән, гироскоп мәгълүматларын кулланып, бик зур төгәллек таләп иткән билгеле бер маршрутны узу программасы язарга мөмкин. Өстәвенә, роботка мәктәп программасыннан материаллар кертергә һәм шул рәвешле өй эшләре әзерләргә, тестлар узарга да була, – дип аңлата программист.

Робот ул арада бик матур да, кызык та рәвештә брейкка охшашрак бию башкара.

– Кешесыман машиналарның төгәллеге адәм балаларын бераз шүрләтә дә, кәефен дә төшерә. Ә бу машиналар ялгышканда, алар күбрәк безнең үзебезне хәтерләтә. Шул вакытта безгә машиналар белән үзара элемтә урнаштырып эш итү дә кулайлаша, – ди инженер.

ТОМАН ТАРАЛГАЧ...

Лаборатория өстәлендә самогон аппаратын хәтерләткән җайланмага күзем төшә. Уртада – ниндидер пар чыгарып торган пыяла колба.

– Томан ул, – ди Инженерлык институтының техник физика һәм энергетика кафедрасы доценты Александр Лучкин.

Лабораториядә ионлаштырылган газ – плазма белән эш итәләр. Ул, мәсәлән, төрле өслекләргә атом хәлендәге матдәләрне бик юка япма итеп төшерү өчен кулланыла.

– Плазма хәлендәге тузансыман матдә белән каплау ысулын куллану өлкәсе бик киң – металл корылмаларны тутыгуга каршы эшкәртүдән башлап, смартфон пыялаларына махсус өслек төшерүгә кадәр. Сүз уңаеннан, билгеле бер даирәләрдә кайчандыр бик популяр «алтын» коронкаларны титанны азот тузаны белән каплап ясарга мөмкин. Бу очракта нитротитан барлыкка килә, ул металл өслеккә утыра. Мондый каплама озак вакыт кырылмый, ышкылмый тора. Тик хәзер мондый тузансыман матдә белән каплау ысулын күбрәк хирургия коралларының, әйтик, скальпельләрнең чыдамлылыгын арттыру өчен файдаланалар, – дип сөйли инженер.

Плазма хәлендәге тузансыман матдә белән каплау өлкәсендәге тикшеренүләр аеруча оборона сәнәгате һәм авиакосмик сәнәгать өчен кирәк.

– Матдәнең, әйтик, шул ук кварцның оптик үзлекләре аның өслектәге калынлыгына бәйле. Без бу юнәлештә тәҗрибәләр уздырабыз, Казандагы Гамәли оптика дәүләт институты белән берлектә тикшеренүләр алып барабыз, – ди Александр Лучкин.

Колбадагы томанның моңа ни катнашы бар соң?

– Монысы тагын да фундаментальрәк хезмәт. Кыскача әйткәндә, без пыску халәтендәге бушану (газ мохитендә электр бушануы), тавыш һәм томанның үзара тәэсир итешүен өйрәнәбез. Бу колбада билгеле бер югарылыктагы тавыш дулкыннары барлыкка китерәбез, алар электр бушануы белән бергә томанның таралуына китерә. Башка бер эксперимент плазманың үзлекләренең түбән басым халәтендә һәм билгеле бер тавыш дулкыннары тәэсирендә үзгәрешен тикшерергә ярдәм итә, – диң аңлатма биреп үтә Александр Лучкин. – Тәҗрибә уңышлы узса, аның нәтиҗәләрен газ бушануы нигезендә эшли торган лазерларны көчәйтү өчен кулланып булачак.

Ә Казан галимнәренең исемнәре исә иртәгәсе көннең инде килеп җиткәнен хәбәр итә торган фәнни журналларда чираттагы мәртәбә урын алачак.

РЕДАКЦИЯ КУХНЯСЫ

«КАБАРТМАСЫЗ СЫЙ БУЛМЫЙ»

Автор:
Руфия Фазылова

Һәр районның, төбәкнең үзенә генә хас ризыгы була. Яшел Үзәндә ул кабартма икән. Кадерле кунак киләме, мәҗлес-мазар узамы – хатын-кызлар тизрәк кабартмага камыр куя. Тагын шул нечкәлеген дә әйтим – һәр авылның үз остасы бар. Зур табын уздырасы булсалар, аны чакыралар. Олы Ачасыр авылында ул – Кадрия апа Гарәфетдинова. Аның кабартмаларын авылда авыз итмәгән кеше юк.

Фото: Лилиана Вәлитова

Бу самими апа белән күбрәк аралашкан саен, аның киң күңеллелегенә, сабырлыгына гашыйк буласың…

– Кабартма пешерергә каян өйрәндегез? – дим аш-су остасына.

– Әнидән инде. Камыр ризыкларын яшьтән әзерли идем. Олы Ачасырга килен булып төшкәнгә, 34 ел булды. Төп йорт булгач, бездән кеше өзелмәде. Барысын да сыйларга кирәк. Татарда үзегез беләсез, камыр ризыгы әзерләмәсәң, табынның яме, ашның сые юк кебек…

– Тумышыгыз белән кайсы яктан? – дим.

– Яшел Үзән районының Танай авылыннан.

Икенче яктан Әминә апа тавышы ишетелә:

– Танай дип әйтелә генә ул, китапта аның тулы исеме «Татар Танае…»

– Сөбханалла, Әминә апа безнең сөйләшкәнне

«АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘ КӨЧ ТӘ, СӘЛАМӘТЛЕК ТӘ БИРӘ»

Хәер, кабартма Яшел Үзәннеке генә түгел. Кайбыч, Кама Тамагы, Буа якларында да әлеге милли ризыкны еш әзерлиләр, шул исәптән туган ягым Апаста да. Бездә Коръән ашларында тәлинкә төбендә юка, аның өстенә кабартма куялар. Әбибабайлар табыннан торып киткәч, башта баскан токмачлы ашны нәкъ менә кабартма белән ашыйсың. Ышаныгыз, моннан да тәмлерәк ризык юк…

– Ә безнең районда юка пешермиләр, – ди Кадрия апа.

– Табынга кабартмагыз юкасыз чыгамы? – дим гаҗәпләнебрәк.

– Әйе, кабартманы без пирог өсләренә тезеп куябыз.

Кадрия апа өйдә үзе генә түгел иде – башларына ак яулык бәйләгән мөлаем мөселман апалары да бар. Шуларның берсе әнисе – 91 яшьлек Әминә апа Камалиева, икенчесе – Олы Ачасыр авылы мәдрәсәсе мөгаллимәсе Әлфинур апа Шиһапова. Әминә апа Апас районының Биеш авылында яши икән, улы гаиләсендә. Ачасырга исә, үзе әйткәнчә, «утырмага» килгән.

– Казаннан кунаклар кайта дигәч, Кадриягә көч биреп торырмын дип, мин дә кердем әле, – дип, кул биреп күрешә Әлфинур апа. – Кадрияне бик дөрес эзләп тапкансыз. Авылда аның кебек тырыш, юмарт, аш-суга оста булган бүтән кеше юк, – дип тә өстәде.

Кадрия апа чынлап та тырыш: ялгызы гына булса да, ике сыер асрый, җәен дистәләгән тавык-чеби алып үстерә икән. Шуның өстенә, авылдагы алты әбине дә карый. Югыйсә үзенә дә 58 яшь тулган. Әле тагын төрле мәҗлесләргә камыр ризыклары пешерә, авылдагы «Зәбәрҗәт» фольклор ансамблендә чыгыш ясый. Олы Ачасыр мәчете каршындагы мәдрәсәдә укый, икенче классны тәмамлаган.

– Барысына да ничек өлгерәсез? – дим.

– Аллаһы Тәгалә көч тә, сәламәтлек тә бирә, әйтмәгәнем булсын, – дип елмайды.

Алты ел элек Кадрия апаның ире үлеп киткән, инфаркттан соң алты ай гына яшәгән.

– Ул вакытта улым өйләнгән, ә ике кызыбыз кияүдә түгел иде әле, – дип сөйләде ул. – Үлгән артыннан үлеп булмый, нишлисең, Аллаһы биргән гомерне генә яшибез. Берничә айдан кызларым бербер артлы кияүгә чыкты. «Вәгъдәгез җиткәндер», – дип, туй ясарга да каршы килмәдем. Зурлап кыз озаттым, мәҗлес җыйдым. Балаларның вакытында оя корып, тормыш башлаулары хәерле. Мине генә саклап утырмаслар…

КАДРИЯ ГАРӘФЕТДИНОВАДАН КАБАРТМА РЕЦЕПТЫ:

Кирәк булачак:
1. Сөт – ярты л
2. Йомырка – 3 данә
3. Шикәр комы – 100 г
4. Сары май – 150 г
5. Майонез – 1 аш кашыгы
6. Он – 4-5 стакан
7. Юеш чүпрә – 50 г
8. Тоз – тәменчә

PRESSA.RU

1. Салабыз!

2. Өстибез!

3. Туглыйбыз!

4. Агызабыз!

5. Кушабыз!

6. Изәбез!

7. Салабыз!

8. Басабыз!

9. Төшерәбез!

10. Кисәбез!

11. Түгәрәклибез!

12. Тезәбез!

икенче яктан да ишетеп алган, – дим Кадрия апага.

– Әйтергә дә куркам. Әнинең колагы да яхшы ишетә, күзлексез бәйли, күрә. Зиһене әйбәт. Гомергә телгә үткен, эшкә батыр булды.

– Син үзең дә әниеңә охшаган инде, – дип куйды мәдрәсә остазы Әлфинур апа да.

«ӘНИДӘН УЗЫП БУЛМЫЙ»

Кадрия апа без килгәнче камыр өчен кирәкле ризыкларны әзерләгән иде. Сөтне җылыткан. Йомырканың сарысын агыннан аерып куйган.

– Йомырканың агын салмыйм, камырны катыра, – диде Кадрия апа.

«Бисмилла» әйтеп, аш-су остасы эшкә кереште. Башта зур табакка йомырка, шикәр комы, тоз, чүпрә салды. Аннан барысын бергә миксер белән бутады. Янә шуңа җылы сөт, майонез өстәде. Яхшылап болгаткач, он кушып, камыр басты.

– Камыр бертөрле булып үзләнгәч кенә, эретелгән сары май салам, – диде Кадрия апа. – Гомумән, теләсә кайсы камырга майны соңыннан салырга киңәш итәм. Алай камыр йомшак та була, тиз кабара. Ә кабартмага мин өйдә ясалган сары май кушам. Әлбәттә, булмаса, кибетнеке дә ярый инде. Тик әбиләрдән калган рецепт буенча әзерлим, дисәң, һичшиксез, сары май кирәк.

Май өстәгәннән соң, янә азрак он салып, хуҗабикә эшен дәвам итте. Кадрия апа камырны ун-унбиш минутлап басты. Шуннан:

– Булгандыр инде бу, әни, кара әле, – дип, күрше бүлмәдә башмак бәйләп утыручы Әминә апага эндәште.

Әминә апа җәлт кенә чыгып кызы янына килде дә:

– Йә, кулыңны ал әле, – дип, камырга күз салды. Һәм:

– Булган бу, кызым. Камырың кулга ябышмый инде, – диде.

Мин бу күренешкә гаҗәпләнеп тә, сокланып та карап торам... Менә бит ул тәрбия! Кадрия апа ничә еллардан бирле үзе кешеләргә аш-су әзерләп йөри. Ачасырның әллә никадәр хатын-кызына кабартма пешерү серен өйрәткән. Ә үзе туксаннан узган анасыннан киңәш сорый!

– Әнидән узып булмый. Ул белми әйтми... – дип куйды Кадрия апа.

Хуҗабикә камырны изеп бетерде. Өстен кулы белән тигезләде дә:

– 25 ел фермада сыер саудым, – дип сүзен дәвам итте. – Ул вакытларны камырга кулымны тыкмадым – уклау белән изә идем. Сыер сауган кул бик ару да булмый бит. Фермадан киткәч кенә камырны кул белән ясый башладым. Әлбәттә, болай эшләү әйбәтрәк. Камыр тиз үзләнә.

Кадрия апа табакны башта сөлге белән төрде. Аннан өстенә бишмәт каплады:

– Ару әйберләр, аларны махсус камыр өчен генә тотам. Җылы булса, камыр ярты сәгатьтә кабара. Кабартмага юеш чүпрә яхшы, – дип тә өстәде тагын.

«МАТУРЛЫК ЯРАТАМ»

Аш-су остасының тәрәзә төпләренә күз салам: бер генә буш урын да юк. Ямь-яшел булып помидор, чәчәк үсентеләре утыра. Урын җитмәгәч, кайсын өстәлгә дә куйган. Гөлләр исә идәнгә төшкән.

– Үсентеләргә яктылык кирәк, – ди Кадрия апа. – Гөлләрне шуңа идәнгә күчердем. Җәен килегез, бөтен ишек алды, бакча – барысы да чәчәккә күмелгән була. Матурлык яратам шул.

Ул да түгел хуҗабикә табын янына дәште.

– Юл кешесенең тамагы ач була, әйдә, сезгә дип гөбәдия пешердем, – диде. Тәмле итеп чәен ясады...

– Безнең Ачасырда катык ипи кебек үк ул, ансыз табын кормыйлар, – диде Кадрия апа. Һәм үзе ясаган катыкны авыз итәргә кыстады.

– Кадриянең катыгын аеручა яратабыз, – дип сүзгә кушылды Әлфинур апа да. – Һәр пәнҗешәмбе көнне авыл карчыкларына катык ясап тарата ул. Изге көнелле кеше инде, нәрсә дип әйтим...

– Мал сәдакасы, – ди Кадрия апа. – Булгач, кызганыч түгел. Сыерлар исән-сау булсын, Аллаһы Тәгалә саулыгыбызны бирсен.

Сыер турында сүз чыккач, хуҗабикәдән сорап куйдым:

– Лаеклы ялдагы ялгыз хатынга ике сыер асрау нигә кирәк? Аның файдасы да юк дигәндәй.

– Сөте, катыгы, корты, эремчеге, каймагы, мае – тагын нинди файда кирәк, сеңлем? Гомергә сыер гаиләне туендыручы булды. Бүген дә шулай. Балаларым атна саен кайта, аларга тутырып җибәрәм. Сыер асрамаган күршеләремә, мәдрәсәдә бергә укучы хатын-кызларга сөт бирәм. Булгач, бирүе

дә күңелле. Булмаса – кыен. Сыерны акча дип кенә асрамыйсың бит, калганын гына тапшырам. Аннан, мәрхүм ирем исән чагында бик күп мал тоттык. Мин бу нигезгә килгәндә дә дистәләгән маллары бар иде. Хәзер сыерларны бетерсәм, каралты ятим кала. Мәрхүм ирем дә: «И, мин булмагач, бетерде бу малларны», – дип борчылып торыр кебек. Аякта йөргәндә сыерларны асрыйм әле. Кияүләрем яхшы, җәен кайтып, ел буена җитәрлек печәнне әзерләп китәләр. Балалар бик уңган минем, авылга кайткач, бер минут тик тормыйлар. Гел хезмәттә. Бергә эшләгәч, ашарга да күңелле...

Кадрия апа гел кыстый-кыстый сыйлый:

– Монысыннан да авыз итегез, – ди.

Баксаң, авылга концерт куярга килгән артистларны да аның йортына җибәрәләр икән. 2016 елның җәендә Ачасырга кино төшерергә бер төркем артист килгән. Ай ярым Кадрия апа йортында яшәгәннәр. Хуҗабикә аларга мунча ягып, аш, гөбәдия, бәлеш пешереп торган...

АВЫЛ БИЗӘКЛӘРЕ

Олы Ачасыр авылы каршындагы мәдрәсәдә 11 хатын-кыз укый, диделәр миңа. Мөгаллимә Әлфинур апа Шиһапова шактый еллар авыл мәдәният йортында мөдир булып эшләгән. Лаеклы ялга чыккач, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга кергән. Кулына диплом алганнан соң, авылдаш хатын-кызларына әнә шулай дин гыйлеме укытырга булган.

– Шәкертләрнең уңышлары бик сөендерә, – диде Әлфинур апа. – Берничә ай эчендә гарәпчә укырга, язарга өйрәнделәр. Шул исәптән Кадрия дә. Мәҗлесләрдә дә Коръән укый. Бер булганнан бар да була инде, иң яхшы укучыларның берсе ул.

Авылның «Зөбәрҗәт» ансамбле турында да сөйләштек. Анда сигез хатын-кыз йөри икән. Оешуларына өч ел гына булуга карамастан, төрле конкурсларда җиңүләр яулыйлар. Яшел Үзәндә булган төрле чараларга чыгыш ясарга йөриләр икән. Махсус күлмәкләр тектергәннәр.

– Ансамбль оештыру минем фикер иде, – диде Әлфинур апа. – Клубта эшләгәч, тәҗрибә бар. Олы Ачасыр элек-электән җырмоңга сәләтле авыл булып саналды. Кая гына барсак та, беренче урын безнеке иде. Шул заманда сәхнәдә йөргән хатын-кызларны бергә туплыйсы килде. Үзләренә бу турыда әйткәч, берсүзсез ризалаштылар.

– Ни өчен элегрәк ансамбль булып оешмадык икән дибез хәзер, – дип сүзгә кушылды Кадрия апа. – Авылның бизәге бит без. (Көлә – авт.) Күбрәк халык җырларын җырлыйбыз. Яңа чарага чакырганнарын кызлар белән көтеп кенә торабыз. Җәй көне – «Чишмә көнен», көзен «Бәрәңге бәйрәмен» уздырдык. Шунда камыр ризыклары да әзерләп бардым. Ансамбль белән дә чыгыш ясадык.

– Ә репетицияләр ничек уза? – дим. – Хуҗалык эшләрен ташлап, көн саен клубта йөри аласызмы?

– Чакырсалар, көн дә барыр идек әле! Атна саен концерт куймыйбыз бит. Конкурсларга, бәйрәмнәргә әзерләнгәндә, берәр атна репетиция ясап алабыз, шул җитә. Кич белән клубка җыелу аеруча күңелле. Күбебез фермада бергә эшләгән хатын-кызлар. Яшьлекне искә алып сөйләшәбез, көлешәбез. Аның миңа шунысы кадерле.

«ЗАМАННАН КАЛЫШМЫЙБЫЗ»

Кадрия апа елмая-көлә сөйләшсә дә, төп эше турында онытмый. «Булган бу», – дип, күбек кебек сап-сары камырны куна тактасына төшерде дә пычак белән кисқәләде.

– Моннан ике таба кабартма чыга, – диде.

Биш минут дигәндә, түгәрәкләрне әвәләп, җылы табага тезде:

– Биш-ун минут эчендә алар табада тагын бер тапкыр кабарып алсын, – диде.

Ул арада Кадрия апа электр мичен җылытырга дип кабызып җибәргән иде. Кабартмалар 180 градус чамасында пешәргә тиеш икән.

– Элек кабартмаларны мичтә, ялкында пешерә идек, – диде хуҗабикә. – Хәзер мичле кешеләр калмады. Әйе, ялкында пешкән кабартма җиңелрәк, тәмлерәк тә була кебек. Тик без электр миченә дә ияләндек. Утын ягып торасы юк, тиз дә, рәхәт тә. Инде кабартманы мичтә пешерә дә белмимдер, онытыла бит.

«Бисмилласын» әйтеп, Кадрия апа түгәрәкләнеп киткән кабартмаларны пешәргә озатты...

Шуңа игътибар иттем: хуҗабикә вакыт-вакыт телефонына карап ала. Нәрсәдер яза да.

– Кадрия апа, сез дә яшьләр кебек, гел телефонда ахры, – дим.

– И-и, – дип көлде хуҗабикә. – Ватсапта әллә ничә төркем бар: туганнар, авылдашлар, социаль яклау бүлегендә эшләүче кызлар белән язышабыз... Элек ничек яшәлгәндер, аз гына телефонга керми торсам, дөньядан артта калган кебек булам.

– Әле социаль челтәрдә күбебез үзенең битен булдырды, – ди Әлфинур апа. – Мин инде җитмешкә җитеп киләм. Кешедән калышмыйм дип кенә теркәлгән идем, кызык. Үзе бер дөнья.

– Интернет рәхәт нәрсә икән, – диде Кадрия апа. – Балалар белән аралашыр өчен дә яхшы, фотолар җибәреп кенә торалар...

Кабартмалар ярты сәгать дигәндә пеште дә. Май чүлмәге тышыннан билгеле булган кебек, кабартмаларның уңасы камырыннан ук күренә иде. Мамык кебек йомшак, күпереп торалар. Ә тәме.. Нәкъ менә безнең балачактагы кебек: әчкелтем дә, шул ук вакытта татлы да... Баскан токмач ашы гына җитми. Шуңа күрә кабартма пешерергә уйласагыз, иренмәгез, шулпа да куегыз. Телне йотарлык булачак!



ТАТАРСТАН КОМАНДАЛАРЫ

Казан – спорт башкаласы. Бу инде исбатлауны таләп итми торган хакыйкать. Гаҗәеп тойгылар уята торган спорт сарайлары, бассейннар һәм ареналар – Татарстан башкаласының заманча йөзенең бер өлеше. Бу шулай ук Универсиада-2013, су спорт төрләре буенча дөнья чемпионаты яисә «Формула – 1» авиация ярышлары кебек иң эре халыкара спорт чараларын үткәрүгә дә кагыла.

Шулай да спорт башкаласының горурлыгы, аның үзенчәлекле визит карточкасы – аның иң яхшы командалары. Ил күләмендәге ярышларда һәм халыкара турнирларда Казанны һәм республиканы лаеклы рәвештә танытучы клублар медальләр яулый һәм олы җиңүләр вакытында җанатарларга искиткеч кичерешләр бүләк итә, айлар, кайчак еллар

Фотолар «Рубин» ФК (rubin-kazan.ru), «Ак Барс» ХК (ak-bars.ru), «УНИКС» БК (www.unics.ru) рәсми сайтларыннан алынды

АЛАРДАН БАШКА ЯШӘП БУЛМЫЙ ТОРГАН КОМАНДАЛАР

буе көткән бәхетле мизгелләр белән сөендерә. «Ак Барс», «Рубин», «Зенит», «УНИКС», «Синтез», «Динамо»... – Татарстанны дөнья күләмендә таныту юнәлешендә алар барлык паир-акцияләр һәм презентацияләр нәтиҗәсендә ирешелгәннәрдән дә күбрәк эшлиләр, дисәк тә, мөгаен, дөрес булыр. Әлеге командалар уңышын «Татарстан» журналы битләрендә яктыртa бару бик урынлы булачак, килешәсездер. Бу санда «Динамо-Казан» волейбол клубы турында сөйләргә булдык.



«ДИНАМО-КАЗАН»: ҖИҢҮ ФӘНЕ

Топ-команда ул. «Динамо-Казан»ның волейболчы кызлары, дүрт ел элек планетаның иң көчле клубы исемен яулап, бу дәрәҗәгә лаек икәннәрен бик ышандырырлык итеп дәлилләде. 2014 елгы ул искиткеч команданың күп уенчылары инде спорт карьерасын тәмамлады, ләкин аларга алмашка килгәннәрнең ният-теләкләре һич тә калышырлык түгел. Быелгы сезонда да менә Ришат Гыйләҗетдинов командасы кызлары инде яуланган Россия кубогы янына ил чемпионатының алтын медален өстәп кую мөмкинлегенә ия.

ВИЗИТ КАРТОЧКАСЫ

«Динамо-Казан» волейбол клубы. 2011, 2012, 2013, 2014, 2015 елларда Россия чемпионы; 2014 елда Чемпионнар лигасы җиңүчесе; 2014 елда Клублар арасында дөнья чемпионаты җиңүчесе; 2010, 2012, 2016, 2017 елларда Россия кубогы иясе; 2017 елгы Европа волейбол конфедерациясе кубогы иясе.

«Һәр стресс алгарышка китерә» дигән канатлы гыйбарәне Казан волейбол клубы 2007/2008 елгы сезонда үзендә сынап карый. Нәкъ менә шул сезонда республиканың Транспорт министрлыгы җитәкчелеге «Казаночка»ның («Динамо-Казан» клубының элекке исеме – ред.) үзенә кирәк түгеллеген белдерә. Нәтиҗәдә кызлар сезонга шәһәр пляжында әзерләнергә мәҗбүр була. Ул елны бик күп уенчылар командадан китеп бара. Сезон коточкыч тәмамлана, клубта калган спортчы кызларның күзләрендә үпкә яшьләре ялтырый иде: команда суперлигадан төшеп кала…

Хатын-кызлар волейболында «Текә пикедан чыккан өчен» номинациясе булса, аның бүләген чираттагы сезон өчен, һичшиксез, Казан клубына бирерләр иде. Бәлагә тарыган команданы ул вакытта Әсгать Сәфәров җитәкләгән ТР Эчке эшләр министрлыгы үз канаты астына ала. Шулчакта ук клуб бүгенге исемә күчте – «Динамо-Казан». Һәм йөрәк тотарлык берничә уеннан соң суперлигага кайтырлык көч таба.

Мөгаен, андый җитезлекне бик сирәкләр генә көткәндер, аеруча узган елгы уңышсызлыктан соң. Ләкин тора-бара эшләр үргә китә. 2009 елның июнендә баш тренер вазыйфасына килгән Ришат Гыйләҗетдинов – ул вакыт өчен суперлигада әле яшь остаз – «Динамо-Казан»нан чыннан да һәр яуга әзер коллектив туплауга ирешә. Атаклы Николай Карполь шәкерте, бик зур селекция эшен башкарып, Казанга иң югары дәрәҗәдәге уенчыларны чакыруга ирешә. Дөнья волейболы йолдызы Екатерина Гамова белән килешү төзүе турында игълан итеп,

Фото: Роман Кручинин һәм Сергей Елагин (dinamo-kazan.com)

клуб 2010 елда ук трансфер базарында зур шау-шу уята. Блоклаучы Мария Борисенко, 2010 елгы Россия чемпионатының иң яхшы уенчысы Татьяна Кошелева, илнең иң яхшы либероларның берсе булган Екатерина Кабешова да «Динамо-Казан»ны баета.

Команданы яңартудан гыйбарәт катлаулы чор акрынлап үз җимешләрен бирә башлый. Шул исәптән баш тренерның абруе да моңа булышлык итә.

«Карьерамны Казан «Динамо»сында дәвам итү турында карар бирүемә этәргән факторлар күп иде», – дип яза үзенең «Game Over. Волейбол продолжается» китабында Екатерина Гамова. – Иң әһәмиятле сәбәпләрнең берсе клубның баш тренеры Ришат Гыйләҗетдинов булу иде. Ул җыелма командада Кузюткинның ярдәмчесе булып эшләде, аны тренер буларак та, кеше буларак та яхшы беләидем. Ул Татарстан клубын 2009 елның июнендә җитәкләде. Бу вакытта мин инде «Фенербахче» белән килешү төзегән идем. Җыелма командада вакытта Марина Бабешина белән: «Ришат Сиражетдинович, бер елдан үзегез янына эшкә аласызмы?» – дип көлештек тә әле. Җавап итеп ул да көлде: «Әлбәттә, алам!» Безнең шаярып кына әйтелгән «үтенеч» күрәзәчелек булып чыкты… «Динамо»га югары дәрәҗәдәге уенчыларны чакырулары турында хәбәр миңа да килеп ирешә. Асылда, иң югары биеклекләрне яулау максаты куймаган клубта уйнау минем өчен кызык та булмас иде».

«Динамо-Казан»ның төп составы берничә ел дәвамында тренерлар штабы һәм клуб җитәкчелеге тарафыннан берәм-берәм сайлап туплана. Җиңүгә куәтле омтылышларын кызлар 2013/2014 елгы сезонда бөтен волейбол дөньясына ачык күрсәтә. Россия кубогы өчен уенда Мәскәүдәге адашларына җиңелү дә аларны туктатмый. Чынлыкта бу оттырыш командабызның, ике ел рәттән мәскәүлеләрне Чемпионнар лигасыннан бәреп чыгарган өчен (хәлиткеч матч кубок өчен уен алдыннан гына узган иде), аларны бераз юату кебегрәк була. Нәтиҗәдә, Казан кызлары Европа Чемпионнар лигасының төп бүләген Россиягә кабат (атаклы «Уралочка»ның җиңүеннән соң 19 ел узгач тәүге тапкыр) алып кайтуга ирешә. Ул елны хәтта волейбол белән һич кызыксынмаган кешеләр дә Татарстан башкаласыннан килгән клубның финалда Баку «Рабита»сын ничек тар-мар итүен күзәтте. Ә социаль челтәрләрдә җанатарлар волейболчы гүзәлкәйләргә гашыйк булулары турында йөрәк серләрен ачып постлар яза.

Европаның клуб беренчелегендә җиңү Ришат Гыйләҗетдинов шәкертләренә Клублар арасында дөнья чемпионатына юл ача. Һәм тагын җиңү! Бик шәп уздырылган сезон исә ил чемпионатында триумф белән төгәлләнә: финалда казанлылар Мәскәү «Динамо»сы кызларын ота. Нәтиҗәдә волейболчыларыбыз тарихка «алтын» хет-трик теркәп куя, ә команданың лидеры Екатерина Гамова шәхси хет-трик ясый – Россиянең, Европаның һәм дөньяның иң яхшы уенчысы дип танылa.

Бүген «Динамо-Казан» составында ул вакыттагы «алтын» командадан Ирина Воронкова, Дарья Малыгина һәм Евгения Старцева уйный. Быел Чемпионнар лигасында чыгыш ясаган Россиянең өч командасыннан Казан «Динамо»сы гына плей-офф стадиясенә барып җитә алды. Казанлыларга Европаның мактаулы бүләгенә юлны Италиянең «Конельяно» клубы бүлде. «Алтылык раунды»ның үз мәйданчыгыбыздагы уенында «Динамо-Казан» 3:2 исәбе белән отса да, Чемпионнар лигасының «дүртлек финалы»на узу өчен бу гына җитмәде.

Шулай да Россия чемпионаты финалы алдыннан кызларыбызның үз мәйданчыгында Италия клубын отуы бик мөһим вакыйга, дип саный өлкән тренер Александр Перепёлкин. Бу җиңү Мәскәүдәге адаш команда белән чираттагы дуэльдә Татарстан волейболчыларының үз-үзләренә ышанычын арттырырга тиеш. Алда – «Динамо»лар бәйгесе. Ник әле Казан кызларына алтынчы тапкыр ил чемпионы булмаска, ди?!

ЧИКСЕЗ МӨМКИНЛЕКЛӘР

Регина Миңлебаева – Гадел һәм Ранель исемле ике сөйкемле игезәк малайның әнисе. Үзе дә бик мөлаем ханым. Улларына 12шәр яшь. Гадел менә дигән итеп укый, футбол белән мавыга. Ә менә Ранель… катлаулы формадагы ДЦП авыруыннан интегә. Ул да, туганы шикелле үк, шәп укый, футбол белән мавыга – әмма болар барысы да өйдә.

Автор:
Алсу Дәүләтшина

ЯШИСЕ КИЛҮ

Регина зур горурлык белән гаилә альбомнарын күрсәтә – анда тупырдап торган, алма кебек түгәрәк битле сабыйларның фотолары бихисап. Ранель белән Гадел балачакта берберсеннән һич кенә дә аерылмаган – үсештә дә, килеш-килбәттә дә. ДЦП үзен бары тик сигез ай тулганда гына сиздерә. Регина бу хакта искә алырга яратмый. Әйе, кинәт кенә өйгә хәсрәт бәреп керә, күз яшьләре түгелә, дөньяның барлык төсләре җуела, «Ник моны нәкъ менә безгә бирдең? Нинди гаебебез бар?..» шикелле әрнүле дә, мәгънәсез дә сораулар ява Күккә... Әмма аннары Регина үзен кулга ала: шуннан соң барысы да элеккечә яши башлыйлар. Элеккечә кебек үк, дөресрәге.

– Минем яшәү теләгем яңадан уянды, – ди ул. – Ничек кенә булмасын, әйбәт итеп яшәү теләге. Рухым, үзем ничек кенә депрессиягә бирелергә теләсәм дә, барыбер өстен чыкты, мине чоңгылдан тартып алды. Балаларымны яратам лабаса мин, алар мине ярата, тагын нәрсә кирәк бу тормышта?

Регинаның мәхәббәте ике улына да җитә.

– Йә, ничек яратмаска мөмкин инде аны? – дип елмая әнисе, улы Ранельне ике битеннән дә үбеп. Җавапка улы да балкып елмая, әмма бу елмаюның аңа никадәр авырлык белән бирелгәнен аермачык күрәбез.

АНА БӘХЕТЛЕ БУЛСА, БАЛА ДА БӘХЕТЛЕ

– Ул һәрвакыт елмая, – ди Регина улы турында. – Бу кадәр ихлас итеп һичкем дә елмая алмый! – Шулай ди дә, Ранельнең борыныннан үбеп куя. Аннан Гаделне дә үбә, әмма малай, оялып, әнисенең назыннан кача – зур бит инде ул, янәсе!

12 ел элек, Ранельнең диагнозы белән килешкәч, Регина алдына бер сорау килеп баса: бу тормышта һәрберебезгә дә уңайлы булсын өчен, алга таба ничек яшәргә?

– Балаларым арасындагы аерманы күрмим дә, – ди ул. – Ышансагыз – ышаныгыз, ышанмасагыз – юк. Алар төрле – аермалары шул гына. Әйтик, кемнеңдер күзләре яшел, ә кемнеңдер – кара... Була бит шулай... Аларның көннәре төрлечә уза да, функцияләрне төрлечә үтиләр – мин моңа иялләштем, хәзер тыныч һәм табигый кабул итәм барысын да. Гадел, мәсәлән, үзе ашый, Ранельгә ярдәм итәргә кирәк – бу шулай һәм, димәк, син моны исәптә тотасың, дигән сүз. Миңа авыр түгел.Мин булмаганда, Гадел дә туганына бик теләп ярдәм итә. Ашату, юындыру, өстен алыштыру – болар көндәлек гадәти гамәлләр. Уку белән дә – шулай ук. Кемнеңдер, мәсәлән, бер баласы йөзүгә йөри, икенчесе – биюгә. Бездә дә хәл шундыйрак. Берсе бассейнга бара, икенчесе физзарядка белән өйдә шөгыльләнә. Берсе мәктәпкә барып укый, икенчесе – өйдә. Әмма Ранельне һәртөрле чараларга, утренникларга да йөртәбез... Бары маршрутны алдан ук уйлап куярга да, нюансларын исәптә тотарга кирәк. Боларны алдан хәл итсәң, бер кыенлыгы да юк. Гадел һәрчак янәшә, ул ярдәм итәргә атлыгып тора. Ә иң мөһиме: мин, әниләре, бәхетле булсам, алар да бәхетле. Мин моңа ышанам.

Бәхетле балалар әлеге мизгелдә кәбестә пирогыннан авыз итәргә теләк белдерә. Гадел үз кисәген әләктерә дә компьютерга уйнарга йөгерә.

– Ранельне хәзер ашатып алам да, Гадел янына озатам – алар берберләре белән уртак телне һәрчак табалар. Ә сезгә ул арада бер гаҗәеп тарих сөйлим...

ГАҖӘЕП ТАРИХ

Регина сөйләгән бу тарих чыннан да таң калдырырлык. Аның каһарманнары – Миңлебаевлар гаиләсенә бәхет елмайган, дисәк тә буладыр.

– Казанда инвалид балалар өчен бәйге уздырыла икәнен ишетеп белдем дә, катнашырга булдык, – ди Регина. – Ролик төшерергә кирәк иде, җиңүчегә бүләк – кумир-футболчысы сурәте төшерелгән автографлы футболка. Сөендек инде, без бит футболны яратабыз... – Регина артыннан стеналарга күз сирпибез – анда футбол белән бәйле постерлар, афишалар, плакатлар эленгән. – Гариза биргән идем, миңа «сезнең улыгыз безгә туры килә торган инвалид түгел – ул бит сөйләшә алмый» дигән җавап килде. – Регина рәнҗүен яшерергә тели, әмма үпкәсе күзләреннән күренә. Баласын гаделсезгә рәнҗеткән һәр ана шуларны кичерер иде. Ләкин шул арада ук яктырып та китә үзе, уллары турында сөйли бит.

– Шуннан соң мин без төшергән роликны Россиянең футбол сайтына җибәрдем, – дип, әчке бер горурлык белән дәвам итә ул. – Һәм инде ике сәгатьтән безгә шалтыраттылар, кунакка чакырдылар. Безнең барыбызны да, гаиләбез белән. Хәтта Ранельне озата йөрер өчен – әниемне дә. Билетлар түләнгән иде, утыр да бар гына! Һәм менә без Мәскәүгә чыгып киттек. Мәңге онытылмаслык көн булды ул! Камералардан тыш, көнелне эретә торган – танылган футболчылар малайларның башларыннан сыйпап уза, мәктәптә хәлләр ничек, дип сораша... Футболчыларның тренировкаларын карадык, Алан Дзагоевтан автограф алу бәхетенә ирештек. Ул – Гаделнең яраткан уенчысы. (Әйтүләре буенча, ул безнең видеоны дүрт тапкыр караган һәм безне чакырулары өчен дә без нәкъ менә аңарга рәхмәтле булырга тиешбез).

Аның белән фотога да төштек, Гадел хәтта интервью алырга да өлгерде. Алан Ранельгә карата зур игътибарлылык күрсәтте: фотога төшәр өчен аны хәтта кулына да алды. Һәм менә шушы колясканы бүләк итте. Казанга менә дигән күтәренке кәеф һәм якты тәэсирләр белән әйләнеп кайттык.

ТАУЛАРНЫ КЕМ КҮЧЕРӘ?

Регина белән сөйләшкәндә шуңа игътибар итәсең: ул бик җиңел сөяклеге генә түгел, ә балалары өчен таулар күчерердәй көч-куәткә ия ханым да. Чын-чынлап күчерә дә ул аларны. Шундый «тау»ларның берсе – «инвалидлар өчен парковка» дигән билге. Регинаның максатчанлыгы һәм булдыклылыгы нәтиҗәсендә, әлеге билгене аларның ишегалдында Татарстанда беренчеләрдән урнаштыралар.

– Күз алдына гына китерегез, безнең 9 катлы, күпфатирлы йортта миңа һәрбер фатирны шакып, сораштырып чыгарга туры килде: «Гафу итегез, минем балам инвалид, безнең ишегалдында, подъезд каршында «инвалидлар өчен парковка» дигән билге пәйда булса, сез каршы булмассызмы икән?» Әлбәттә, берәү дә каршы булмады, әмма миңа үтенеп ишекләр шакып йөрергә туры килде, шул гына. Култамгалар җыеп. Хәзер, шөкер, билге тора. Кайберәүләрнең, аны күрмәмешкә салышып, төбенә үк машина куюлары көнелне тырный, әрнетә, билгеле. Алар, нишләтәсең, миңа 12 яшьлек баланы һәм аның коляскасын подъездан чыгаруның ни бәһагә төшкәнен күзалламый.

ЯШӘРГӘ ӨЙРӘТҮ ФӘНЕ

Ранель турында сөйләгәндә, Регина аның сәламәтлеге белән бәйле бик күп сынаулар кичүе турында ассызыклый. Әмма ул аны мөмкинлекләре чикле бала дип исәпләми. Киресенчә, мөмкинлекләре чиксез бала, дигән караштa тора. Ләкин,

Фото: Ната Смирнова

PRESSA.RU

Футбол буенча Россия жыелма командасы спортчылары белән истәлеккә төшкән фото.

ди, Регина, ул мөмкинлекләрне тормышка ашыру өчен аңа даими ярдәм кирәк. Хәзер, әлбәттә, ил күләмендә дә, Татарстанда да инвалидлар өчен, 10 ел элек булган вазгыятьтән аермалы буларак, күп нәрсә эшләнә. Бу өч баскычлы ярдәм: дәүләт, бизнес һәм әти-әниләр. Соңгылары балаларының ихтыяҗларын барыннан да яхшырак белә – чөнки алар шушы борчумәшәкатьләргә күмелеп яши. Алар әйләнә-тирәне, баласы мохтаҗлык күрмәсен өчен, аңа яраклаштырырга кирәк икәнлеген яхшы аңлый. Ничек яраклаштырырга кирәк икәнлеген дә. Мисал өчен, өй буенча хәрәкәт итәр өчен уңайлы коляскалар кирәк. Урам коляскаларының булуы да зарур. Икешәр колясканы алу – күпчелек ата-ана өчен ирешеп булмаслык нәрсә, ләкин тырышалар бит, кая барсыннар! Ярый, болары булсын да, ди, ә менә махсус лифтлар белән нәрсә эшләргә? Пандуслар, кануннар – боларына инде, һичшиксез, дәүләт сәясәте ярдәмендә генә ирешеп була. Әлеге канун һәм карарларның үтәлүе дә кирәк бит: ата-ана, Регина кебек, парковка билгесе куярга рөхсәт итегезче, дип, соранып йөрергә калмасын өчен. Балалар һәм аларның ата-аналары үзләрен читкә кагылганнар итеп түгел, нормаль кешеләр итеп хис итсеннәр өчен. Мондый хәл һәркемнең башына төшәргә мөмкин бит...

БАЛАЛАР МАННЫЙ БОТКАСЫН АШАУЧЫЛАРГА ҺӘМ АНЫ АШАМАУЧЫЛАРГА БҮЛЕНӘ

– Минем хәлдә иң мөһиме – төшенкелеккә бирелмәү. Аңа бирелә, ягъни бирешә калсаң, шунда ук упкынга тәгәрисең. Ә ул упкынның төбе бармы, юкмы – берәү дә белми. Бәлки, син анда гомерең буена тәгәрәп тә төшеп җитә алмассың. Шулай булгач, нигә тәгәрәргә ди анда? Шушындый улларың булганда бигрәк тә?

Ә бу хәл бик мөмкин: балаңның инвалид булуын тоемлаудан түгел, юк, ә тирәдәгеләрнең реакциясеннән. Аларның карашларыннан, ә бигрәк тә – сүзләреннән. Ранель турында ишетергә мөмкин булган сүзләрнең иң йомшагы: «яшелчә». Аны мәктәпкә урнаштырганда, ниләр ишеткәнемне үзем генә беләм: «Нәрсә, укытучыларны яшелчәгезне үстерергә бакчачы дип белдегезме әллә? Аның бит мөмкинлекләре чикле!»

Мин болай дип җавап кайтара идем: «Әйдәгез, сезнең авыз, борыныгызны, кулларыгызны бәйлик тә, баш миегезне эшләргә калдырыйк! Сез нәкъ шулай ук барысын да аңлаячаксыз, әмма кыймылдап нидер эшли генә алмаячаксыз! Ул чикләрне башка төрле юллар белән кичәргә сәләтле! Сөйләшмичә, хәрәкәтләнмичә генә. Ә сез аның елмаюына карагыз – никадәр самими ул! Аның бит психикасы зыян күрмәгән. Ә сез менә мускулларыгыз эшләмәгән килеш, шулкадәр тырышып, ихластан елмаеп карагыз!»

Менә хәзер Ранель пирог сорады. Читтән карап торганда сез бары тик: «Аааа!» – дигәнне генә ишетәчәксез. Әмма ияләшә төшкәч, барысы да аңлашыла башлый: мин аның тавышыннан тоеп алам да пирог сузам. Аның бары тик үз теле – шул гына. Без бит барыбыз да ниндидер телдә сөйләшәбез: кемдер рус телендә, кемдер татар телендә, кемдер – кытайча. Ә Ранель – үзенекендә.

Йә, нинди «яшелчә» булсын ди инде ул?! Хәтерлим, шундый социаль реклама бар иде: «балалар манный боткасын ашаучыларга һәм аны ашамаучыларга бүленә». Бетте китте! Башка аерма юк!» Менә безнең Ранель да кофе ярата, ә Гадел яратмый. Бетте! Минем өчен башка аерма юк! Һәрбер әни шикелле үк, мин балаларымның имин үсүләрен һәм тормышта үз урынын табуларын телим. Алар белән горурланасым килә!

«ӘНИЕМ, БЕЗ – ТУНИСКА!»

– Мин шушындый ук шартларда позитивта яшәүче шактый әниләр белән таныш. Юк, елап утырмыйлар. Елмаеп яшәгәндә һәм нидер эшләгәндә генә барысы да килеп чыга бит – алар моны яхшы белә. Менә без – гадәти гаилә, кинәт кенә хыялда да мөмкин булмаганча, атаклы футболчылар янына чыгып киттек!

Ә 10 көн элек кенә мин Ранель белән дәвалау процедураларын алып йөрдем. Шулчакта бала процедурада вакытта үземә нинди дә булса шөгыль табарга кирәк, дигән фикергә килдем. Тоттым да документларымны КХТИга, читтән торып уку бүлегенә тапшырдым. «Икътисад, җитәкчелек итү һәм хокук» белгечлеге буенча икенче югары белем алырга ниятләп торам. 32 яшьлек «апа» булуга карамастан, яшь-яшь һәм чип-чибәр кызлар белән имтиханнар тапшырдым – аларның әле белемнәре дә үзләре кебек, «картаймаган». Кердем бит. Хәзер ничек өлгерергә инде дип, планнар корам, менә. Өлгерәчәкмен, билгеле! Өлгермичә ярамый!

Кыскасы, маҗара дигәндә, миңа куш! Балаларны иңгә утыртып, башка илгә чыгып китү, дисеңме. «Әнием, без – Туниска!» – дип, үзем әнине кисәтеп куям да, җилдерәбез. Курку хисе юк миндә. Менә бу «зарядник» (Регина Ранельның башыннан сыйпый – авт.) миңа

Ранель дә яхшы укый, ләкин өйдә генә.

– Мин барысын да булдырам, чөнки минем мохтаҗ булып яшисем килми!

һәрчак көч биреп тора. Аннан иңгән энергияне тоюга мин таулар күчердәй көчкә ия булам. Әлегәчә ирешә алмаган бердәнбер нәрсәм – мөмкинлекләре чикле балаларны дистанцион укыту өчен җиһазлар комплектын юнәтү. Ул безгә закон тарафыннан бирелергә тиеш. 2011 елның 16 сентябрендәге 771нче номерлы карар белән «Татарстан Республикасында «Электрон Татарстан» (2011–2013 еллар) мәгълүмати һәм коммуникацион технологияләрнең үсеше һәм кулланылышы» озак срокка исәпләнгән максатчан программасы расланды. Программа кысаларында минем балам югарыда әйтелгән комплект белән тәэмин ителгән булырга тиеш. Моңа федераль бюджеттан акчалар күчерелде.

Ләкин, ни кызганыч, әлегә ул юк! Инде күпме вариантны кулланып карадым: министр урынбасарында да булдым, балалар хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдә дә, администрациягә хатлар яздым, РОНОга, түрәләргә никадәр юл таптадым… Ә бит вакыт уза. Әлеге комплект ярдәмендә Ранель хәрефләрне укый да, таный да алыр иде. Нинди дә булса җитешсезлекләре булган баланың реакциясен билгели ул аппарат, аннары шул реакцияне күрсәтеп тә бирә. Барысы кирәгенчә җайлаштырылган. Арендага да бирелә ала, тулаем кулланылышка да. Казанда мондый комплектны күпләр алды һәм куллана, безнең очракта исә вакытында өлгермәдегез, диләр. Мин бусагаларны таптаган арада вакыт уза тора, Ранель инде 5нче сыйныфны тәмамлап килә. Билгеле, нинди генә ситуация булмасын, мин барыбер аннан чыгу юлын табачакмын. Бары ничек икәнен генә белмим әлегә. Әгәр алдында бер ишек ябылса, икенчесе, өченчесе ачылырга тора, дип юкка гына әйтмиләр бит.

МОХТАҖ БУЛАСЫМ КИЛМИ!

Карап торышка хатын-кызларча нәзберек-нәзакәтле тоелган Регина үз эчендә атом электр станциясен йөртә, диярсең. Аның барысына да ирешәчәгенә һич тә шикләнмим!

– Башта баш ватам, уйлап карыйм, аннары – эшлим, нәтиҗәгә ирешәм, – дип, тормыш итү кагыйдәләрен аңлатырга тырыша ул безгә. – Балалар моны күреп тора, шулай ук тик утырмаска, нәрсәгә дә булса омтылырга өйрәнәләр. Эшне дә үземә үзем үк уйлап табам. Тугыздан алтыга кадәр офиста утырырга мөмкинлегем булмагач, фриланс рәвешендә шөгыльләнергә мәҗбүрмен. Ирекле, бер тапкыр эшләнә торган, графигы кысаларга кертми торган эш белән, ягъни мәсәлән. Барысын да булдырам. Чөнки минем мохтаҗ булып яшисем килми!

ДЕПРЕССИЯ БЕЛӘН ТОРМЫШ УПКЫННАРЫННАН ЧЫГАР ӨЧЕН РЕГИНА МИҢЛЕБАЕВАДАН БЕРНИЧӘ СЕР:

– Һәрчак иң югары ноктада булу – мөмкин эш түгел. Очыштан, күтәрелештән соң гадәттә түбәнгә тәгәрәү булып ала. Табигый күренеш. Әмма бу әле һич кенә дә кулларыңны салындырырга кирәк, дигән сүз түгел. Хәрәкәттә булырга кирәк. Берни эшләмичә, төшенкелеккә бирелү – депрессиягә турыдан-туры юл.

Иң авыр чакларымда китап укыйм. Мин чын мәгънәсендә китап корты. Китаплар рухландыра, канатлар куя. Элегрәк психологларга, гаилә терапиясенә йөрергә тырыша идем, имеш, заман белән алга барам. Сафсата! Китаптан да яхшырак терапия уйлап табылмаган әле!

Эчемә негатив җыймаска тырышам. Шундый кешеләр бар, аларны «деструктив маятниклар» дип атыйлар, синең көнеңне бер сүзе белән бозып ташларга мөмкиннәр. Әмма мин андыйларга чик куя белам, «дураклар» дим дә игътибарымны башка нәрсәгә юнәлтәм.

Баш миен сүндереп кую да кирәк кайчак. Мәсәлән, рәсем ясарга утырып – искиткеч әйбәт техника, шунда ук тынычланасың.

Ә иң мөһиме – үзеңне ярату. Син елмаясың икән – балаларың да елмая, дигән сүз. Ана белән бала арасындагы бәйләнеш гаять көчле. Гаиләдә кем дә булса депрессия кичерә икән, башкаларга да бик кыен.

Яраткан дус кызымнан күңелем кайткан икән, гаиләмне сайлыйм. Чөнки аның аша минем өемдәгеләргә дә негатив үтеп керергә мөмкин.

Үземне даими үсештә тотарга тырышам. Тренажер залына йөрим – атнага ике мәртәбә. Сәламәт тәндә – сәламәт рух. Бу чыннан да шулай.

Бар нәрсәдән һәм һәр кешедән ямь табам. Начар гадәтләрне яхшыларына алыштырырга тырышам. Һәр айның беренче көне нәрсәне дә булса яхшыга үзгәртер өчен сәбәп. Яки – үз җитешсезлекләреңне төзәтергә. Мисал өчен, 1 гыйнвардан бирле мин шикәр кулланмыйм. Бөтенләйгә баш тарттым. Шикәрсез чәй эчәм һәм шушы вакыт аралыгында күзгә күренеп зифаландым. 1 февральдән салкын су белән коена башладым. Бу миңа бөтенләй ошамый, мин хәтта салкын бассейнны да күралмый идем. Әмма коенам. Һәм чирләми башладым. 1 марттан руль артында каешымны эләктереп йөри башладым. Элегрәк еш кына кирәксенми идем.

Тормыш әнә шундый вак кына җиңүләрдән тора.

Начар нәрсәләр турында уйларга вакытым юк. Кичә бер сайтта инвалидлар өчен президент гранты барлыгы турындагы мәгълүматка юлыктым. Ә минем бер проектым бар. Инде санаулы көннәр генә калган булса да, өлгерергә тиешмен. Шуның белән мәшгульмен, дүрт көн калып бара. Начар нәрсәләр турында уйлап утырырга вакыт кая калсын, ди!

Берәүдән дә сораганым юк. Барысын да үзем эшлим. Үзем уйлап табам, тормышка ашырам. Бәлки, бу дөрес тә түгелдер, әмма мин бит үземнең реакциямне беләм, ә башкаларныкын – еш кына юк. Шуңа үзең эшләүгә ни җитә!

Ни дә булса эшләргә алынсаң, җиренә җиткереп эшлә! Шул вакытта гына сине уңыш көтә.

PRESSA.RU

«ТАТАРСТАН» журналы өчен МАХСУС

БАЛАЛАРНЫ НИЧЕК САКЛАРГА?

Владимир Мамонтов, «Говорит Москва» радиостанциясенең генераль директоры, ни өчен игътибарлы һәм уяу булырга кирәклеге, нәрсәне күз уңыннан җуйсак, кире кайтарып ала алмау ихтимал икәнлеге хакында.

Каникулга оныклар килде һәм без, ниһаять, агач Буратиноны ясап бетерергә карар кылдык. Аның күзләре ун тиенлектән, борыны озын таякчыктан ясалган булса, башлыгы исә – гадәти оекбаштан. Ә менә куллары белән аяклары балта белән юнган инде, нишләтәсең. Аларны рәткә китерер өчен фрезер сатып алынды. Әби күзлегеннән карaганда, хәтәр нәрсә: үзе жуылдый, үзенең фрезалары үткен, кулланганда, чып-чын осталык таләп итә... Әмма нәтиҗәсе соң! Эшкәртелгән читләре ялт итеп тора, күгәннәре менә дигән итеп беркетелгән... кыскасы, тупас Буратинобыз күз явын алырдай кыяфәткә керә! Бу сезгә компьютерда атыш уйнау түгел инде, ә тормышта бер генә тапкыр булса да үз кулларың белән берәр нәрсәне җиренә җиткереп ясап карау!

Әлбәттә, беррәттән куркынычсызлык техникасы буенча курс та уздык: фрезаны ничек итеп оясыннан алырга да җәрәхәтләнмәскә, ни рәвешле бармакка шырпы кадалмаслык, күзгә йомычка чәчрәмәслек итеп эшләргә, гомумән фрезерны ничек тотарга, ә үзеңне – ничек... Эшне тәмамлаганнан соң, рефлексны ничек камилләштерергә дә розеткадан вилканы тартып чыгарырга. Ярый ла син инде олы кеше, ә бит тирә-юнеңдә компьютер чорына караган «бәләкәчләр», нигездә. Кызыксынып кына төймәгә басарлар да... – Алла сакласын!

Нәкъ менә шул рәвешле бер көтү «бәләкәч» белән пневматикадан атарга да өйрәнәбез: «солдат» пистолетның предохранителеннән тиешле дәрәҗәдә файдаланырга өйрәнгәнче, берсенә дә атарга рөхсәт ителми. Бала аңларга тиеш: төз ату – бер нәрсә, әмма аңарчы, рәхим ит, үзеңнең һәм башкаларның куркынычсызлыгын тәэмин итә бел. Без бу күнекмәне автоматизм дәрәҗәсенә җиткәнче кабатлыйбыз. Тиздән үзләре дә иялләшә: бер-берсен күзәтә һәм контрольдә тота башлый.

Минем бер иптәшем, гаиләсе белән сәүдә үзәге яисә күңел ачу комплексына килсәләр, һәрчак «урынны билгеләү» уенын уйнарга керешә. «Кайтасы юлны исеңдә калдыр», «узганда күргән атамаларны кабатлап чык», «чыгу юлын күрсәтүче яшел күрсәткечләр кайда очрады, әйт әле» – ул балаларына бу күнекмәләрне Кемеровода булган фаҗигагә кадәр бик күптән алда тукый килде. Болай, дөнья хәлен белеп булмый, дип кенә. Хәзер дә дәвам итә бу «уен»ны. Шул рәвешле балаларыбызны уяурак булырга өйрәтә һәм хәтәрдән саклап кала алуыбызга ышана. Аларның фикерләвен дөрес якка борып җибәрергә һәм тиешенчә күнектерергә кирәк, дип исәпли.

Башкача да мөмкин. Фрезаны кулга бирмичә. Мишеньга атудан мәхрүм итеп. Тирә-юнебез хәвефхәтәрсез һәм йөргән юлыбызга салам җәелгән, дип үз-үзебезне алдап. ...Әмма саламга ут кабарга мөмкин бит. Хәтерлим, шулай бервакыт мәктәптә укыганда урынны билгеләү буенча дәрес булган иде. Урманда, компас белән. Һәм ул дәреснең тормышта да кирәге чыкты. Урманда һәр агач артында сезне сакларга әзер кеше утырмый бит. Билгеле, бармаска да була урманга, хәтәргә юлыкмас өчен. Хәер, яшәмәскә дә – әйләнә-тирәбез бит алар белән мыжлап тора!

Менә шундый уй-карашлар белән яшәдем мин тормышта. Һәм телевидениедә Кемерово вакыйгасы турында сүз алып барганда, бу карашларымны башкаларга җиткерергә дә җөрьәт иттем. «Куркыныч фикер белдердегез әле сез, Владимир Константинович, – дип, шунда ук минем репликага чытырдатып ябышты алып баручы, янәсе, нәрсә килеп чыга, балаларны кинозаллар белән сәүдә үзәкләренә ышанып тапшырырга ярамый... – Ягъни сез «дип стэйт» тарафдары булып чыгасыз инде...

Телеканалда сөйләгәндә, фикеремне җиренә җиткереп белдерә алмадым шикелле тойгы калды, шуңа да монда аныклап бетерәм. Аңлыйсызмы, безнең тирәлегебез фальшь, ялган белән тулы. Карап торышка бик тә цивилизацияле тоелган фальшивка: сәүдә үзәге, ресторан, спорт мәйданчыгы, югыйсә, ә чынбарлыкта хромланган су бөркегече торбага да кушылмаган булырга бик мөмкин, сакчы иң беренче булып куркып качачак, кухня күселәр белән тулы, капка баланың башына әйләнеп капланырга күп сорамас... Безнең кибет киштәләрендә сыр бар – әмма ул һәрвакыт сыр булмаска да мөмкин, без инде моңа иялләшкән. Ә кайчан чыгарылганы, кайчанга кадәр сакланырга тиешлеге – гомумән икенче мәсьәлә. Безне иртәдән кичкә кадәр үзебезгә уяулык күрсәтергә өндиләр: балык белән казылыкны яхшылап иснәп карап алырга, нитрометрлар белән йөрергә, этикеткаларны һәйбәтләп өйрәнергә, биш төрле май тәкъдим ителә икән, аның «табигый» диелгәненнән дә кайсы табигыйрәк булуын җентекләп тикшерергә. Мине чыгырымнан чыгарган нәрсә менә

Иллюстрация: Стив Хонкс

ни: ә калган дүртесе монда нәрсә эшләп ята алайса?!

Безнең мәктәпләрдә балаларны, Европа рухындагыча, ничек итеп маньяк кулына эләкмәскә өйрәтәләр. Ул маньякны полиция тотарга тиеш түгелмени, дигән сорау бирә калсаң, сиңа диванага карагандай карыйлар. Һәм менә мин сорауны кабыргасы белән куярга мәҗбүрмен: киштәләргә чыккан сыр белән майның сыйфатын үземә тикшерергә калдырган дәүләткә мин ничек, бер борчусыз гына, балаларымны ышанып тапшырырга тиешмен, ди?! Ничек итеп мин балаларымны кино карар өчен кинозалда калдырып, ишекне бикләделәр дип, җиңел сулап, тыныч күңел белән кофе эчәргә китим? Ә без бит асылда ышанырга тиешбез: билет сатучыга, экраннан төшкән Микки-мауска, картаеп беткән губернаторга, саклаучы-фәрештәгә, илебезгә...

Параноиклар исән кала, гадәттә. Бу сүзләргә ышанмый да булмый. Уен бүлмәләренең диварларына пластик шартлаткыч урнаштырылган урыннарда барлык ата-аналарны да уяу булырга чакырам. Әйе, без урларга өйрәнгән төзүчеләргә суд оештырачакбыз. Җансыз инспекторларның да җинаятен, һичшиксез, фаш итәчәкбез. Без, «Зимняя вишня»ның хуҗасын Австралиядән кайтарып, цивилизация үрнәге буларак тәкъдим ителгән коточкыч ялган декорация торгызуы өчен җавапка тартачакбыз. Җавап бирмәгән берәү дә калмаячак!

Әмма балаларны гына кайтарып ала алмаячакбыз. Илебезне дә яхшыртачакбыз. Хәвефсезрәк итәчәкбез. Һичшиксез! Әмма ул көнгә кадәр үзебез дә, балаларыбыз да исән-имин барып кына җитә күрсеннәр иде берүк. Алай-болай, ялгышлык белән, юлда әрәм булмыйча.

PRESSA.RU

facebook.com/protatarstan

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

twitter.com/protatarstan

instagram.com/protatarstan

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

Реклама 16+

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Хәбәрсез югалганнарны **НИЧЕК** эзләргә

Рәфкать бабай **НИК** елый

Роберт Әхмәтҗановны **НИ ӨЧЕН** «альбатрос» дип йөрткәннәр

Алмыш хан татар тарихында **НИНДИ** эз калдырган

Шәкүр карак **КАЙДА** туган

СУГЫШ СЕРЕ: КОРБАННАР ҺӘМ ИСЕМЛЕКЛӘР

Бөек Ватан сугышы тәмамланганга 73 ел тулып килә. Тик әле һаман сугыш калдырган кайнар эз суынмый, аның тирән ярасы төзәлми. Ачыкланмаган сораулар да тарих сере булып кала бирә. Нинди сораулар ул, диярсез. Бу санда шуларга тукталырга булдык.

Автор:
Руфия Фазылова

ХӘБӘРСЕЗ ЮГАЛУ-ҮЛҮ ТҮГЕЛ!

Рәсми рәвештә Татарстанда 350 мең тирәсе кеше кире әйләнеп кайтмаган. (Казан Кремлендәге Бөек Ватан сугышы музей-мемориалының мөдире Михаил Черепанов, яңа табылдыкларны кушып, бу сан 388 мең чамасы дип саный). Шуның 180 меңгә якыны хәбәрсез югалганнар исемлегендә. Аларның күпчелеге турында әле дә бер мәгълүмат юк. Алай гына да түгел: хәбәрсез югалган солдатлар әле бүгенгәчә үлгәннәр исемлегендә йөрми. Кызык та, кызганыч та: 73 ел буе ул кешеләр фронтта диярсең! Хәер, һаман да ирләрен, якыннарын сугыштан көтүче апалар бар бит. Алар могҗиза булуына ышана. Ә бәлки нәкъ менә шул ышаныч бу апаларны яшәткәндер дә...

Дөньяның башка илләре күптән Бөек Ватан сугышында хәбәрсез югалганнарны юридик яктан үлгән солдатлар исемлегенә кертте.

– Ләкин Россиядә генә аларның «әйләнеп кайтуына» ышаналар бугай. Тагын да гаҗәбе: сугыш беткәннән соң, хәбәрсез югалган ирен, әтисен, якынын эзләп, хәрби комиссариатка килүчеләргә ул вакытларда: «Ә сез якыныгызның чынлап та сатлыкҗаннар рәтендә булмавына ышанысызмы?» – дип сорау яудыра торган булалар. Шуның өчен куркуга калган халык нигездә тыныч кына өйдә фронттагы кадерле кешеләрне көтеп ятуны хуп күргән, – дип ачыклык кертте Михаил Черепанов.

Совет власте йомшаргач та, кешеләр Бөек Ватан сугышында хәбәрсез югалган якыннарын эзләргә әллә ни ашыкмаган. Тормышны көйләргә кирәк, үткәннәр белән генә яшәп булмый бит... Еллар узган саен сугыш чоры балалары да олыгая барган, инде күбесе дөнья куйган. Аннан, мәсьәләнең икенче ягы да бар: сугышта хәбәрсез югалучы якыннарын тапкан очракта да, бу кешеләр өчен матди яктан моның әллә ни әһәмиятле булмаган.

Һәм менә алты ел элек әлеге тема тирәсендә ыгы-зыгы купты. Сәбәбе – 2012 елның 22 февралендә РФ Хөкүмәте тарафыннан кабул ителгән 142нче номерлы карар. Президент Владимир Путин ире, әтисе сугышта үлеп калган хатын-кызларга, балаларына акча бирергә (хәрби вазыйфасына карап – 200–300 мең сум) дип кул куйды. Бу яңалык Россиядә яшәүче күп гаиләләргә кагыла. Тик... хәбәрсез югалганнар үлгәннәр исемлегендә йөрми бит!

– Президент тарафыннан 142нче номерлы карар имзалангач, халык суд юлын таптарга кереште, – дип сөйләде Михаил Черепанов. – Үзәк Банктан акча алу өчен гражданнарга якынының сугышта һәлак булганлыгын исбатларга кирәк. Әкәмәт, бер яктан караганда, хәбәрсез югалган солдат, ул акчаны үзе килеп алырга тиеш, ул бит үлмәгән, янәсе. Соң, алтмыш-җитмеш ел хәбәре булмаган кеше үлгән булып чыга бит инде! «Әйдәгез, аларны юридик яктан үлгәннәр дип исәплик. Моның өчен әллә ниләр эшләргә дә кирәкми. Югалган кешене үлгән дип һәр районның судьясы игълан итә ала», – дидем. Юк, мине ишетүче булмады.

КЕНӘГӘДӘГЕ АКЧАЛАР

Бу турыда бөтен кеше белмидер дә, бәлки: Бөек Ватан сугышында, яу кырындагы һәр солдатка кертем кенәгәләре ачылган, ягъни һәр сугышчыга хезмәт хакы куелган. Гади солдатларга бер төрле хезмәт хакы – 20 сум түләнсә, югарырак дәрәҗәдәге хәрбиләрнең, мәсәлән,

Фото: Александр Ефремов

Еллар	Бөек Ватан сугышында Татарстаннан үлгән һәм хәбәрсез югалучылар
1941	66 000
1942	115 993
1943	83 723
1944	49 662
1945	24 444

Чыганак: «Рәсми Татарстан» порталы.

сержантларның, лейтенантларның хезмәт хаклары, солдатларныкына караганда бермә-бер артык була.

– Берничә ел элек Мәскәүгә – Федерация Советына киңәшмәгә барган идем, – ди Михаил Черепанов. – Анда Архангельскидан Солдат. ру сайтына нигез салучы Игорь Ивлев уникаль ачыш ясавы турында сөйләде. Ул, күп еллар архивларда казынып, менә нәрсәгә тап булган: 1942 елда СССРның Оборона халык комиссариаты структурасында СССР Дәүләт банкының кыр учреждениеләре барлыкка килә. Шушы оешма тарафыннан сугышта катнашучыларның һәрберсенә акча салу кенәгәләре ачылган булган. Кенәгәләр белән Оборона министрлыгы (ул вакытта Оборона комиссариаты) каршындагы финанс бүлеге идарә иткән. Сугыш тәмамланганда, кенәгәләрдә барлыгы 4 миллиард сумга якын акча хуҗаларына түләнмичә калган. Кемдер сугыш кырында үлгән, кемдер тоткынлыкка эләккән һ.б. төрле очраклар. Ә бит 1942 елда ук, оборона наркомы урынбасары Андрей Хрулевның күрсәтмәсе буенча, хәрбинең үлеме турында билгеле булса яки ул хәбәрсез югалса, аның гаиләсенә үлү таныклыгы белән бергә кенәгә яки аңа түләнергә тиешле акча турында белешмә дә җибәрелергә тиеш була. Ләкин бу эшләнми һәм кертем кенәгәләре хакында белүче кеше дә булмый. Әмма банк әлеге акчаларга җаваплы карый: сугышта катнашучыларның хезмәт хакы әле дә Россия Үзәк банкы фондларында җыелып ята. Акчалар еллар үтү белән индексацияләнә. Тик менә аларны бирергә генә ашыкмыйлар.

Закон нигезендә, сугышта катнашучыларның кенәгәләрендә җыелып барган ул акчаларны бүген хатыны яки балалары ала ала. (Оныкларга бирелми). Ләкин моның өчен иң элек ачыкларга кирәк: сугышчыга кертем кенәгәсе ачылган булганмы-юкмы. Бу сорауга җавап алу өчен Россия үзәк банкына (адресы: Россия үзәк банкы, Красноармейск кыр учреждениесе, 107016, Мәскәү шәһәре, Неглинная урамы, 12нче йорт) «фәлән-фәлән кешенең кертем кенәгәсе булганмы» дигән сорау белән хат юлларга кирәк. Иң мөһиме: хатта солдатның кайсы хәрби частьта хезмәт итүен төгәл күрсәтергә кирәк. Исем-фамилия буенча гына банк белешмә бирми. Шунысы да бар: сугыш кырында һәлак булган солдатның кайда хезмәт итүен ачыклау бик катлаулы. Эшне иң беренче җирле хәрби комиссариатка мөрәҗәгать итүдән башларга кирәк.

Сугыштан исән-сау әйләнеп кайтканнарның, нигездә, хәрби билетлары үзләре белән була. Анда исә аның кайда хезмәт итүе турында мәгълүмат бирелә. Алар да банкка хат юллый ала. Сугыштан кайтканнарның да, әгәр дә аңа кертем кенәгәсе ачылган булса һәм әлегә кадәр ул алынмаса, бүген дә хезмәт хакын алу мөмкинлеге бар.

«ЭНӘ БЕЛӘН КОЕ КАЗУ»

Янә хәбәрсез югалганнарга килик. Аларның язмышын ачыклау энә белән кое казуга тиң икән. Татар исем-фамилияле кешеләргә аеруча кыен, чөнки аларның исем-фамилияләре нинди генә вариантларга үзгәртелмәгән. Гайфуллин Гайсә – Райфуллин Гайсәгә, Әмирханов Американовка әйләнгән.

– Бер ханым гомере буе үзенең әтисен Мигманов фамилиясе буенча эзләгән, – диде Михаил Черепанов. – Кая гына мөрәҗәгать итмәгән, ә чынлыкта әтисен Мичманов дип теркәп куйганнар. Татар исемнәре белән тагын икенче проблема да бар: кайчак өч бертуган өч төрле язылыштагы фамилияне йөрткән. Татарлар балаларына әтиләре, бабалары исемнәрен дә фамилия итеп алган бит.

Хәер, татар гына түгел, рус исемнәрен дә нинди генә формаларда язмаганнар. Мисал өчен Владимир исемен биш төрле вариантта теркәгәннәр. Шуңа күрә хәбәрсез югалган туганыңны күпме эзләп тә таба алмау куркынычы бар.

– Соңгы биш ел эчендә 20 меңгә якын хәбәрсез югалган ватандашыбызның үлгән урынын ачыклый алдык, – ди Казан Кремлендәге Бөек Ватан сугышы музей-мемориалының мөдире. – Һәр табылган солдат турындагы мәгълүматны ОБД (БМБ, ягъни берләштерелгән мәгълүмат базасы) Мемориал сайтында (www.obd-memorial.ru) урнаштырылды. Теләгән кеше әлеге сайтка кереп, үзен кызыксындырган мәгълүматны карый ала.

Татарстанның үз сайты да бар: **www.kremnik.ru**. Анда сугышта катнашучылар турында мәгълүмат-

PRESSA.RU



лар хаталарсыз тупланган, татарча исемнәр дә дөрес язылган. Бүгенге көндә сайтта 400 меңләп кеше турында мәгълүмат урнаштырылган.

Россиядә сугышта хәбәрсез югалганнар белән эшләүче махсус оешма юк. Ләкин Михаил Черепанов кебек җаны-тәне белән шул эшкә бирелгән кешеләр һәр төбәктә бар. Алар бер-берсен белә, хәбәрләшеп, яңа табылган мәгълүматлар белән бүлешеп торалар.

– Һәр яз саен казу эшләренә чыгып китәбез, – ди Михаил Черепанов. – Көчле бәрелешләр булган җирләрне тикшерәбез. Элеккеге СССР илләренә караган калдыклар табабыз икән, шунда ук аларга хәбәр итәбез.

– 70 елдан соң да калдыклар буенча солдатның шәхесен ачыклау мөмкинме? – дим.

– Төрле очраклар була. Әлбәттә, сөякләр таркала. Әмма солдатның каскасы, шлемы, аерым күкрәк билгеләре буенча танырга мөмкин. Тагын бер үзенчәлек турында әйтәсем килә: немец солдатларының сөякләре тирәндәрәк ята, ә безнең солдатлар өстәрәк. Күрәсең, безнең сугышчыларны яхшылап күмәргә өлгермәгәннәр.

70 ЕЛДАН СОҢ...

Куркыныч сан: сугышка киткән һәр икенче кеше кайтмаган. Бүген, дистә еллардан соң, әлеге дәһшәт турында яшь буын онытып бара кебек. Һәрхәлдә, Җиңүнең нинди зур корбаннар, фаҗигаләр бәрабәренә килгәнен аңлап бетерми...

Бер генә мисал. Унынчы сыйныфта укучы бер үсмер малай белән сөйләшеп торабыз. «Әгәр безне Германия җиңгән булса, рәхәтрәк яшәр идек», – ди. – Германия алга киткән ил. Безне дә шундый тормыш көткән булыр

«БАБАЙНЫҢ КАБЕРЕН ЭЗЛӘП ТАПТЫК!»

Азат Мозаффаров, Кайбыч районы, Кошман авылы:

– Әтиемнең әтисе – Габдулла Мозаффаров сугышка 1941 елның көзендә алына. Сигез ай Суслонгерда була. Әби анда ике тапкыр бара. Бабайның ачлыктан тилмергәннәрен гел сөйли иде. Шуннан бабайны Смоленск янындагы фронтка җибәргәннәр. Ул анда яралана, госпитальдә ята. Савыккач, Воронеж шәһәренә җибәрәләр үзен. 1942 елның 19 августында шунда һәлак була.

1999 елда без, Воронеж шәһәренә барып, бабайның каберен эзләп таптык. Шәһәрнең үзәк военкоматында махсус журнал – полк командирының көндәлекләре саклана булып чыкты. Анда бабайның сугышчан юлы да язылган. «Туганнар каберлегендә күмелде» дип, конкрет адресы да күрсәтелгән иде.

Каберлек Мәскәү – Воронеж юлында, уң якта. Анда егермеләп кешенең исем-фамилиясе язылган. Әтиебез Фәритнең кабере өстендә Коръән чыктык, туган нигездән алып килгән туфракны сиптек. Әлбәттә, бик дулкынландык...

Безнең белән әтинең энесе Фәһим, аның улы да барды. Бабайны эзләүдә Фәһим абый башлап йөрде. Ул эзтабарлар оешмасына мөрәҗәгать итте. Эзли торгач, бабай турында шактый мәгълүмат табып бирделәр. Менә шулай итеп әтинең дә, Фәһим абыйның да гомерлек хыялы тормышка ашты – бабай каберенә барып дога кылдылар. Кызганыч, ул көнне әби генә күрә алмады. Ул гомере буе бабайны сагынып яшәде. Фронттан килгән бердәнбер хатны һәм бабайның хәбәрсез югалуы турындагы белешмәне Коръән битләре арасында саклады. «Читтә өйләнеп икенче гаилә корган булса да бәхил, бары яшәсен генә...», – дия иде.

«ӘТИНЕҢ ӨЧ КАБЕРЕ БАР»

Рәфкать Зарипов, Балтач районы, Түнтәр авылы:

– Әтиебез Шәкүр Зариповның сугышчан юлын дистә еллар эзләдем. Нәтиҗәдә, өч каберен таптым. Әйе, кызык та, кызганыч та...

Әти сугышка 1941 елның августында алына, мин сентябрьдә туган. Әни өч баласын ялгыз үстерә. Әти сугышка 1941 елның декабрь аенда гына керә. Әнигә: «Җәһәннәмнән котылам, фронтка китәбез», – дип хат яза. Суслонгерда оештырылган өйрәнү лагере, чыннан да, солдатлар өчен җәһәннәмгә тиң була. Кул белән окоп казып көн иткәннәр, аларга көненә бер стакан кәбестә суы биреп торганнар. Анда татар, удмурт, мари, чувашлар гына булган. Янәсе, фронтка кергәнче кешеләрне шулай рус теленә өйрәтәләр...

Әти 1942 елның 27 гыйнварында һәлак була. Ә өйгә 1945 елда гына хәбәрсез югалды, дигән хәбәре

иде...» Мөгаен, берәр сугыш ветераны моны ишетсә, өнсез калыр иде. Әйе, безнең буын ул яктан бәхетлерәк: сугыш китергән афәт турында шул коточкыч елларны күргән әби-бабайлардан ишеттек. 9 май көнне орден-медаль таккан бабайларны күреп сокланып та, гаҗәпләнеп тә карый идек. Ни кызганыч, сугыш ветераннары санаулы гына калып бара. Ә димәк, шул дәһшәтле еллар турында сөйләүчеләр дә бармак белән генә санарлык...

Бөек Ватан сугышы музей-мемориалына экскурсиягә төркем-төркем балалар килгән иде. Кемдер мөкиббән китеп, кемдер әллә ни хисләнми генә экспонатларны карап йөри. Ә Михаил Черепановның бер җөмләсе укучыларны җанландырып җибәрде:

– Балалар, Гитлер СССРны җиңеп безне рәхәттә яшәтергә уйлаган дисезме? Юк! Ул нацист булган, бары немецлар гына яшәргә хокуклы дип уйлаган. Халыкның бер өлешен үтереп, икенчесен кол итеп тотарга хыялланган. Ә безнең җирдә ул атом-төш кораллар базасы булдырырга ниятләгән....

Балалар тын да алмыйча Михаил әфәндене тыңлады. Кайберләре экспонатлар янына килеп озак кына уйланып торды. Укучыларга сөйләү, аңлату кирәк шул, алар телендә, чын, заманча итеп. Шулай булган очракта башларына әллә нинди ахмак уйлар кермәс иде...

Ә Бөек Ватан сугышындагы Җиңү – мөгаен безнең ил, хәер, Европа өчен дә иң әһәмиятле, хәлиткеч вакыйга ул. Моны киләчәк буын да аңласын иде. Һәм сугыштан кайтмаган бабаларын, тамырларын эзләү белән киләчәктә алар шөгыльләнер, дигән өметтә калам.

килә. Әтине без 1960 нчы елларда ук эзләргә керештек. Тик нәтиҗәсе генә булмады. Соңрак, 1995 елда, Подольск шәһәрендәге Төп архивка әти турында белешмә сорап хат юлладым. «Зарипов Шәкүр Иваново шәһәрендә җирләнгән» дигән җавап хаты килде. Туган еллары, авыл исеме дә туры килә. 1999 елда каберлекне күрергә туганнар белән җыелып бардык. Тик 6 мең кеше җирләнгән зиратта безнең әтинең исемен тапмадык. Шәһәр военкоматына кереп, Төп архивтан килгән хатны күрсәттем. Әтине, кабер ташларының берсенә теркәп куябыз, диделәр. Чынлап та, 2010 елда Иваново зиратында әти фамилиясе тора иде инде. Барып күрдек.

Тик... Миңа бу сәер тоелды. Күз буяу өчен генә язып куелган төсле. Янә әтинең сугышчан юлын эзләргә керештем. Новгород өлкәсе Боровичи шәһәрендә җирләнгән кешеләр арасында да әтинең фамилиясе бар. Озак уйлап тормадык, Боровичига киттек. Кечкенә шәһәр булуына карамастан, анда 7–8 госпиталь булган. Әллә ничә мең солдат шунда җирләнгән. Әтинең исеме госпитальдә вафат булган кешеләр арасында бар, ә зиратта юк. Шуннан архив документларын яңадан өйрәнә торгач, әтинең Боровичидагы башка зиратка күмелгәнлеге ачыкланды...

Мин хәбәрсез югалган шактый кешене эзләдем, берничәсен таптым да. Бер генә фикер әйтәм: анда шулкадәр күп буталчыклар... Кеше исемнәрендәге хаталарны әйтмим дә. Күп вакыт, тикшереп тә тормыйча, кабергә бөтенләй икенче кешеләр исемен язып куйганнар.

«ТУФРАК КҮМГӘН ТАРИХНЫ КУЗГАТМАГЫЗ!»

Әнәс Хәбибрахманов, Марий Эл Республикасы, Морки районы:

– Әниемнең әтисе Яппаров Каюм сугышка 1942 елда, Мари АССРның Морки районы Туранча авылыннан алына. Авылда бригадир булып эшли ул, җирле депутат итеп тә сайлана. Каюм бабайның өйдә хатыны һәм өч кызы кала. Берничә ай үткәч, фронттан «Хәбәрсез югалды» дигән хәбәр килә. Бабай турында башка бер генә хәбәр дә булмый.

Әнием Гөлсирәгә, әтисе сугышка киткәндә, 10 яшь була. Бала чагының иң якты хатирәсе – әтиле чагы. Бабай кызларын бик яраткан. Акыллы, тырыш кеше булган ул. Әби исә, кызларын кияүгә сорарга килгәч тә: «Әтиләре кайтса, аның рөхсәтеннән башка гына кияүгә биргәнгә, ачуланмасмы икән», – дия торган булган. Әйе, әби гомере буе бабайны көтте. Кияүгә чыгарга сорап килүчеләр дә булган. «Исән ирем була торып нинди кияү?!»– дип кырт кискән. Әбиебез 86 яшенә җитеп дөнья куйды.

Азрак үсеп буй җиткәч, бабайның сугышчан юлын эзләп карыйсы килде. Тик әбиебез кискен каршы төште. Белмим, әллә бер-бер нәрсәдән шикләнде, әллә аңа шулай хыялларында, өмет белән яшисе җиңелрәк идеме... Әби вафатыннан соң әни дә: «Туфрак күмгән тарихны кузгатмагыз», – диде.

СУГЫШ КИЧКӘН «ӘЛМӘНДӘР КАРТ»

Мин аның хәтта исемен дә белми идем, «бабай», бетте-китте. Авылның башка балалары да аны һәрчак «бабай» дип йөртте. Юк, өлкән яшьтә булганы өчен генә түгел, ә үз иткәнгә, яратканга күрә... Ә ул бик теләп һәр бала-чагага «бабай» була, алар белән сөйләшә, көлдерә, күчтәнәчләрен бирә. Тик сугыш турында куркыныч хатирәләрен беркайчан да сөйләмәс. «Без дошманны җиңдек, сез дә көчле булыгыз!» – елмаеп, шулай гына дияр. Югыйсә аның тарих сандыгында нинди генә хатирәләр юк...

Сүзем – Апас районы Шәмбалыкчы авылының сугыш ветераны Рәфкать Мадышев турында.

Автор:
Руфия Фазылова

«ФӘХРИ АБЫЙНЫҢ ДӘВАМЧЫСЫ»

Бабай белән танышуым болай булды: Шәмбалыкчыга туганнарга кунакка барып йөри идем. Берсендә көтү кайткач, урамга чыктык. Тау астыннан моңлы тавыш ишетелә – «Карурман»ны җырлыйлар. Ике туган сеңлем Алинә: «Бабай чыккан, әйдә, тизрәк», – диде. Тау астына йөгердек. Түшсәк, җыйнак кына йорт каршысында бер бик сөйкемле карт утыра. Җырыннан бүленми генә, безгә карап елмайды. Ә аннан, елмаеп-көлеп: «И, кунак кызы да бар икән», – диде.

Шул көннән башлап бабай якын кешемә әйләнде. Рәхәт кеше иде ул: бакчасында яңа өлгергән җиләк-җимешне өзеп ашата, тәмле кәрәзле бал белән сыйлый, ә аңардагы истәлекләр! Аның кебек тәмләп сөйләүче тагын бармы икән? Тавыш тоннарын төрләндереп, әле куркыта, әле көлдерә. Без авызыбызны зур итеп ачып тын да алмыйча утырабыз... Шәмбалыкчыга барсам, бабай янына керми калмый идем.

Тукта, ни өчен үткән заманда язам: бабай исән бит. Дөрес, берничә ел инде үзен күргәнем юк. Шәмбалыкчыга да сирәк барыла, хәер, бабай да авылда җәен генә була. Менә инде бишенче кыш Рәфкать бабай Казанда – кызларында яши икән.

– Әти быел кисәк картайды, – дип каршы алды безне Фәридә апа. – Әле узган ел гына бүтән иде. Җәй буе ялгызы Шәмбалыкчыда яшәде. Быел, белмим, үзен генә калдырып китеп булмас. Аяклары көчкә йөртә. Сугышта алган яралары үзен сиздерә...

Дөресен әйтим, хәтеремдә Әлмәндәр карт образы кебек саклана торган бабаемны күргәч, каушап та калдым: бирешкән.

– Картлыктан да начары юк икән, – диде үзе дә. – Сугышны кичтем, ике хатынымны җирләдем. Ә картлык алар белән чагыштырганда да яманрак икән...

– И, бабай, әле хәтерең яхшы, аяк-кулларың йөри, – дим.

– И, кызым, минме икән бу дип утырам кайчакта...

Шуннан бабай белән Шәмбалыкчыга «кайтып килдек»: болында ул утырткан агач-куаклар инде үскәндер. Ә менә теге кечкенә инеш ничек икән, аны чистартып торучы бармы, томаланмаганмы...

– Узган ел капка төбеннән ерак китә алмадым, – дип көрсенде бабай. – Быел да туган авылыма бик кайтасым килә. Шәмбалыкчыда аякларым да әйбәтрәк йөри башлар иде кебек.

– Бабай, әйдә элеккеге кебек җырла әле, – дим.

Бабаем башта сабый бала кебек каушап калды, аннан тамагын кырып:

– «Эшче» операсыннан «Нигъмәт» ариясе, – дип, җыр сузды.

– Әтинең Казанда бер тапкыр да җырлаганы юк иде, – диде Фәридә апа. – Күрәсең, сезне чынлап та үз итә. Әнә, җырлый да, елый да...

Бабайның тавышы кечкенәдән моңлы булган. Гаҗәп түгел, нәселләрендә атаклы җырчы бар – Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Фәхри Насретдинов. Ул Рәфкать бабайның әнисенең бертуган энесе.

– Фәхри абый мине бик якын күрде, – дип сөйләде бабай. – Опера җырларга өйрәтте. Кунакка барсак: «Фәхри абыйның дәвамчысы», – дип таныштыралар иде. Минем җырлаганны берничә тапкыр Мәскәү каналларыннан да күрсәттеләр.

Фото: Лилиана Вәлитова

«ҮЛЕП ТӘ БУЛМЫЙ, ТЕРЕЛЕП ТӘ...»

Рәфкать бабайның сугышта катнашканын ишетеп беләм. Тик бу хакта иркенләп сөйләшкәнебез юк иде. Белмим, әллә без кызыксынмадык, әллә бабай үзе моңа әһәмият бирмәде. Кыскасы, бу очрашуда бабайны көр күңелле, юмарт, тормыш яратучы кеше булудан тыш, батыр йөрәкле һәм «күлмәктән туган» булуына инандым.

Сугышка унсигезе тулгач алына ул. Башта Мәскәү янында махсус курсларда укый. Аннан сержант исеме алып, Белоруссиягә – Үзәк фронтка җибәрелә. Смоленск янында барган сугышларда сул аягы яралана. Өч ай госпитальдә яткырганнан соң, аны яңадан фронтка җибәрәләр. Кабат яралана, тагын шул ук сул аяк. Беренчесендә ядрә аякның табанына тисә, икенчесендә бот башын сызып үтә. Янә берничә ай дәваланганнан соң, яшь егетне разведчиклар курсларына җибәрәләр.

– Ике мәртәбә «тел алганым» булды, – дип сөйләде бабай. – Аннан кайткач, бер ай ял бирәләр. Ял дигәч тә, син барыбер тик ятмыйсың: разведкага әзерләнәсең. Картаны, мәйданны өйрәнәсең. Бу шулкадәр мавыктыргыч, азарт бирә торган эш ки, хәтта сугыш турында онытасың. Максат бары бер генә – фашистны ачыклау.

Сөйләгәндә кызык тоелса да, ул бик куркыныч эш: разведкага төркемләп китеп, үлеп калучылар да күп була. Хәер, бабай үзе дә үлем белән күзгә-күз очрашкан.

– Гомерең бетмәсә, үлем гел янәшә йөреп тә, исән каласың икән ул, – ди бабай. – Һич онытасым юк: бер-бер артлы җирдән шуышып барабыз, шулвакыт каршы яктан ут ачтылар. Синең белән янәшә барган кешенең күз ачып йомганчы шинельләре күккә оча. Нәрсә булачагын белеп дә белми: күзеңне йомасың да үлем көтәсең. Шарт-шорт. Менә хәзер, шушы секундта юк булам, дисең. Тик... ун минутлап синең якка таба ут ачып торсалар да, адәм баласы үлми кала ала икән. Гомере бетмәсә...

Шул засада вакытында пуля Рәфкать бабайның эченә тия. Авыртудан, күп кан китүдән яшь разведчик аңын җуя.

– Андый вакытта бер-береңне калдырырга ярамый иде, – ди бабай. – Яраны бәйләгәннәр дә, мине якындагы госпитальгә җибәргәннәр. Бер тәүлек аңга килмәгәч, «Үлем палатасына» керткәннәр. (Ягъни әле йөрәге тибә, ләкин хәле бик авырлар янына. – Авт.) Мин ул вакытларны төш кебек кенә хәтерлим: азрак аңга килеп күзләремне ачам да янә сүнәм. Өч көннән соң тәмам аңга килдем. «Бу яшәргә җан талаша бит», – дип, миңа операция ясадылар. Туры эчәклекне кисеп, икенче юлга тоташтырганнар. Кече, олы йомышны да клизма белән генә чыга торган булдым. Шуннан мине Ленинград шәһәрендәге хәрби госпитальгә җибәрделәр. Анда унике тапкыр операция ясадылар. Үлеп тә булмый, терелеп тә...

Бабай күз яшьләрен сөртте. Аннан дәвам итте:

– Ул вакытта мин Ходайдан бары үлем сорадым. Авыртудан, каткат туналудан шулкадәр туйдым. Этләрдә дә өч-дүрт тапкыр гына тикшерү үткәрәләр икән. Ә мине уникe тапкыр ярдылар. Кисәләр дә ялгыйлар, ялгыйлар да кисәләр. Тагын үзара киңәшәләр, тагын... Инде сугыш та бетте, ә мин һаман ярты җан булып госпитальдә ятам...

БӘХЕТ БЕЛӘН БӘХЕТСЕЗЛЕК – ЯНӘШӘ...

1947 елның декабрь аенда Рәфкать бабай «Табиблар ярдәменнән баш тартам» дигән язу калдырып, туган ягына кайтып китә. «Читтә үлгәнче, туган туфрагымда күмелим», – ди. Бер ел бернәрсә эшли алмый, кая ул, үзен йөртергә дә кыен була хәтта. Аягына яхшылап баса алмый, өстәвенә алар сызлап интектерә. Кече, олы йомышларын да кешечә үти алмый – эчәклекләре дөрес эшләми. Шуңа күрә өйләнергә дә ашыкмый. Сугышка киткәнче очрашып йөргән кызы да була югыйсә. Ул бүтән егеткә кияүгә чыгып куя.

– Мин кайткач, әни шатлыгыннан нишләргә белмәде, – дип, хатирәләре белән бүлеште Рәфкать бабай. – Әни хакына булса да яшәргә кирәк дидем. Тән сызлануы басылмаса да, җан сызлануы басылды. Әллә әниемнең кайгыртуы, әллә туган як һавасы килеште, кәефем көннән-көн яхшырды. Үзлегемнән акрын гына физик күнегүләр ясый башладым. Казан табибларына барып күрендем. Шул чордагы меңләгән башка кешеләр кебек яңадан яшәргә өйрәндем.

Рәфкать бабай шулай өйдәге вак-төяк эшләргә алына. Үзе әйткәнчә: «Үлем көтеп тик ятып булмый бит!» Соңрак колхоз эшенә дә чакырып киләләр. Гомере барлыгына ышанмаган егет хәтта өйләнә дә.

– Кем уйлаган, өч бала атасы булырмын, йорт салырмын дип, – ди бабай. – Фәүзия белән 37 ел яшәдек. Бик чибәр иде ул: озын зифа буйлы, куе кара чәчле, зәңгәр күзле. Хәер, гомергә акыллы, чибәр кызларга гына күз аттым. Булачак хатыным Яшел Үзән районының Мулла Иле авылында укытучы иде. «Эшемне ташлыйсым килми», – дигәч, аның янына үзем күченеп килдем. Ул вакытта миңа 32 яшь тулган иде. Безнең Шәмбалыкчы кечкенә авыл бит, ә Мулла Иле зур, шәһәргә дә якынрак.

Рәфкать Мадышев сугыштагы батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз һәм III дәрәҗә Дан орденнары, шулай ук күпләгән медальләр белән бүләкләнә.


Бабайның алмагачы өч төрле алма бирә.

Рәфкать бабайның сөйкемле сөяге бар шул. Мулла Илендә дә ул авыл кешеләре белән уртак телне тиз таба. Кул эшен белгәнгә күрә, тәрәзә рамнары ясарга керешә. Һәм үз эшенең остасына әйләнә. Шуннан кергән акчага йорт та сала, өч баланы да үстерәләр. Тик балаларны үстереп, олыгаеп барган бер мәлдә бабай яраткан хатынын югалта:

– Фәүзия кисәк авырып дөнья куйды. Еладым да, җырладым да, – ди Рәфкать бабай. – Ялгызлыкны яратмыйм. 67 яшемдә яңадан өйләнергә булдым. Балалар каршы килмәде. Тик икенче хатын белән ике генә ел тордык, аерылыштык. Минем балаларны яратмады. Һәм 73 яшьтә тагын өйләндем. Әлфия исемле, кияүгә чыкмаган, миннән сигез яшькә яшьрәк, бик акыллы, булган хатын иде. Тормышым янәдән яктырып киткәндәй булды. Әйтәм ич, ялгызлыктан да авыррак нәрсә юк. Әлфия, беренче хатыным кебек, аш-суга да уңган, сабыр да булды. Балалар да үз итте аны, гел кайтып йөрделәр. Тик ун гына ел яшәп калдык, 2006 елда үлеп китте...

Рәфкать бабай утырткан чыршы-наратлар.

Бабайның бүген бердәнбер хыялы – туган авылы Шәмбалыкчысындагы йортына кайтып, капка төбенә чыгып, «Карурман»ны җырлау.

– Бөек Ватан сугышы совет халкының күзен ачты. Яшәр өчен үзенә бер сабак та булды. Әйе, яшь гомерләр, беткән сәламәтлекләр кызганыч. Безнең буын тормышның ямен күрергә өйрәнде. Хәзерге яшьләр тормышның кадерен аңлап бетерми. Көн дә телевизор карыйм, сугыш барган илләрне күреп бик борчылам. Илләр тыныч булсын, дип телим. Тынычлыкка ни җитә! Моны бездән дә артык белүче юк.

БҮРЕНЕ БҮРЕККӘ САЛСАҢ ДА...

– Әти гаҗәеп кеше, – дип сүзгә кушылды Фәридә апа. – Аңардагы энергия бер кеше гомеренә генә аз. Белмәгән нәрсәсе юк. Үл үләннәрне кайчан җыясын, ничек эчәсен белә. Безне дә өйрәтеп бетерде: кара чәй эчмибез. Ел буена җитәрлек үләннәр җыеп куябыз. Әти беркайчан тәмәке тартмады, аракы эчү белән мавыкмады. Кешеләр турында начар сөйләмәде, мөгаен, озын гомерле булуының сере шулдыр...

Рәфкать бабай туган авылы Шәмбалыкчыда, үзләренең бакча башына, елга буйларына йөз егерме төп чыршы-нарат утырткан. Алар бүген үсеп, посадка хасил иткән. Ә бакчасында өч төрле алма бирә торган алмагачы бар. Тагын бабай чын умартачы да икән әле. Бал кортлары турында әллә ниләр белә. Кортлар кышын исән чыктылармы икән, дип кайгырып утыра икән.

– Узган ел кортларым өч оя гына калган иде, – диде бабай. – Аларга зур игътибар кирәк шул, картайдым. Дистә еллар умартачы булып, ике тапкыр гына кортлар чыгып качты. Ана кортның оядан кайчан китәсен алдан белеп тора идем. Махсус кечкенә оялар ясыйм да, бакчадагы агач башларына менгереп куям. Яшь оя еракка очып китми – агачта гына кала.

– Бүрене бүреккә салсаң да, урманга карый, – дип, халык әйтемен искә төшерде Фәридә апа. – Әти көннәр буе авылны сагынып утыра. Югыйсә монда да рәхәт, ике бүлмәле иркен фатир. Бик тәрбияләргә тырышам үзен, эштән дә киттем. Тынгысыз кеше ул, тик ятарга өйрәнмәгән. Бер хәл сөйлим әле. Моннан берничә ел элек әти ялгызы капка баганасын җирдән күтәреп алып, икенче җиргә күчергән. Авылдашлар шалтыратып әйтте: «Бабайның бүсере кузгалды», – диләр. Тиз генә кайтып, Казанга алып килдек. Табиблар кырт кисте: «Операция ясамыйбыз, 87 яшьлек кеше өчен бик катлаулы». Ә әти сүзендә нык торды: «Урыннан да кузгала алмыйча, гарип булып яшәмим. Үземдә көч тоям, үлмим, борчылмагыз», – диде. Чынлап та, операция уңышлы булды, дүрт көннән әтиебез өйгә дә кайтып җитте.

Бабайның бүген бердәнбер хыялы – туган авылы Шәмбалыкчысына кайтып, капка төбенә чыгып утырып, «Карурман»ны җырлау.

– Авылда тавышым да ачылыр кебек, кызым. Казанда тыным кысыла минем.

Саубуллашканда бабай, күз яшьләрен сөртеп, кулымны кысты:

– Исән булсам, әйдә, җәйгә кил әле. Элеккеге кебек капка төбендә утырыйк. Сез алма ашарсыз, мин җырлармын...

PRESSA.RU

ТӨНГЕ БОМБАРДИРОВЩИКНЫҢ СОҢГЫ СУГЫШЫ

Өч ел элек «Татарстан» үткән гасырның бәһасез раритетын эзләп тапты. Казу эшләренең кирәге чыкмады: дөньяның теләсә кайсы авиация музее өчен хыял гына булган самолёт-легенда – У-2 – Милли музейның калын диварлары эчендә үк табылды. Әмма иртә сөенгәнбез: төнге бомбардировщик вакыт тарафыннан шактый гына таушалган икән. Гомерен запасникларда чикләргә язганмы әллә үзенә? Оптимистик планыбыз техник ядкарьне торгызу һәм халык алдына чыгару иде...

Автор:
Әскәр Сабиров

Ул чакта мин энтузиастлар, махсус белгечләр һәм спонсорлар ярдәмендә самолётны тиз арада тормышка кайтару мөмкинлегенә һәм аны тагын бер мәртәбә туристлар агылачак урынга әверелдереп булачагына һич кенә дә шикләнмәдем. Ни дисәң дә, Казан – илдә дә бармак белән генә санарлык уникаль экспонатларны санламый торган шәһәр түгел бит. Ә инде Казандагы У-2 самолётының, чыннан да, тарихи кыйммәткә ия раритет булуында һичбер шик юк.

Искә төшереп үтәм: һавага беренче тапкыр данлыклы Михаил Громов тарафыннан күтәрелгән һәм кайчандыр массачыл рәвештә җитештерелгән әлеге самолёт бүгенге көндә илебездә берничә данәдә генә сакланып калган. Берсе – Мәскәү янындагы Монинода, авиация музеенда. Икенчесе – 30 нчы елларда Төньяк полюс аша батырларча очыш ясаган Валерий Чкаловка бүләк ителгәне – Түбән Новгород өлкәсендә. Тагын берсе – 80 нче елларда зур саклык белән кабат торгызылганы – Ульяновскида, гражданлык авиациясе музеенда. Һәм менә, ниһаять, безнеке, Казандагысы...

УНБЕР МЕҢНЕҢ БЕРСЕ

Совет заманында У-2 (По-2) Казан музее экспозициясенең бизәге саналган. Хәтта бизәге генә дә түгел – тартып тору үзәге, бигрәк тә малайларны. Элек авиация техникы булган, хәзер һәвәскәр пилот һәм үзбелемле авиаконструктор Ирек Вилданов, кайчандыр, монда куелган бипланны күрер өчен, Казанга Яр Чаллыдан махсус килә идем, ди әнә. Безгә, Казан малайларына, еракка барасы юк – классташлар белән безнең өчен бик кадерле булган экспонатны тагын бер күрер

Фотолар: «Татарстан» журналы архивыннан

Фото: www.airpages.ru

өчен музейга әллә ничә мәртәбә килдек! Сугышчан самолёт бит ул, винты да, двигателе дә чын, сугыш күргән! Караучы апа сизмәмешкә салышканда, без яшеренеп кенә аның канатына һәм фюзеляжына да кагылып алабыз. Машинага кагылып карау һичшиксез кирәк иде. Мөмкин булмаган хәлгә ышанасы килүдән: фанерадан, рейкалардан һәм тукыма тарттырылып җыелган бу йомшак конструкциянең чыннан да тәннәрен фашистларның котын алучы хәрби самолёт икәнлегенә ышанар өчен.

Узган гасырның беренче яртысында ук очкан машина теләсә кайсы илдә алтын бәясенә йөри. Нинди дә булса чит ил авиация музее, мөгаен, уникаль экземпляр өчен бик теләп берничә йөз мең долларын чыгарып салыр иде. Хәер, әлеге У-2 самолётының Татарстан өчен кыйммәтен валюта белән үлчәп булмас. Музей экспонаты гына түгел – безнең тарихыбызның бер өлеше бит ул. Бу – 387нче Казан авиация (хәзер – вертолёт) заводында сугыш елларында чыгарылган унбер мең У-2нең берсе.

Яшүсмерләр һәм хатын-кызлар салкын цехларда, ярымач килеш, сугыш елларында мондый машиналарны аена 350 данәгә кадәр җыйган. Ә без хәтта шул берданберне дә яңадан торгыза алмыйбызмыни? Бу сорауны без моннан өч ел элек, самолёт-легендага бердәм көч белән яңа сулыш өрергә чакырып, үзебезнең укучыларыбызга биргән идек. Билгеле инде, беренче чиратта У-2нең «тудыручылары» – Казан вертолёт заводының ярдәменә өмет иттек.

БЕЗНЕҢ БЕЛЕШМӘ

У-2 (По-2) очкычы авиаконструктор Николай Поликарпов төркеме тарафыннан 1928 елда эшләнеп, 1953 елга кадәр чыгарылган. Бөек Ватан сугышы елларында ул төнге бомбардировщик, самолёт-разведчик буларак һәм санитар авиациясендә кулланылган. 350 килограммга кадәр бомба йөртә алган. Җиңел бипланны немецлар «кофе тегермәне», «тегү машинасы», «рус фанерасы» дип атап йөрткәннәр, әмма шул ук вакытта акрын очкычны (сәгатенә 150 км) бәреп төшерә алучы Тимер тәре белән бүләкләнгән. У-2дә танылган Тамань гвардия авиаполкы очучы кызлары сугышкан. Аларның 23е Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган, ул исемлектә безнең якташыбыз Мәгубә Сыртланова да бар. У-2 самолётларын җитештерү сугыш елларында Казандагы 387 нче заводта (хәзер – Казан вертолёт заводы) оештырылган. Ай саен биредә 350 гә кадәр машина җыелган.

ТЫНЫЧ ВАКЫТНЫҢ ТИШЕК-ТОШЫКЛАРЫ

«Без күптән уникаль экспонатны кешеләр алдына чыгарырга хыялланабыз, әмма аны реставрацияләү өчен акча табарга тырышуларыбыз бернинди нәтиҗә бирмәде, – ТР Милли музееның генераль директоры Гөлчәчәк Нәҗипованың безнең мәкаләгә җавабы әнә шундый булды. – Акча һәм У-2не торгызырга сәләтле белгечләр булса, тиешле булган барлык рәсми якларын хәл итәр идек...» Җитәкче сүзләренә караганда, реставрация эшләренең моннан берничә ел элек үк белгечләр тарафыннан әзерләнгән сметасы да бар икән.

Тагын бер атнадан вертолёт заводы үзенең шундый ук аңлаешлы реакциясен белдерде: «үз баласын» бәладә калдырмаячак. КВЗның матбугат хезмәткәре, редакция белән бәйләнешкә кереп, шундый хәбәр җиткерде: предприятиенең генераль директоры (ул чакта Вадим Лигай – ред. иск.) реставрацияне хуплаган. Ә инде тагын бер атна

үтүгә без инде КВЗның музейга командировкага җибәрелгән ике белгече белән бергәләп У-2нең фюзеляжында һәм канатларында вакыт калдырган тишек-тошыкларны өйрәнергә керештек.

Белгечләр яшереп тормады: монда эш – хәттин ашкан. Музейчылар сак кына кисәтеп куйдылар: бу гади машина гына түгел, кыйммәтле экспонат, реставрация махсус кагыйдәләр нигезендә алып барылырга тиеш... Әмма бөтен шикшөбһәләр гомуми ышаныч янында эреп юкка чыкты: озакламый яңадан туган У-2не теләгән һәркем күрә алачак. Әлегә потенциаль реставраторлар яшәртү процессы үткәреләсе завод мәйданына фюзеляжны ничек күчерү турында сөйләшкәндә, без инде музей хезмәткәрләре белән бергә, самолёт-легенданы куюө өчен аеруча отышлы урыннарны, барлап, якын киләчәкнең күркәм манзарасын күзалладык. Вариантларның берсе буенча бипланны нәкъ парад баскычы турысында түшәм астына урнаштыру каралган иде. Икенчесендә – музей ишегалдында, пыяла астында...

Якын киләчәк барып чыкмады. У-2не реставрацияләү мәсьәләсен карагач, берничә көннән соң, вертолётчылар шундый хәбәр бирде: бу эшкә тотынмаячаклар, башка эшләр дә бик күп... Сәбәпләрен беренче заттан ишетергә тырышуыбыз да бернинди файда бирмәде – ул чакта Вадим Александровичка телефон аша элəгү мөмкин булмады.

Сәнәгатьнең башка «китлары» да музейдагы У-2не коткарырга теләк белдермәде.

ХӘТЕРНЕ ЮГАЛТУ

Бүгенге көндә элементларга таркатылган У-2 – фюзеляжы аерым, канатлары аерым, тәгәрмәчләре аерым – элеккечә үк музей запасникларында тыныч кына тузып ята. Белмәүчеләр өчен мәгълүмат: ул экспозициядән инде бик күптән, Советлар Союзы таркалганчыга кадәр үк юкка чыккан. Тиз арада дәвалау таләп ителгәнгә күрә, акрын очкыч күз алдыннан вакытлыча алынган булган. «Реставрация» хәзергәчә «дәвам итә», югыйсә безнең музей раритеты турында берни белмәгән малайларның яңа буыннары үсеп җитте инде.

Музейчыларны гаепләргә кирәкми, аларның финанс ягыннан хәлләре нindiрәк икәнен һәркем белә. Моннан тыш, югары дәрәҗәдәге түрәләргә ишеттерергә һәм реставрациягә акча табарга өметләнеп, алар ничәмә тапкырлар чаң кагып карадылар.

2002 елда, Казанга ул чактагы мәдәният министры Михаил Швыдкой килгән чакта, аңа тиз арада ярдәм таләп ителгән ике уникаль экспонатны күрсәткәннәр – Екатерина патша заманындагы каретаны һәм У-2 самолетын. Каретага акча табылган, ә легендар биплан, күрәсең, министрга тәэсир итмәгән...

Ни гаҗәп, реаль тарихның үлеп баруын битараф кына күзәткән хәлдә, без ул сугышны хәтеребездә мәңге саклаячагыбызга ихлас ышанабыз. Бинихая зур корылмаларга һәм мемориалларга акча табабыз. Ә Чын Хәтерне югалтабыз. Уйлап карасаң, 1945 елда Казанда төзелгән, ни ядрәләрдән, ни ярчыклардан саклый алмаган «броня»лы У-2 ул сугыш турында, кайбер дәреслек параграфларына һәм гранит мемориалларга караганда, шактый күпне сөйли алыр иде!

Безнең, гомуми көчләрне берләштереп, самолёт-легенданы торгызырга тырышуыбызның барып чыкмавы, язмыш көлүе булдымы – нәкъ Җиңүнең 70 еллыгына туры килде. Шушы елда Казанның Җиңү паркында яңа буяулары белән балкып торган У-2 – чын У-2нең начар күчермәсе пәйда булды. Бу макетны, байтак акчаларын һәм көчләрен сарыф итеп, вертолёт заводы «гамәлгә кертте», диләр... Мөгаен, мондый макетлар да бик кирәктер. Ә миңа калса, бу табибның, чын авыруга ярдәм итмичә, манекенны дәваларга керешүе кебегрәк күренеш...

ӘЙДӘГЕЗ, ОЧЫЙК!

Мин элеккечә үк ышанып әйтәм: безнең аны югалтырга хакыбыз юк! Бәһасен бернинди акчалар белән исәпләп булмый торган уникаль самолёт тормышка кайтырга тиеш! Һәм бүген «поликарпов»ны гомуми көчләр белән торгызырга ышаныч, өч ел элеккегә караганда, зуррак та әле. Беренчедән, безнең Татарстанда тарихи һәйкәлләрне торгызу өчен спонсор акчаларын җәлеп итүнең бай тәҗрибәсе бар. Әгәр дә «Яңарыш» фонды, бәһасе изге архитектура урыннарыннан һич ким булмаган бу тарихи раритетны да үз карамагына алса, ничек яхшы булыр иде.

Икенчедән, бездә уникаль реликвияләрне саклауны буш сүз түгел, намус эше итеп санаган никадәр предприятие бар! Әйтик, «Татнефть» һәм «Зенит» банкы. Мин нәкъ менә аларның өч ел элек Франциядәге экспозициясенә хәрби Як-3 самолёты да куелган «Нормандия-Неман» дивизиясе музеен торгызуга байтак акча кертүләре турында белдем. Парижда, музей ачылышында, «Татнефть» компаниясенең генераль директоры Наил Маганов Россия телеканалына мондый ин-

PRESSA.RU

тервью биргән: «Безнең бурычыбыз һәм вазыйфабыз – бу тарихи дөреслекне киләсе буыннарга җиткерү. Ә моның өчен бүгенге көндә яшәүче аз санлы ветераннарның тере истәлекләрен, реликвияләрен сакларга, һәм безнең, бөек халыкның, Җиңү өчен эшләгәнебезнең үз рухын кадерләргә кирәк».

Казанның У-2 самолеты – нәкъ шул реликвияләрнең берсе, һәм аңа юл, Париж музеена караганда күпкә якынрак, димәк, бу изге эштә ярдәм өмет итәргә безнең тулы хакыбыз бар. Без мәңге шулай, янәшәдәгене күрмичә, үз йортыбыздан ерак җирләрдә генә изге эшләр эшләп йөрмәбездер бит? Шунысы ачык: самолётны торгызу өчен акча табу – мөмкин хәл. Минимум бурыч – У-2 музей залында яңадан үз урынын алсын өчен, аңа реставрация ясау. Максимум бурыч – самолётны кабат канатларына күтәрү. (Бездә ни өчендер, иске самолётларга реставрация ясаганда, аларны очу халәтенә җиткерү каралмаган, әмма чит илләрдә бу – гадәти күренеш – ред. иск.) Күз алдына китерегез: әгәр легендар биплан һавага күтәрелсә, ничек шәп булыр иде! Бу ветераннарга, аларның балаларына, оныкларына, оныкларының балаларына иң яхшы бүләк, миңа калса!

Фронт өчен У-2 самолётларын җыючылар әле дә исән, алар онытылган технологияләрне искә төшерерлек хәлдә. Энтузиастлар, табып алып, берничә машинаны яңадан төзегән сызымнар да сакланган. Шундый машиналарның берсен ике ел элек Ирек Вилданов һавага күтәргән. Моның өчен авиаконструктор-энтузиастка тау кадәр әдәбият актарырга һәм капшап диярлек онытылган процессларны торгызырга туры килгән. Аның самолёты авиация бәйрәмендә дә катнашкан инде. Бу – хәрби У-2нең 30 нчы еллардагы оригиналь двигательле төгәл күчермәсе! Вилданов музейдагы У-2не дә реставрацияли ала, билгеле инде, ярдәмчеләре һәм тиешле акчасы булганда. Безнең хәбәрчебез белән әңгәмәсендә Ирек тагын бер тапкыр раслады: ул эшкә иртәгәдән үк керешергә әзер – әйткәнемчә, акча гына булсын.

Аңлашыла инде, оригиналь машинаны торгызу, аның прототибын төзүгә караганда, күпкә катлаулырак. Әмма техник (авиация) университеты булган, берничә авиация ФТИ, КБ һәм предприятиеләре эшләп торган Татарстан өчен бу эш – булдыра алырлык бурыч. Бу хәтта бурыч та түгел – намус эше.

Шундый машиналарның берсен ике ел элек Ирек Вилданов һавага күтәргән. Моның өчен авиаконструктор-энтузиастка тау кадәр әдәбият актарырга һәм капшап диярлек онытылган процессларны торгызырга туры килгән.



АЛЫП КАЙТА АНЫ ЕЛЛАР БЕЗГӘ...

Француз шагыйре Шарль Бодлерның «Альбатрос» дип исемләнгән шигыре бар. Сюжеты бик гади: озын-озак диңгез сәфәрендә йончыган матрослар, эчпошыргыч көндәлек тормышларына аз гына булса да ямь, кәмит өстәр өчен, «диңгез киңлеге патшаларын» – горур һәм иркле кошларны – альбатросларны аулый. Тотып алгач, бу алагаем җан ияләрен палубага җибәрәләр дә олы канатларын кая куярга белми интегүче кошлардан рәхәтләнеп көләләр. Чөнки тегеләре нәрсәгәдер барып төртелә, нишләргә белми җәфалана, тәмам мәхлук хәленә төшә. Диңгез өстендәге һаваны ярып очарга күнеккән әлеге хөр кошлар тар палуба өчен яратылмаган чөнки. «Шагыйрь, синең дә хәлең шундый...» – дип тәмамлый соңгы строфасын Бодлер.

Автор:
Луиза Янсуар

«РОМАНТИКА – АДӘМНӘРНЕҢ ЙӨРӘК КАНАТЛАРЫ...»

Тукта, ни өчен әлеге юлларга мөрәҗәгать итәм соң? Француз әдәбиятында, аның да богемага караган категориясендә, «яманлык җырчысы» («певец зла») буларак дан казанган Шарль Бодлер монда нигә кирәк, диярсез. Һәм хаклы булырсыз. Бу урында үзебезнең Миргазиян Юныска сүз биреп, аның публицистикасына мөрәҗәгать итсәк, мөгаен, дөресрәк булыр. Хәер, ул безне барыбер дә шул ук Бодлерга алып барып тоташтырыр, югарыда искә алынган «Альбатрос» шигыренә. Чөнки нәкъ менә дөнья океанын, диңгезләрен кичкән, бу тормышның нинди икәнен үз күзләре белән күреп белгән Миргазиян Юныс шагыйрь Роберт Әхмәтҗановны Бодлер шигырендәге образга тиңли, аны «татар шигъриятенең альбатросы» дип атый. Ничәмә-ничә еллар диңгез флотында хезмәт иткән әдип бу чагыштыруны юкка гына кулланмагандыр, дип уйлыйм. Ул альбатросларны да үз күзләре белән күргән, ә аннан да бигрәк милли әдәбиятыбызны дөнья контекстында ваемлап бәяли, чагыштырып карый алгандыр, шөт. Роберт Әхмәтҗановның «канатлары» безнең офыкларга сыешмый икәнне тойганга язгандыр «Альбатрос язмышы» дип аталган мәкалә-эссесын да...

«Талант мохиткә җайлаша алмый. Сыймый аның офыклары көндәлек тормыштагы прагматиклар калыбына. Зур талант һәр әсәрен бәгыренең иң сизгер, иң әрнүле почмагыннан сыгып чыгара...

Альбатросның очканын күргән кеше бу күренешне мәңге оныта алмый. Кайвакыт без романтика турында сүз куертабыз, ә үзебез аның нәрсә икәнлеген күз алдына да китерә алмыйбыз. Альбатросның океан киңлеге өстендә зәңгәр күктә йөзгәнен күргән кешегә романтиканың нәрсә икәнлеген аңлатуның кирәге калмый...»

Кайчандыр, әле узган гасырның 70 нче елларында гына, Роберт Әхмәтҗанов «романтика – адәмнәрнең йөрәк канатлары» дип язган иде. Бу урында укучыда «романтика» төшенчәсенә бүген салынган беркатлы һәм шактый попса төсмерен алган мәгънә калкырга мөмкин: Инстаграмдагы яисә башка социаль челтәрләрдәге ваниль постлар, җиңел һәм рәхәт тормышка омтылу, гел сөешү-үбешүдән торган, фотосессияләрдә «баллы» чагылышы теркәлеп калган мәхәббәт... җилбәзәклекне алга сөрү. Әмма бу тамырдан ялгыш күзаллау. Бу прагматизмга корылган заманыбызның төшенчәләрне алыштырып уйнавына, аларны үзенә яраштырып, яңа тышчага төреп күрсәтүенә, спекуляциягә әверелгән күренеш кенә нибары. Бүгенге көндә «мин – романтик» дип күкрәк сугучыларның күбесе асылда прагматизм



Афзал Шамов
Татар Танае

Габдулла Тукай
Кушлавыч

«Татарстан» журналы инде ике ел дәвамында алып барган «Кече ватан патриотлары» проектының максаты – татарстанлыларны республикабызның исемнәре онытылыбрак барган талантлы шәхесләре, әдәбият-сәнгать әһелләре белән таныштыру.

«Татарстан» журналы республикада яшәүче халык арасында уздырган сораштырулар шуны күрсәтте: күпләр XX йөзнең күп кенә күренекле шәхесләрен инде онытып бара. Абдулла Алиш, Гаяз Исхакый, Шәйхи Маннур... хәтта әлеге исемнәрне ишеткәч тә «танылган кеше инде», «шундый урам бар», «кем дип әйтсәм дә читенсенәм...» кебек җаваплар алырга туры килде.

Янка Купала
Печищи

Туфан Миңнуллин
Мәрәтхуҗа

Фотолар: Луиза Янсуар, Балык Бистәсенең Туган якны өйрәнү музее архивыннан

«КЕЧЕ ВАТАН ПАТРИОТЛАРЫ» ПРОЕКТЫНЫҢ КАРТАСЫ



Проект кысаларында без Татарстан районнарына чыгабыз. Анда, кече ватанда, талантлы якташлары турындагы истәлекләрне кадерләп саклаучы кешеләр белән очрашып, күренекле шәхесләрне яңадан «кайтарабыз». Кайбер туристик маршрутларның шактый еракта булуына карамастан, барыбер барабыз. Музейлар, туган нигез, без язган шәхесләрне кайчандыр белгән җирле кешеләр – болар барысы да Татарстанның олы байлыгы.

категориясенә караучылардан гыйбарәт. Бигрәк тә – «романтик» блогерлар.

Роберт Әхмәтҗанов шигърияте безгә башка романтиканың барлыгына ишарә итә. Кешелек яратылганнан бирле аның тәүге асылына сусаудан барлыкка килгән романтиканың. Шуңа да аның шигырьләрендә Табигать күкрәген тутырып сулый, кош-кортлар, нәни бөҗәкләр, җәнлекләр үз табигый халәтендә яши. Ә кешеләр асылыннан китәрәк барган саен үз йөзен, төсен, үзен югалта. Роберт Әхмәтҗанов шигъриятендә Табигать безгә әнә шул югалткан асылыбыз турында сөйләр, хәер, юк, сөйләр генә түгел, ә чаң кагар өчен хезмәт итә. «Сарбай турында легенда» дип исемләнгән, жанрын билгеләү шактый зур кыенлык тудырган әсәрен генә алыйк:

...Очтың камыллы кырлар аша,
Үзең дә камыл төсендә –
күренмисең дә!..

...сикереп коймадан,
сары йомгактай,
очтың хуҗаң артыннан,
куып җиттең,
узып киттең –
гүләп торган
олы магистраль каршына!

Чакырдылар сине кирегә:
«Борыл болыныңа,
кайт яшел ишегалдыңа,
Сарбай!» – дип ялынды барысы да.

... Илләр гизәргә китүеңме
олы дөньяда,
кешедәй, күпне белеп?..
Имеш, син ятасың кайдадыр
гудрон юл читендә...
Ап-ак җаның
киткән... Айга менеп!
Моны беркем белдермәде,
сөйләмәде соңгы хәбәрләр,
сөйләмәде җилләр...
Иң кешелекле Сарбаем,
кайда син, җуләр?!

Кеше сүзен,
хуҗаң күңелен
күздән аңлый идең син, җаным!
Космик гасырда
кайбер бәндәләрдән
кешелеклерәк иде бит җаның...

Ә бит сүз, уйлана калсаң, бөтенләй дә Сарбай турында... дөресрәге дөньялыкның бер маэмае хакында бармый. Сүз инде космик гасырдан соңгы – виртуаль платформалар, роботлар, югары технологияләр камап алган, һәм үзләренең кайда башланып, кайда тәмамлануын ваемлаудан мәхрүм калган... адәми затлар турында бара.

PRESSA.RU

Беренче рәттә (сулдан уңга): Хәснул Вәлиуллин, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким; икенче рәттә (басып торалар): Роберт Әхмәтҗанов, Гамил Афзал.

Әнә шул романтика яши Роберт Әхмәтҗанов шигъриятендә. Үзеннән соң дуамалланып җилләп, давыллап килгән. Киләчәккә кисәтү булып – ул безне тамырларыбыздан аерылмаска чакыра. Чын шагыйрьләргә, зур шагыйрьләргә хас булганча самими бер гасабилык, каударлык белән. Анда XVIII–XIX гасырларда Европада пәйда булган, деистик Аллага каршы куелган пантеистик карашлар һәм дөньяны тойгылар, хиссият аша кабул итәргә өндәгән Тере Аллага инануны алга сөргән романтизм чаткылары очкынлана, бии. Аның аша, полифония булып, Новалис, Гельдерлин, Байрон, Шелли, Китс, Блейк, Стендаль, Жуковский, Лермонтов, Тютчевлар яңгырап тора. Романтик рәсем сәнгате буяуларыннан соң, Роберт Әхмәтҗанов шигърияте полотносына иртә һәм соңрак иҗат иткән импрессионистларның палитрасы килеп кушыла. Нотр-Дамны тәүлекнең төрле сәгатьләрендә армый-талмый киндеренә төшергән Моне кебек, ул да туган ягының табигатен шигырьләрендә берөзлексез сурәтли. Елның дүрт фасылында да, буяуларның һәм манзараның нюансларын үзгәртә-үзгәртә... Аңлашыла да, туган төбәк – кендек каны тамган урын, аңа мәңге көчкодрәт биреп тора торган җир, аның дөнья моделенә беренче штрихларын сызган «Улей»:

Авылым –
Арышым,
син минем Парижым!
Үрләр аша миңа үреләсең,
солы кырларыннан карыйсың.
Карабодай тулы төклетура,
бәбәкләре зеңли ясмыкның.

Шул уйларда ничә көзгә кердем,
шул хис белән ничә яз чыктым!
Каенстан!
Урман башыннан ук күренәсең –
йөрәгемә матур утырган!
Әнә синең яңгыр басмаларың,
урамнарың –
минем Нотр-Дам!

Әнә зәңгәр инешең, шатлыгыннан
ташларына чаклы яктырган!
Авылым,
күтәреп куй хәтер пәрдәләрең,-
сагыну җиле иссен үрләрдән...
Алып китә мине еллар синнән,
суларында кала күләгәм...

Инешеңә иелеп, кояш белән
чәчен юа синең талларың.
Еллар аша күренә: шундый биек
күтәрелер икән таңнарың!..
Еллар аша күрәм кояшының
Камылларда чәчрәп янганын.
...Тау артыннан ишетәм туган якта
әрекмәнгә
тамчы
тамганын!

Роберт Әхмәтҗанның шигырь стиле хакында «күбәләкле» дип әйтәсем килә. Эчендә күбәләк тырпылдаган сыман тоелган тере җөмләләргә юлыкканың бармы? Булса, чын шигырьгә юлыккансың, димәк! Ә чын шигырьгә юлыгу – сүз һәм хис кадерен белгән кеше өчен асыл бәхет ул. Яшерен-батырын түгел, инде ничә буын шагыйрьләре Роберт Әхмәтҗанның сүз куәтен, сүз сөрешен тоеп, аңардан өйрәнеп, шигърият күгенә күтәрелде.

Зөлфәт, шагыйрь, 2001 ел.

САРЫ КРУЖКА ҺӘМ БАХНЫҢ ХОРАЛЫ

Бу шагыйрьдә мине иң гаҗәпләндергәне – Европа һәм Көнчыгышның икесен үзендә бердәй эретеп укмаштырган гаҗәеп югары дәрәҗәдәге эстетика. Юкса, ни күргән ул үскәндә шул туган басу-кырларыннан, инешеннән, үрләреннән, каенлыкларыннан башка? «Тау артыннан» дигәне дә – калкулыктан узмый лабаса... Парижның исе дә килми без барып чыккан Иске Арышта. Тирес чүмәләләрен, барыбызның да авылларындагыча, гадәти рәвештә, брезент белән каплап куйганнар. Яз килеп җитә алмаган тайгак юллардан чанага җигелгән атлар уфлап йөгән өстери. Җилдерер өчен яратылмаган аларның бәкәлләре дә, авыр йөк атлары бу. Үзләренең ферма белән ихата арасында гомер сөрәчәкләрен анык тоюларын күзләрендәге моңсу сирпелештән «укып алырга» мөмкин.

Ничек шундый шагыйрь ярала алган бу туфракта?! Әлеге сорауга җавапны, бәлки, мәңге дә таба алмам. Әмма эзләвемне дәвам итәм... Дәвам итәм, чөнки ул миңа тынгы бирми. Чөнки миңа җавап табарга берәү дә ярдәм итми. Ни туган-тумачасы, ни замандашлары, ни якташлары... Кабат шигъриятенә кайтып капланырга гына кала. Ә анда инде тоташтан Идел-Йорт, Татар Иле җәйрәп ята:

Мин кая барам?
Кояш чыгышыннан
баешына чаклымы?
Мин тик бер кунакмы?
Җирем нинди –
күксел туфракмы,
акмы?

Кемгә таянам?

Минем моңнарны үзенә кундырган –
тигәнәкме,
алтын куакмы?

Еракмы синең үткәнеңә?
Көткәнең нинди?
Кем нигезләре кемнәргә калмый,
уралмый утка кемнәр тәхете,
кемнәр бәхете...
Кем ярларын кемнәр кочмый?
Нинди кошлар
очмый кыйблага?..
Синең йөзне күрдем елгада.
Баш очында Итил-су ага...

Мәскәүдә Татар әдәбияты көннәрендә.

Балык Бистәсенең Туган якны өйрәнү музеенда безне көткәннәр иде. Әмма килеп керешебезгә кысанлык өчен гафу үтенделәр: «Вакытлыча әлеге бинага урнаштырып тордылар, шуңа фондларның да барысын чыгармадык, күбесе җыеп куелган хәлдә ята...» Әмма Роберт Әхмәтҗановның фондын ачып, иң түрдә аңа багышланган стенд ясап куйганнар. «Фонд» дигән сүз күңелемә башта җылы йөгертсә дә, стендка якынрак килгәч, йөрәгем кысылып куйды. Киштәләрдә аның китаплары тезелешеп тора, кульязмалары, хатлары, юбилеена килгән телеграммалар таралып ята, менә аның фотосы, мактаулы бүләкләре барлыгын хәбәр итүче катыргылар, күкрәк билгеләре. Менә күзлеге, яраткан галстугы.

– Бездә тагын ике галстугы саклана, – дип, горурлык белән өстәп куя музей хезмәткәре Любовь Владимировна Ахунова.

Ә стендның иң түрендә Роберт Әхмәтҗанов шигъриятенең барлык күзәнәкләреннән саркылып торган кояш кебек, сап-сары, «Липтон» язулы кружка балкып утыра. Бу кружкадан шагыйрь чәй эчәргә яраткан...

Гаҗәпләндерде дә, сискәндерде дә ул мине. Акция буенча чәй тартмасы белән бергә сатыла торган гадәти, күпчелек өйләрдә очратырга мөмкин предмет булуы беләнме икән? «Безнең апа бәрәңге ашый икән бит?!» – дип гаҗәпләнгән үсмерләрчә, мин дә берара эстет Әхмәтҗановның тормышта шулкадәр гадәти нәрсәләрне үз итүенә аптырап тордым. Кинәт кенә миңа бу кружка, Тарковскийның «Солярис» фильмындагыча, Бахның хоралы астына һавада йөзә башлагандай тоелып куйды...

– Туганнары боларны безгә аның үлеменнән соң ук китереп тапшырды, – дип, чынбарлыкка кайтарды мине Любовь Владимировна. – Күрәсең, ул көндәлек тормышта бөтенләе белән талымсыз кеше булгандыр. Әйберләре дә бик аз. Чүп җыймаган... Яхшы мәгънәсендә...

Һәм аның сүзләре барысын да үз урынына «утыртып» куя: кешегә тормышта никадәр аз кирәк асылда! Шушылардан күбрәгенә аның ихтыяҗы да булмаган... Чәй эчәргә – кружкасы, ятып йокларга – караваты, рәешкә чыкканда кияргә бер-ике пар костюмы, өч галстугы булгач, тагын ни кирәк?! Ул рәештән рәешкә йөрер өчен яратылган җан иясе дә түгел ләбаса! Аның төп урыны – өстәл белән урындык, ә иң табигый халәте – галәми ялгызлыгы.

Күзгә кара төндә, мин – мосафир,
Үзем белән калгач бергә-бер,
Төн эченнән тавыш бирде бер кош:
«Сәлам!» – диде гүя кемгәдер...

Шомлы җилдә шаулап куйды әрем,
Җылымса җил урман куеныннан
Абагалар исен алып килде,
Мезозойлар чоры ягыннан.

Төн түренә очып барышы иде,-
Юл сорадым иптәш коңгыздан.
Карадым мин шунда нәкъ түбәмдә
Чаткыланып янган йолдызга...

Галәм коесында – талир тәңкә,
Өмет бирде сүнгән күңелгә:
Йөргән чакта шушы яссылыкта,
Юк, ялгыз түгел,
Ялгыз түгел кеше бу Җирдә!

PRESSA.RU





«Әгәр Роберт Әхмәтҗан, бүтән берни дә язмыйча, бары «Солдатлар» исемле шигырен генә биргән булса да, исеме әдәбиятыбыз тарихына кереп калыр иде. Юк, хикмәт Фәтхерахман Әхмәдиевнең йөрәк түреннән сызылып чыккан гаҗәеп моңлы көйгә җырлануында гына түгел. Әйе, ул шигырь, музыка канатларында гына күтәрелеп, сабан тургае кебек күңелләрне җилкендерә, йөрәкләрне дулкынландыра торган шигырьләрдән түгел. Роберт Әхмәтҗановның «Солдатлар» шигыре мөстәкыйль әһәмияткә ия, ул үзе музыка кебек ниндидер тылсымлы аһәңгә ия…

Мин шигырьнең бер серен тотып алдым бугай. Менә ул: шигырь унтугыз яшьлек лейтенантларны, унсигез яшьлек солдатларны шинельләренә төренеп мәңгелек йокыга талган балалар дип атый. Һәм шул «балалар» дигәнне төрле мәгънәләр салып кабатлап бара. Менә шушы зур шигъри табыш әсәрне тылсымлы итә. Харап инде, дияр, бәлки, укучы, нәрсәсе табыш? Кабатлыйм, табыш бу! Шул балаларны, шул аналарны үлеп ярата торган олы йөрәкле шагыйрьнең генә күңеленә, башына һәм каләм очына килә ала торган табыш әнә шул лейтенантлар, шул солдатлар аналарына соңгы минутларына кадәр бала булып калачаклар ич!..»

Ибраһим Нуруллин, язучы, 1995 ел.

ГОМЕР ТИРӘГЕНӘ ГЕНӘ ОРЫНЫП…

– Бигрәк чибәр, мәһабәт кеше булган. Затлы… – дип, соклануын белдерә Любовь Владимировна фондтагы фотографияләрне барлаганда. – Кызганыч, мин аның шигырьләрен оригиналда укый алмыйм, әмма искиткеч тирән, соклангыч шигърият дигәннәрен гел ишетәм. Дөрес, катлаулы да диләр… Андый талантларга яшәве авыр шул…

Гадәттә сәфәребез без язган шәхеснең кече ватанда калган туган-тумачасы, балачак дуслары, аны белгән кешеләр белән очрашып сөйләшүне күздә тота. Әмма Роберт Әхмәтҗанов очрагы монда да искәрмә булды. Аның китапларын һәм туганы турындагы хатирәләрне саклаган Рәйсә ханым да, ни кызганыч, без килеп төшкән көннәрдә каты хаста булып, «татарстанлы»ларны кабул итәрлек хәлдә түгел иде.

Дөньягызга килеп бәхетле мин,
Йа Ходаем, килеп шаккаттым! –
Гасырларын сабыр кичтем кебек,
Мизгеленә – бетте тәкатем!..

– дип язган иде Роберт Әхмәтҗанов «Гомер юлы» дигән бер шигырендә. Әнә шул шигырендәгечә, мизгел булып яктырып алган да ул, утлы көлтәсе безгә калган, әйтерсең. Иң гаҗәпләндергәне: үзе исәндә иҗатын да, шәхесен дә берәү дә ваемлап җиткерә алмаган кебек, хәзер дә «Роберт Әхмәтҗанов» дигән галәмгә орынырга, аны ачарга шикләнәрәк төшәләр шикелле. «Җәяүле күбәләк» шигырендәге образына ияреп, «Җәяүле





Кубәләк» дип тә атадылар аны, татар поэзиясенә яңача тәнкыйди караш формалаштырырга омтылыш ясаган Илшат Вәлиулла аның иҗатын, Көнбатыш призмасында карап, Милан Кундераның атаклы романына ишарәләп, «чынбарлыкның түзеп булмаслык җиңеллеге» дип тә билгеләде. Ә Роберт Әхмәтҗанов барыбер дә ачылмаган галәм булып кала бирә. Лем һәм Тарковскийның «Солярисы» кебегрәк, безгә нидер әйтергә, нәрсәнедер аңлатырга, җиткерергә теләгән Океан, гүяки. Иң тирән яраларыбыз, иң якты хисләребез кайда яшеренеп ята да, хәтеребез нәрсә саклый – әнә шуларга җибәрә ул үзенең нурланышын.

Әмма без ул җибәргән сигналларны кабул итәргә әле бик үк әзер түгелбез бугай. Һаман да. Эзләреннән йөргәч, тормышын да, шәхесен дә күбрәк тоемлап, аңлап булыр иде шикелле. Әмма, юк, ул тагын да зуррак сер булып калды. Аскеза шагыйре булуына тагын да ныграк инанып, «гомер тирәгенең ябалдашы»на гына орынып кайттык. Аны тормышта түгел, ә Шигырьдә эзләр өчен. Бәлки, тапмас өчендер дә, әмма – барыбер эзләр...

Гомерем буе син канатым булдың,
Хыял илләренә чакырдың.
Яңгыр булып тәрәзәмә чирттең,
Син килүгә өем яктырды...

Киткән ярлар китте –
оныттылар,
Хәтерләмим мин дә күбесен...
Тик син калдың, тик син,
и Шигърият, –
Онытылыр ярым түгел син.

ШУЛАЙ БЕРВАКЫТ...

БЕЗНЕҢ ГАСЫР КЕШЕСЕМЕ?

– Чаллыда шигырь язып азапланучы бер мөтәшагыйрьдән сорагач, ул: «Роберт Әхмәтҗан... безнең гасыр кешесеме соң ул?» – дип сорау белән җавап бирде. Әйе, тугани, Роберт Әхмәтҗан Болгар заманнарыннан килгән безнең гасыр кешесе...

1960–1998 елларда аны бары тик бер фәрештә – шигърият кенә саклады һәм исән калдырды. 50нче еллар азагы–60нчы еллар башында татар шигъриятенә үзенең искиткеч чиста, беренчел сафлыктагы, кабатланмас метафора-чагыштырулары, ниндидер сюрреаль образлары, реаль чынбарлыктан читтәрәк торган кебек тоелган сабый шигырьләре, «Таш аргамак» поэмасы белән дулап килеп кергән Роберт Әхмәтҗанны елдашзамандашлары, 30нчы елгылар, читкә тибәрде. Аны ничәмә-ничә тапкыр ул чакта чәчкә аткан төркемчелеккә тартып карадылар. Ул бер төркемгә дә кушылмады, озак еллар китапларын чыгара алмаса да, кумирлар тудыру һәм аларны мактап, премияләр алуга юл тотмады. Әдәби түрәлек аның иң куркыныч дошманнарының берсе булды. Бу шагыйрьлек белән сугарылган шәхсән позиция яшәеш чыганагы иде.

Без, 40 нчы елгылар, барыбыз да диярлек, Роберт Әхмәтҗан шаукымында идек. Без аны хәтта табыну объекты – шагыйранә балбал, кумир ясарга да әзер идек. Әмма ул аңардан да баш тартты, хәтта мондый шаукымлы «түрәлек» – богемачылыктан да тартынды, күрәсең. Тумыштан бик тә тыйнак, ашыкмаган Роберт барыбер беркемгә дә охшамый торган үз богемасында калды. Мондый иҗади батырлык премияләр белән түгел, намуслы гомер, әрнүле язмыш белән аклана шул.

Айдар Хәлим, язучы.
1998 ел.

ШАГЫЙРЬ ЯЗЛАРЫН НИК САНЫЙ?

– Мин әле әлифбаны яңа өйрәнеп, икенче класска гына күчкән елны (1958 ел) әткәем Уфага эш белән баргач, гаиләдәге алты кешегә алты кызыл алма, ә миңа (миңа алма җитмәдеме икән инде?) Роберт Әхмәтҗановның «Егерменче яз» исемле шигырь китабын алып кайткан иде. Һәм мин, китап кулыма эләгүгә, татлы, сутлары сыгылып торган хуш исле кызыл алма турында бөтенләй оныттым.

Бүген, әлбәттә, көлке тоелыр, әмма ул чакта мине иң гаҗәпләндергәне китапның исеме булды: бу кеше ни өчен язларны санап бара икән дә, егерменче язда нәрсә булган?

Булган. Шагыйрь мине, нәкъ икенче класска кергәндә, мәхәббәт учагына ташлады. Мин ул китапны гел ераграк яшерә, аннан качып котылырга тырыша торган бер Мәҗнүн, юк, бер Ләйләгә әверелдем. Һәм... беразданинде курку аша булса да, хакыйкатькә төшендем: мәхәббәттән качып котылып булмый...

Мин Роберт Әхмәтҗановның башка китабы булырга мөмкин, шигырь аннан да тәэсирлерәк була, дип уйлый алмый идем. Чөнки гомер язларының санаулы гына икәнлеген, сигез генә яшьлек кешегә мәхәббәттән качып булмаганлыгын төшендергән илаһи китап булды ул миңа тугызынчы язымда. Ул миңа: «Граждане, яз килә!» – дип, күзләрем саргаеп сулганда да, кышларым башына чал төшкәндә дә һаман оран салып торды һәм тора.

Нәҗибә Сафина, язучы.
1995 ел.

PRESSA.RU

Идел буе Болгарстанында тантаналы рәвештә исламны кабул итү. Рушан Шәмсетдинов картинасы. 1997 ел.

АЛМЫШ ХАН ҺӘМ ИБНЕ ФАДЛАН

ТАТАРСТАН
МАХСУС

Таныш исемнәр. Беренчесе – Идел Болгары дәүләтенә нигез салган шәхес, икенчесе – Болгар дәүләтендә рәсми ислам кабул итү тарихы белән бәйле Багдад илчелеге сәркәтибе.Ниләр беләбез без алар турында? Кызганычка каршы, бик аз. Шулай да, тарихи чыганакларга таянып, белгәннәребезне бер тәртипкә салып карыйк әле.

Автор:
Фаяз Хуҗин

ДӘҮЛӘТ ТӨЗҮ

IX гасыр ахыры – X гасыр башы Кара диңгез, Азов һәм Каспий буе далаларыннан Урта Иделгә күчеп утырган болгарлар тарихында мөһим этап булып тора. Инде ике йөз ел чамасы Идел-Кама төбәгендә яшәп, шул төбәкнең табигатенә яраклашып, халкы белән ярыйсы гына танышып, утрак тормышка күнегеп өлгергән болгарлар һәм дә алар белән бергә күчеп утырган тугандаш суварлар, барсиллар, бәрәнҗәрләр, тарихка **Шилки** исеме белән кереп калган илтәбәр (юлбашчы) кулы астында берләшәләр.

Кешелек җәмгыятенең борынгы община строеннан башлап кайсы гына чорын алып карасаң да, социаль тигезсезлек дигән күренешкә тап булырбыз. Бу – табигый хәл. Һәр җәмгыятьнең лидерлары була. Алар гади халык массасыннан (ыругдашларыннан, кабиләдәшләреннән), беренче чиратта, физик яктан көчле булулары, кыюлыклары һәм батырлыклары белән, аннан соң, хәзергечә әйтсәк, ораторлык сәләте белән дә аерылып торганнар. Нәкъ менә шул лидерлар арасыннан сайланып куела торган булган инде кабилә юлбашчылары. Һәм шул ук юлбашчылар күрше кабиләләргә талау сугышлары (ул заманнар өчен гадәти хәл) оештырганнар, кулга төшкән байлыкны да, үзләренчә аңлаган гаделлек принципларыннан чыгып, алар бүлгән. Байлыгы булгач, ул юлбашчының яшәү шартлары да үзгәрәк

Фотолар автордан алынды

була инде, әлбәттә. Гади халык кебек кечкенә юрталарда яшәмәс ул, сарайлар төзетер үзенә. Булган байлыгын саклау өчен һәм үзенең иминлеген дә кайгыртып, юлбашчы тугрылыклы сугышчыларыннан торган дружина тота башлый. Ул дружинаны да, әкренләп кубәя барган эреле-ваклы чиновникларны да туйдырырга кирәк бит – халыктан салым җыя башлыйлар. Шул рәвешчәрәк барлыкка килә ул дәүләт дигән нәрсә. Дәүләтнең идарә органнары – администрациясе, шул администрация, хаким резиденциясе урнашкан каласы (крепосте) һәм инде хакимгә (ханга, патшага) буйсынучы халыклар яши торган территориясе була.

ИДЕЛ БОЛГАРЫ ДӘҮЛӘТЕНЕҢ БЕРЕНЧЕ ИДАРӘЧЕСЕ

Илтәбәр Шилки чорында болгарлар гегемонлыгындагы төрки кабиләләрдән торган дәүләт берләшмәсе формалаша башлый. Бу процесс аның улы **Алмыш хан** чорында төгәлләнә. Алмыш ханны без, тарихчылар, Идел Болгары дәүләтенең беренче идарәчесе – илтәбәре дип саныйбыз. Бу чыннан да шулай. Ләкин шуны да истә тотарга кирәк: Х гасыр башында әле ул – Хәзәр каганлыгына буйсынган өлкә генә. Алмышның улы каган сараенда тотык (заложник) хәлендә яши, ә кызы каганга көчләп кияүгә бирелгән була. Әмма Алмыш бу бәйлелектән котылуның төрле юлларын эзли, дәүләтнең мөстәкыйльлегенә омтыла, һәм тиздән әлеге бәйлелек формаль бер нәрсәгә әйләнә. Менә фактлар.

Алмыш хан, хәзәр каганының рөхсәтен сорап та тормыйча, үзенең исеменнән акча суктыра башлый. Беренче болгар акчалары, нумизмат-галимнәр әйтүенчә, 902–908 еллар аралыгында сугылган. Археологик казу эшләре вакытында килеп чыккан әлеге акчалар – дәүләтнең мөстәкыйльлеген раслаучы кыйммәтле табылдыклар. Сүз уңаеннан шуны да исегезгә төшереп үтәм: әлеге акчаларда Алмыш ханның мөселманча исеме күрсәтелгән – Җәгъфәр ибне Абдаллаһ. Димәк, шул чорда ук инде болгар идарәчесе ислам динен кабул иткән булып чыга.ее

Алмыш хан. М.В.Горелик реконструкциясе.

Идел Болгары идарәчесе – илтәбәр Алмыш Багдад хәлифәсе илчелеге сәркатибе Әхмәд ибне Фадлан тарафыннан шактый җентекле итеп сурәтләнә. Фадлан Алмышның түбәндәге портретын бирә: бик таза, озын буйлы һәм мәһабәт гәүдәле, күкрәктән чыккан куәтле тавышлы.

Сурәтләр һәм археологик дәлилләргә караганда, Алмыш ханның өстендә уемы муеннан билгә кадәр сузылган, озынлыгы тезгә кадәр җиткән кафтан. Уемның түгәрәк төймәләре каптырма элмәкләргә төймәләнә. Кафтан якалары җәнлек тиресе (койрыгы җилкә аркылы күкрәгенә төшеп торган) белән каймаланган. Бәйрәм кафтанын кыйммәтле ефәктән тегәннәр, ефәк Византиядән, Урта Азиядән, Фарсы иленнән яисә Кытайдан ук кайтартылган. Кафтан кыйммәтле металл бизәкләр куеп эшләнгән пута белән буып куелган, путага шулай ук кыйммәтле металлар белән бай итеп бизәкләнгән кылыч, сугышчан пычак һәм янчык та эленгән.

Ыштан балаклары чигелгән, күн бизәкләр белән бизәлгән биек кунычлы итеккә кыстырылган. Башына кыйммәтле мех белән каймаланган түгәрәк яисә конус формасындагы башлык кигән. Ул шулай ук кыйммәтле металлардан ясалган тәңкәләр һәм укалар белән бизәлгән.

Болгар – сәүдәгәрләр иле. Яз ахырларына таба Идел буйлап Болгар ярминкәсенә төрле илләрдән сәүдә кораблары килә торган була. Аларны гадәттә хан үзе каршы ала, чөнки сатуга алып килгән товарларның уннан бер өлеше дәүләт казнасына тәгаенләнә. Хәзәрләрдән килгән сәүдәгәрләргә дә Алмыш тарафыннан бернинди ташлама ясалмый.

ХАЛЫКАРА МӨСТӘКЫЙЛЬЛЕККӘ БЕРЕНЧЕ АДЫМНАР

Алмыш хан дипломатия өлкәсендә дә үзенең беренче һәм, әйтергә кирәк, уңышлы адымнарын башлый: Урта Азия илләре белән тыгыз мөнәсәбәтләр, беренче чиратта, сәүдә элемтәләре урнаштыра, угызлар берләшмәсенең Әтрәк исемле бер кабилә башлыгына үзенең кызын (башка чыганаклар буенча – сеңлесен) кияүгә бирә. Алмыш хан дипломатиясенең иң зур уңышы, әлбәттә, – Гарәп хәлифәлеге белән илчелекләр алмашу.

921 елда Алмыш хан Багдадка Габдулла ибне Башту җитәкчелегендәге илчелек җибәрә. Аның төп бурычы Багдад хәлифе әл-Моктәдир белән хәзәр каганына каршы бердәмлек (союз) төзү була. Бу турыда Алмышның әл-Моктәдиргә юлланган хатында ап-ачык әйтелгән. Хәтта Алмыш хан Багдад хәлифеннән «дошманыннан саклану өчен» крепость-шәһәр төзүдә ярдәм сорый һәм Болгарга Багдад илчелеге составында ислам дине белгечләрен дә җибәрүен үтенә. Сөйләшүләр барышында Моктәдир үзеннән илчелек җибәрергә ризалыгын белдерә. Аның төп максаты болгарлар арасында хәлифәт йогынтысын ныгыту, ислам дине таралышын төньяк тарафларга кадәр киңәйтү, хәзәрләргә каршы көрәштә Алмыш ханның булышлыгына ирешү була.

Билгеле булганча, Алмыш хан Багдад илчелеген Болгар җирендә 922 елның 12 маенда каршылый. Берничә көннән соң, төгәлрәк әйткәндә, 16 майда, тантаналы шартларда ислам дине дәүләт дине буларак кабул ителә. Тарихыбыздагы әлеге мөһим вакыйгага турында сөйләгәндә бер нәрсәгә игътибар итегез: бу чакта бит хәзәр каганнары яһүди динен тотканнар, Алмыш хан исә, дөресрәге, инде ике дистә ел элек үзен мөселман дип игълан иткән Җәгъфәр ибне Абдаллаһ, алардан рөхсәт тә сорап

PRESSA.RU

Алмыш ханның Ибне Фадлан белән очрашуы. Рушан Шәмсетдинов картинасы. 1999 ел.

тормыйча, илдә ислам динен рәсмиләштерә. Бу факт та, минемчә, Болгар дәүләтенең Хәзәр каганатыннан номиналь рәвештә генә бәйлелектә булуына ишарә.

X гасыр башларында Болгар илендә Болгар, Биләр, Сувар кебек исемнәре елъязмаларда теркәлеп калган беренче шәһәр-калалар барлыкка килә. Эреле-ваклы авыллар турында искә дә алып торасы түгел. Икенче төрле итеп әйткәндә, ярымкүчмә болгарларның җирләшүе, ягъни тулысынча диярлек утрак тормышка күчүе Алмыш хан чорында тәгәлләнә. Болгар иленең киләчәктәге тотрыклы үсешенә дә нәкъ менә Алмыш хан идарә иткән чорда ныклы нигез салына.

Алмыш ханның ничәнче елларга кадәр идарә иткәнлеге мәгълүм түгел. Ислам динен дәүләт идеологиясе дәрәҗәсенә җиткереп рәсмиләштергәннән соң ул тәхетне улына, Микаил бине Җәгъфәргә калдыргандыр, дип уйларга нигез бар – Микаил бине Җәгъфәр исеме сугылган акчалар 920 нче елларга карый.

БАГДАД ИЛЧЕЛЕГЕ БОЛГАРДА КУНАКТА

Алмыш хан **Әхмәд ибне Фадлан** белән, югарыда әйтелгәнчә, 922 елның 12 маенда очраша. Гарәп сәяхәтчесе Әхмәд бине әл-Габбас ибне Рәшид ибне Хаммад ибне Фадлан – Багдад илчелегенең сәркәтибе, хәлиф сарае хезмәтчесе. Бик укымышлы кеше була, шуңа күрә аңа юл язмалары алып бару һәм илчелекнең эш нәтиҗәләре турында исәп-хисап тоту эше тапшырыла. Бу эшне ул менә дигән итеп башкарып чыга. Безнең көннәргә кадәр сакланып калган Ибне Фадлан язмалары («Рисалә») болгарларның X йөз башы тормыш-көнкүрешен, гореф-гадәтләрен ярыйсы гына тулы итеп күз алдына китереп бастырырга мөмкинлек бирә.

16 майда үткән тантаналардан соң Алмыш хан Багдад кунакларын һәм үзенең якыннарын мең кеше сыйдырырлык юртасына мәҗлескә чакыра. Кунакларны кабул итү йоласын Ибне Фадлан үзенең китабында җентекләп тасвирлый, шул ук вакытта болгар патшасы турында да беренче тәэсирләрен бәян итә. Алмыш ярыйсы гына тулы гәүдәле, инде корсак та үстерә башлаган урта яшьләрдәге боеручан бер хакимдер, ди. Гомумән алганда, Багдад илчеләрендә ул уңай тәэсир калдыра.

Бер-ике көн үтүгә, Алмыш илчелек сәркәтибен үзенә чакыра һәм аны утлы табага бастыра: «Әл-Моктәдир хәлифәнең хатында телгә алынган һәм син миңа тапшырырга тиешле 5000 динарны кая куйдыгыз? – дип җикерене хан. – Ул акчаларны мин кальга (крепость) төзегәндә сарыф итәргә исәп тота идем». Алмышның мондый кыланмышыннан куркуга төшкән Ибне Фадлан аңлатып бирә: Моктәдирнең ул динарларны бирергә тиешле бурычлы кешесе бөлгән булып чыга һәм илчелек, ул яши торган шәһәрдән буш кул белән чыгып, юлын дәвам итәргә мәҗбүр була. «Дөресен әйткәндә, казнамда ул каланы гына төзерлек алтын-көмешәрем җитәрлек, – ди Алмыш моңа җавап йөзеннән. – Хәлифәнең динарларын бу эшкә хәерхаһлык, Аллаһның ризалыгы билгесе итеп кенә кабул итмәкче идек».

Берничә көннән бу аңлашылмаучылык бөтенләй онытыла, һәм Багдад илчелеге килү шатлыгыннан башы күккә тигән Алмыш хан Ибне

Фадланны һәм аның юлдашларын халык арасына алып чыга, ил белән таныштыра, болгар бабаларының элеккедән калган гореф-гадәтләре турында сөйли. Ибне Фадлан Болгарга килгән рус-варяглар белән дә якыннан танышу бәхетенә ирешә. Күзәтүчән һәм искиткеч хәтергә ия сәркәтип боларның барысын да күңел дәфтәренә «язып» бара.

Илчелек Болгар илендә берничә ай була, көзгә таба, «көннәр кыскара башлагач», кире кайту юлына чыга.

КЫЙММӘТЛЕ ТАРИХИ ЧЫГАНАК

Багдадка кайтып җиткәч, Әхмәд ибне Фадлан үзенең юлъязмаларын тәртипкә салып, күргән-белгәннәрен яңадан исенә төшереп, Моктәдир хәлифә өчен хисап әзерли. Бәхеткә каршы, бу язмалар юкка чыкмаганнар. Аларны 1923 елда Иранның Мәшһәд шәһәре китапханәсендәге кулъязмалар бүлегендә Төркиядә яшәүче эммигрант-тарихчы Әхмәтзәки Вәлиди табып ала һәм 1939 елда Германиядә (Лейпцигта) немец телендә бастырып чыгара. Ибне Фадлан кулъязмасы А.П. Ковалевский тәрҗемәсендә 1956 елда Мәскәүдә дә нәшер ителә. Әнвәр Хәйри тарафыннан әзерләнгән татарча тәрҗемәсе 2013 елда дөнья күрде.

Әхмәд ибне Фадлан «Сәяхәтнамәсе» Идел болгарлары, аларның күршеләре башкорт, хәзәр, угыз, һәм дә рус-варяглар тарихын өйрәнүдә кыйммәтле һәм ышанычлы тарихи чыганак булып тора.

Татар тарихында иң күренеклеләрдән саналган уникаль шәхесләр буларак, Алмыш хан белән Ибне Фадлан һәйкәлләрен башкалабыз урамнарында, паркларында күрергә насыйп булсын иде.



Ибне Фадлан сәяхәте. Җаек елгасын кичү. Рушан Шәмсетдинов картинасы. 1999 ел.

PRESSA.RU



Фото «Татарстан» журналы архивыннан

ТАТАРЛАР – ДӘҮЛӘТ ТӨЗҮ ЮЛЫНДА

Бу язмамда сүз татар халкының тамырлары турында барачак. Җир йөзендә бер генә дә сыңар тамырлы халык юк. Татарлар да бер тамырлы гына түгел. Алар тик болгарлардан гына яки Алтын Урдадан гына барлыкка килгән дигән фикерләр белән килешеп булмый.

Автор:
Индус Таһиров

ТАТАР ФЕНОМЕНЫ

Без болгарлар да, койрыгыбыз белән Алтын Урдага нык береккән. Өстәвенә, без әле кыпчаклар да. Хәтта хәзәрләр дә. Угро-фин, күпмедер рәвештә славян каны да бардыр бездә. Һәрвакыт бертуктаусыз хәрәкәттә булган, дөньяның бер читеннән икенче читенә йөреп торган халыкта ник башкаларның да тамгасы булмасын икән? Алар бар, әлбәттә. Ләкин ничек кенә булмасын, без – төркиләр. Алай гына да түгел, төркиләрнең юл башында торган татарлар без.

Безгә мәгълүм булган юл башыбыз моннан 25 гасыр элек яшәгән бабаларыбызга барып тоташа. Шушы дәвердә борынгы бабаларыбыз берничә, хәтта кытайларны буйсындырырдай дәүләтләр төзегәннәр.

Ни гаҗәп, без 1895 елда ук инглиз галиме Эдуард Паркер тарафыннан язылган «Татарлар тарихыннан меңел» исемле китабына тиешле игътибар бирми яшәгәнбез. Бу кеше, күп еллар буе Кытайда дипломатик хезмәттә булып, борынгы кытай чыганакларын өйрәнгән һәм татарның тирән тамырларын нык-лап ачыклаган. Заманында китап шулкадәр зур резонанс тудырган ки, аны 1937 елда кытай галиме, Шан Да Паркерның мәгълүматларын яңа чыганаклар белән тагын да баетып, үз телләренә тәрҗемә иткән.

PRESSA.RU

Бу соңгы мәгълүматны мин бүгенге көнне Алматы шәһәрендә яшәүче милләттәшебез Мөнир ага Ерзинның үземә язылган хатыннан белдем. Мөнир ага үзе дә бик кызыклы шәхес. Ул заманында Кытайда кытай телендә университет бетергән Алматыда да университет тәмамлаган. Ул да кытай чыганаклары белән таныш. Мөнир ага ул чыганакларын кайсы китапханәләрдә ятканлыгы турында язган. Аңа моның өчен генә түгел, Кытайга күчеп килгән татарлар язмышына багышланган «Тропою предков» исемле китабы өчен дә зур рәхмәт.

Тагын бер милләттәшебез – дипломат һәм галим Йолдыз Хәлиуллин турында фикер белдермәсәм, мине дөрес аңламаслар, дип уйлыйм.

Татар тарихы һәм аның бүгенге язмышы белән янып-көеп йөрүче милләтәшебезнең «Независимая газета»сында 2009 елның 6 октябрендә басылган һәм Эдуард Паркерга багышланган зур әһәмияткә ия булырдай мәкаләсен шулай ук бик кызыклы, дип саныйм.

Татарларның дәүләти тәҗрибәсе монголларга да күчеп, аларга да дөньякүләм империя тудыруга юл ачкан. Татарның биеклеге монголлар барлыкка китергән Алтын Урда дәүләтен татарлаштыруда да чагылыш тапкан. Моны бернинди шик-шөбһәсез татар феномены дип атарга була. Болгар иленә, кыпчак далаларына килгән монголлар, хәтта Чыңгызның үз токымы да төркиләшкән, татарлашкан.

Икенче бер нык төпле болгар тамырыбыз аларны ислам диненә күндергән, Алтын Урда дәүләтен ислам дөньясына алып кергән. Алай гына да түгел, ханнар Мәскәү дәүләтенә нигез салганнар. Дөрес, рус тарихчыларының күбесе, Гарвард университеты галиме Ричард Пайпс әйтмешли, бу турыда сөйләргә ояла.

Тамыры тирән булган халыкны тарихтан йолкып алу мөмкин түгел. Татар язмышы – авыр язмыш. Бөеклекнең иң биек ноктасыннан коллык ноктасының иң төбенә төшү җиңел була алмый, әлбәттә. Дөньяның гөрләп торган ничәмә-ничә дәүләтен юктан бар иткән халыкка кискен рәвештә коллыкка күчү – ул фаҗиганең дә фаҗигасе.

Чыннан да, кыска гына вакыт эчендә Казан җир белән диярлек тигезләнә, татарлар башкалаларыннан, уңайлы булган күптәнге яшәү урыннарыннан куыла. Гасырлар буена җыелган рухи байлыгыбыз бөтенләе белән юкка чыга. Бәлки башка бер халык шушы сынаулар аша үтә дә алмаган, инде күптән юкка чыккан булыр иде. Ләкин татар үлемне дә, кайгыны да җиңәргә өйрәнгән һәм тарих тарафыннан ныклап чарланган халык. Аңа яшәү көчен әнә шул тамырлары биреп торган.

Татарлыкның иң зур дошманнарыннан булган атаклы миссионер Ильминский юкка гына татарларны дәүләтле халык дип атамагандыр. Безнең халык дәүләтеннән мәхрүм булганнан соң да, кайгы белән үлем арасында калса да, бөек булып кала алды. Миссионерларның «татарлар өч йөз буена руслар белән бергә яшәүләренә дә карамастан, руслашмыйлар, киресенчә башкаларны татарлаштыралар», дигән сүзләрендә дөреслек юк түгел. Галим-миссионер Ефимий Малов 1904 елның 30 сентябрь – 14 октябрь чорындагы көндәлек язмалары арасында уфтанып язылган мондый юллар бар: «Без, руслар, ун гына түгел, йөзләгән еллар дәверендә татарлар өстеннән хаким сыйныф рәвешендә яшибез. Инде Казан алынганнан соң да өч йөз елдан артык вакыт үтте, тик менә без аларны күпме дәрәҗәдә генә руслаштыра алдык икән соң? Тагын да өч-дүрт йөз ел көтәрбезме икән?»

МИЛЛИ ТАМЫРЛАР УЯНА...

«Уяндык без бишенче елның бер таңында», – дип язган Тукаебыз. Россия капкасын революция шакый башлау белән татар да уяна.

Татарлар XVIII–XIX гасыр чикләрендә яңарыш кичереп, үз мәгариф системаларын булдырып, Россиянең иң укымышлы халкына әвереләләр, 20 дән артык газета-журнал, миллионлаган тираж белән китаплар чыгарып, аларны барлык төрки халыкларга да җиткерә алуга ирешәләр. Дистәләгән язучы, шагыйрь үсеп чыга, театрлар барлыкка килә, музыкаль сәнгать туа. Әллә инде «халыклар төрмәсе» дип аталган Россиядә шушы гүзәл үзгәрешләрне булдыра алу могҗиза түгел? Бу һичшиксез могҗизаның да могҗизасы! Кыскасы, Россия күгендә татар йолдызы балкый башлый.

1911 елны «Вакыт» газетасында басылып чыккан бер хатта мондый сүзләр бар: «Үзенең китап теле һәм әдәбияты, үзенең тарихы, менә дигән үткәне булган халык беркайчан да юкка чыкмас... Менә безнең халык уяна, өстендәге кабер туфрагын кагып төшерә һәм озаклап яткан кабереннән чыга. Татарның киләчәге томанлы түгел, ул бик тә ышанычлы».

Казан жандарм идарәсе башлыгы 1909 елның 9 августындагы Эчке эшләр министрлыгының полиция департаментына юнәлтелгән депешасында татарлар арасында милли идеянең ныгуына борчылып, болай дип язган: «Бу идеянең максаты барлык мөселманнарны бер дәүләткә җыюдан гыйбарәт. Аның тактик алымнары татарларда һәм мөселманнарда милли хис уятуга, автономия, милли мәктәп, милли бердәмлек булдыру, рус йогынтысына һәм хөкүмәтнең руслаштыру сәясәтенә каршы торуга юнәлтелгән... ә киләчәктә Төркестан һәм Кавказ белән союзга кереп, эшне гомумтөрки республика төзүгә кадәр җиткерү күздә тотыла».

1911 елда төзелгән бер жандарм белешмәсендә «Казан губернасында һәм кайчандыр куәтле булган тарихи татар патшалыгының үзәге Казанда алдынгы татар элементлары җыела», – диелгән. Әйе, беренче рус революциясеннән соң Россия татарлары дәүләтчелекләрен аякка бастыруны максат итеп куялар. Шул елларны Петербург шәһәрендәге татар студентлары «Татар учагы» исемле оешма оештырып, анда шулай ук татарлар өчен махсус республика булдыруны үзләренең бурычлары итеп билгелиләр.

Ә инде 1917 елгы революцион өермәләр дәверендәге берничә мөселман съездында дәүләтчелек мәсьәләсе ныклап тикшерелә. Шул елның маенда булып үткән I Мөселман съездында Россия федератив рәвештәге дәүләткә әверелергә тиеш дигән карар кабул ителә. Ә Нижгар мулласы Габдулла Сөләймани Россиядә татарлар өчен бер штат төзергә кирәклеген алга сөрә. «Штат» төшенчәсе беренче мәртәбә шунда яңгырый һәм акрынлап көчкә керә. ■

ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

2018 елның
II яртыеллыгына
«Татарстан»
журналына язылу
дәвам итә

«Татарстан» журналына ТР буенча язылу индекслары:

П 2381	**татар телендә** 900 сум 00 тиен	**П 2378**	**рус телендә** 900 сум 00 тиен

«Татарстан» журналына РФ буенча язылу индекслары:

П 7076	**татар телендә**	**П 7077**	**рус телендә**

Реклама 16+

PRESSA.RU

КЕШЕЛӘРНЕ КЕШЕГӘ ИЛТҮЧЕ ЮЛЛАР

2018 елгы китап яңалыкларына күчәргә дә вакыт җитте. Берәмтекләп аларны барлауга керешәбез, димәк. Бу сезон безгә шактый кызыклы, ымсындыргыч исемлек тәкъдим итә: Бернар Вебер «Из потустороннего мира», Харуки Мураками «Убийство командора», Фредерик Бегбедер «Жизнь без конца», Рутгер Брегман «Утопия для реалистов», Нури Робен «Смерть Сталина», Борис Акунин «Не прощаюсь», Алексей Иванов «Тобол. Мало избранных», Дина Рубина «Рябиновая роща», Гузәл Яхина «Дети мои»... Үзебезнең китап нәшриятында басылып чыкканнары – аерым бер киштәне тәшкил итә. Барысына да – үз вакыты. Әлегә быелгы иң көтелгән китапларның берсеннән башлый торыйк.

Автор:
Луиза Янсуар

Джулиан Барнс, «Одна история»

Джулиан Барнсның яңа романын көтеп алу дөнья укучысына гына түгел, ә рус телле аудитория өчен дә үзенә күрә бер тенденциягә әверелде, дисәк, ялгышмабыз, дип уйлыйм. «The only story», ягъни «Одна история» белән дә шулай булды – баштарак ул инглиз телле ленталарда пәйда булса, акрынлап, әле тәрҗемә ителгәнче үк, инде русчага үзешчән тәрҗемәләрдә дә челтәрдә «йөри» башлады. Кыскасы, 2018 елгы китап яңалыклары арасында ул иң көтелгәннәреннән берсе иде...

Барнс исеме рус укучысына инде күптәннән һәм яхшы таныш. Бездә аның әсәрләренә игътибар да, ихтыяҗ да шактый зур. Шуңа да ул, хаклы рәвештә, рус теленә яхшы тәрҗемә ителгән хәзерге көн авторларының берсе буларак исәпләнә. Инде заманча классикага әверелгән «Метроленд» романы кайчандыр рус укучысы шулай ук яратып укыган Сомерсет Моэм премиясенә ия дип табылган иде. Әлеге әсәр бездә шактый популяр – аны 1960 елгы буынның гыйсъянчы һәм нигилистлары манифесты дип тә атыйлар.

Соңрак Барнс безне «До того, как она встретила меня», «Любовь и так далее», «Попугай Флобера», «История мира в 10 ½ главах», «Шум времени», «Как все было», «Англия, Англия» һ.б. әсәрләре белән сөендерә килде. Ә минә 2011 елда Букер премиясенең шорт-битенә эләккән (Барнс Букерга моңа кадәр дә 3 тапкыр тәкъдим ителә) һәм ахыр чиктә аңа лаек дип тә табылган «Предчувствие конца» романы минем шәхси коллекциямдә (һәм минем генә дә түгел, бу Барнсның, сораштырулар күрсәткәнчә, «иң-иң» әсәре дип санала) иң кадерлеләрдән.

Аны бүгенге заман язучыларыннан иң аяусызы, «коры» теллесе, һәм бер үк вакытта «төзәлмәс романтигы» да дип атыйлар. Мәхәббәтнең тормышчан нюансларын сурәтләүдә Барнс кадәр саркастик-усалы да, нечкә-лиригы да юк бугай. Хәер,

Әдәбиятка ярлыкларны язучылар үзләре түгел, ә тәнкыйтьчеләр тага. Миңа күп еллар дәвамында бик күп төрле «лейбл»лар йөртергә туры килде. Бер Америка тәнкыйтьчесе мине «предпостмодернист» дип атады. Хәзер дә ул төшенчәнең мәгънәсенә төшенә алганым юк әле. Ничек кенә булмасын, без инде бернинди ярлыкларга да туры килмибез, минемчә. Модернистлар моннан йөз ел элек иҗат итсә, постмодернистлар (әйтик, Борхес буыны) инде барысы да – кабердә. Без хәзер кемнәр була алабыз, дисезме? Пост-постмодернистлар, дигән атама киләме шунда ук телегезгә? Юктыр, дип ышанасым килә. Минем романнар, үзегез билгеләгәнчә, бер-берсеннән шактый аерыла: кайсылары формаль рәвештә новаторларчадыр, бәлки, икенчеләре, киресенчә, кинәт кенә – традицион. Мин абстракт әдәби агымга караганда, хәзер яза торган конкрет китабыма тугры калуны кулайрак күрәм. Әйдәгез шартлы рәвештә, без язганнарны Пост-Лейбл әдәбияты дип атап карыйк, булмаса.

Джулиан Барнсның «Российская газета»да басылган әңгәмәсеннән.

Аны «инглиз әдәбиятының тере классигы», «постмодернизм әдәбиятының апостолы», «бүгенге заман әдәбиятының хамелеоны», хәтта desperado («десперадо», «отчаянный») дип тә атап йөртәләр. Үзе исә ул бүгенге әдәбиятта чикләр юылган, ә исем-атамалар гомумән дә актуаль түгел дип саный.

берсе икенчесе белән аерылгысыз бәйләнгән бит – никадәр нечкәрәк булса, кеше шулкадәр агрессиврак рәвештә үз-үзен саклый, тышкы факторларга каршы тора да. Вакыты-вакыты белән романтизм чорында – Ромео-Джульетталар хиссияте заманында калгандай тоелган Барнс геройларына бу ике чик аеруча хас. Быелгы «Одна история» романы язучының моңарчы дөнья күргән романнары арасыннан иң күңелгә тия, иң тетрәндерә торганыдыр да, бәлки. «Предчувствие конца» әсәренең дәвамы буларак язылган әлеге әсәр, һәрхәлдә,

PRESSA.RU



минем китап киштәмә төшмәскә менеп кунаклады.

Тәнкыйтьчеләр романны «кеше мөнәсәбәтләрен гаять җентекле, ювелирларча нечкәлек һәм осталык белән анализлаган заманча әсәрләрнең берсе» дип тамгалады. Барнсның «иярләгән» өлкәсе бу – мәхәббәттәге метаморфозалар. «Кеше кайсы урында иң нык ачыла, аны шунда эзләргә кирәк» дигән позициядә тора ул. Нәкъ менә шунда кешенең фәрештәләре дә яши, иблисләре дә, аныңча. Һәм, асылда, кешене, барнсча, нәкъ менә мәхәббәт тарихы билгели дә – беренчесе һәм соңгысы. Әнә шулай, мәхәббәтне микроскоп астына куеп тикшереп, ул аның кискен борылышларында кеше табигатенең ничек чагылуын, характерының ничек формалашуын күрсәтә безгә. Беренче мәхәббәт – моның өчен иң кулай эксперименталь база, кинәнеп тикшеренүләр уздырырга мөмкин. «Афәрин, Барнс!» – дияргә генә кала.

«У большинства из нас есть только одна история. История любви у каждого своя. Пусть она закончится крахом, угаснет, пусть даже не начнётся вовсе и останется в воображении, но от этого она не станет менее реальной. Наоборот, она может стать даже более реальной. Иногда встречаешь пожилых супругов, которые, как видно, до смерти наскучили друг другу, и диву даёшься: что между ними общего, почему они до сих пор вместе? И оказывается, не потому, что их держат условности, привычка и самоуспокоенность. А потому что у них есть история любви. Она есть у каждого человека. И это – единственная история».

Һәм менә безнең самими рәвештә «мәхәббәт романы» дип кенә кабул итәргә әзер булган романыбыз аяусыз рәвештә иҗтимагый чынбарлыкның куркыныч кисемтәсенә әверелә – узган гасыр Англиясе, Лондоннан ерак булмаган кечкенә генә ыспай шәһәрчек. Геройлар аны китапның буеннан-буена «Деревня» дип атый. Бар да җайга салынган: җитеш тормыш, бу тормышның бер өлеше булган урта хәлле (әүл урта хәллелек безнекеннән шактый аерылып тора, монысын да онытмыйк) буржуа әфәнделәр һәм ханымнар тормышларын ни белән дә булса бизәргә омтылып яшиләр. Теннис – шул мавыгуларның берсе. Һәм менә көтмәгәндә-уйламаганда, «авыл»ның зур өметләр уяткан «алтын яшьләре»нең берсе – 19 яшьлек Пол исемле егетебез – теннис клубына барган җиреннән үзенә әнисе булырдай, 40 яшьтән узган ханымга – җирле сәяси клеркның хатыны Сьюзен Маклаудка гашыйк була. Көпә-көндез, Англия чынбарлыгы уртасында, үз яшенең зирәклегенә, ышанычлылыгына карамастан... Сьюзен Маклауд та яшь-яшь егеткә карата чын хисләр белән яна башлый. Сьюзенның Полдан өлкәнрәк, инде университетта укый торган ике кызы бар. Полның әти-әниләре аңарга бөтенләй икенче төрле язмыш тели. Баштарак «кәмит бер скандал» рәвешендә генә кабул ителгән, бөтен «авыл»ны тетрәндергән әлеге вакыйга акрынлап «кәмит» кенә булудан туктый. Әмма шуның белән тагын да аянычрак төсмер ала. Кешеләр башка кешеләргә, баштарак төрттереп, аннан ачыктан-ачык мыскыллап, һөҗүмнәр ясап, «кәмит»не әле кичерергә дә әзер, ә менә чын хисләрне, ихласлыкны – беркайчан да! «Дөньядагы иң куркыныч нәрсә – ихласлык һәм чын тойгылар» – Барнс романнары аша кызыл җеп булып үтә торган мотивларның берсе бу.

Һәм менә аяк астыннан туфрак киткән, өендә ире тарафыннан еллар буена кыйналып, җәберләнеп яшәгән (әмма беркайчан да бу хакта «авыл» халкына сиздерергә җөрьәт итмәгән һәм мәңге җөрьәт итмәячәк тә!) Сьюзен белән әле ул туфракта ныклап басып та тормаган Пол икәүләп Лондонга чыгып китәләр, Сьюзенның булган акчаларына йорт юнәтәләр һәм... бергә яши башлыйлар. «Авыл» өстенә аяз көндә бомба төшкәндәй була. Әмма... ул шартламый кала. Кешеләр, бу акылга сыймаслык тарихны эчләренә йомып, азагы ни булып бетәчәген көтә башлыйлар: мәхәббәт бит ул башында гына матур вә соклангыч, ә тора-бара, җаваплылыкка һәм көндәлек мәтавыкларга әйләнгәч, тотып кара син кулыңда ул асыл кошны...

Сьюзен белән Пол язмышына төшкән сынау озак дәвам итә – 10 елдан артык. Бу аралык эчендә төрлесен кичерергә туры килә

аларга. Үзләрен бөтенләй кешелектән чыккан, инде алга таба дәвам итәргә, хәтта ки яшәргә дә көчләре калмаган чакта да... «Минем сиңа кадәрге гомеремдә син кайда идең?» дигән җөмлә саклый аларны. Әмма тора-бара бу җөмләнең мәгънәсе дә, каян килгәне ачыкланып, үз көчен һәм кадерен җуя. Инде ул да җуелгач, әле хисләренең башында гына Сьюзенның Полга әйткән сүзләре сакларга керешә яратуны:

«Согласись: мы – отработанное поколение. Лучшие ушли. Остались людишки мелкого пошиба. В этом суть любой войны. Поэтому теперь одна надежда – на твоё поколение».

Респектабельлек икенче киемгә әверелгән тормыш эчендә үзләренең ялангач хисләре һәм омтылышлары белән икәүдән-икәү калган бу гашыйклар безгә бүгенге тормыш шартларында берничек тә кузаллана алмаган Ләйлә белән Мәҗнүнне, Таһир белән Зөһрәне хәтерләтә. Аларны шушындый шартларга китереп куйсаң, ни булган булыр иде икән? Ипотека түләтсәң, бурычларга батырсаң, тормыш алып барырга кушсаң... Мәхәббәт романнардан укыр һәм Инстаграмдагы фотоларда матур итеп элеп күрсәтер өчен генә ярый хәзер, димәк? Ә бәлки, без аны ныграк кире каккан, танымаган саен, ул кайчандыр безне аулап алыр өчен хәстәрен көчлерәк күрәдер?

Пол белән Сьюзен тарихы, көтелгәнчә, аяныч тәмамлана, дияр кайбер укучылар. Юк, көтелгәнчә, рациональ һәм тормышчан. Әмма ул тыштан караганда гына – тәмамлана. Шундый зур көч, хис бер яндырып-көйдереп үткән икәү өчен тормыш – үзләре исәндә – беркайчан да тәмамлана алмаячак.

«Он подгонял жизнь под свой темперамент, она подгоняла свой темперамент под жизнь. Её путь был, конечно, более рискованным, поскольку сулил больше радостей, но не оставлял страховочной сетки... Страховочная сетка отсутствовала. В его воспоминаниях всегда возникал один и тот же образ. Она висит за окном, а он удерживает её за запястья, не в силах втянуть обратно, но и не позволяя ей упасть; две жизни замерли в мучительном ожидании...

Я и не подозревал, что её раздирает тревога. Откуда мне было знать? Я думал, тревога засела только во мне. Но теперь понял – к сожалению, запоздало, – что тревогой терзается каждый. Нам, смертным, от неё никуда не деться. У нас есть нормы поведения, помогающие унять её или притупить, есть шутки, заученные реплики, привычки и множество способов отвлечься и развеяться. Но в каждом из нас, я убежден, затаились смятение и тревога, готовые в любой момент вырваться наружу. Одних тревога подталкивает к Богу, других к отчаянию, одни с головой уходят в благотворительность, другие в пьянство, одни погружаются в эмоциональную отрешенность, а другие выбирают для себя такой образ жизни, который, по их мысли, ограждает человека от серьёзных потрясений».

Әмма бу – иллюзия. Асылда, роман кешеләрнең үзләре хакында булган иллюзияләрен анализлау һәм чәлпәрәмә китерү максатыннан язылган әсәр. Үзенә дә замандашларына да бу иллюзияләр артында яшеренеп яшәүнең ни дәрәҗәдә куркынычсыз икәнлеген бик яхшы аңлаган автор, аңлы рәвештә, әлеге адымга бара: менә хәзер, шушы урында ясалма битлекләрдән арындырмасаң, үз-үзенә туры карарга мәҗбүр итмәсәң, кешеләр инде... кеше булудан туктарга да мөмкиннәр. Җәмгыять безне роботлаштыру юлында һәм техник, һәм эмоциональ тәэсир итү ысуллары мәсьәләсендә көннән-көн камилләшә бара. Без дә аның артыннан кууны дәвам итикме, ди ул.

Һәм кешене кешегә якынайтуның, аңлашуга китерә алуның бернинди технократия, сәяси һәм иҗтимагый корылышта тәкъдим итә алмаган иң борынгы юлын тәкъдим итә – яратуны. «Возлюби ближнего своего» тәгъбиренең заманча вариациясе, дип ирония белән елмаерсыз, бәлки. Ә нишләп әле юк, ди? Юкса без, тәмам автоматлашып, бер-беребезгә булган риясыз ышанычтан бөтенләй мәхрүм калырга да мөмкинбез түгелме?

Һәрбер кешенең тормышы – эмоция-кичерешләр көрәше барган сугыш кыры түгелмени? Ә бит тормышлары эмоциональ күтәрелешләр һәм упкыннардан тормаса, роман каһарманнары «яшәгән» яссылыкта безгә бик тә күңелсез булыр иде. Язучының бурычы – бер үк вакытта серне сурәтләү дә, аны анализлау да. Персонажларның эмоциональ тормышына мөнәсәбәтем язу процессының үзенә булган кебек үк: мин аларга тулаем кереп тә күмеләм, шул ук вакытта үземне тыеп торырга да мәҗбүр булам. Минем әсәрләрем, гадәттә, автобиографик характерда түгел. Роман-тәүбә, роман-терапия кебек төрләргә гомумән ышанмыйм. Кайчакта үз тормышымда булган вакыйганы сюжет канвасында кулланырга мөмкинмен әле, әмма анысын да ул объектив рәвештә кирәк булганда, зур ихтыяҗ тудырганда гына. Һәм, аңлашыла ки, ул тулаем һичкем тарафыннан да танылырлык булмаса гына.

Джулиан Барнсның http://offtherec.org/ru/ сайтындагы әңгәмәсеннән.

PRESSA.RU

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНЫҢ ӘДӘБИ ПРЕМИЯСЕ

Реклама 16+

«Татарстан» журналының
Әдәби премиясе 2018

«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы һәм «Татарстан» журналы 2018 елгы Әдәби премиягә бәйге игълан итә.

«Татарстан» журналы әдәби премиясе Татарстан матур әдәбиятына сизелерлек өлеш керткән әдәби әсәрләр иҗат итүче авторларны барлау һәм иҗатларына игътибар итү максатыннан игълан ителде.

Премиягә түбәндәге жанрларда иҗат ителгән кульязмалар дәгъва итә ала: роман, повесть, хикәяләр циклы. **Әсәрләрнең Татарстан турында яки Татарстан авторы тарафыннан иҗат ителгән булуы һәм моңарчы беркайда да басылмаган булуы бәйгенең төп шарты!**

Кульязмалар Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә – русча һәм татарча – кабул ителә.

2018 ел дәвамында «Татарстан» журналы экспертлар советы тарафыннан сайлап алынган текстларны журнал битләрендә һәм журнал сайтында protatarstan.ru басылып барачак.

Гран-при – китабыгызның басылып чыгуы.

2018 елның декабрендә бәйгенең жюрие ике телдә иҗат ителгән әсәрләр арасыннан җиңүчеләрне сайлап алачак – татар телендә бер әсәр һәм рус телендә бер әсәр. Икесе дә китап булып басылып чыгачаклар.

Бәйгенең шартлары:

1. Кульъязманың электрон версиясе.
2. Номинант турында мәгълүмат – әсәр авторының фамилиясе, исеме, атасының исеме, контактлары – элемтә өчен телефоны, адресы).
3. Авторның кыскача иҗади биографиясе (әгәр әдәби әсәр берничә автор тарафыннан иҗат ителгән булса, һәрберсенеке).
4. Әсәрнең синопсисы.

Кульязма таләп ителгән материалларның тулы пакеты белән килмәгән очракта, жюри рәисе әсәрне кабул итмәскә хокуклы.

Кульъязмалар tatarstan@tatmedia.com электрон тартмасына «КОНКУРСКА» тамгасы белән кабул ителә.

Конкурсны үткәрү срогы: 2018 елның 19 мартыннан 2018 елның 15 декабренә кадәр.
Тулырак мәгълүмат protatarstan.ru сайтында.

КОНКУРСКА

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНЫҢ 2018 ӘДӘБИ ПРЕМИЯСЕ

Гөлүсә Шиһапова

Җанымны күбәләкләргә бирерсез...

Гөлүсә Шиһапова Чүпрәле районының Зур Чынлы авылында туа. Урта мәктәпне тәмамлагач, КФУның Л. Н. Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Г. Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлегендә укый. Хәзерге көндә магистратураның 2 курсында. Габдулла Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театрында эшли.

Бүген күк әфлисун төсендә. Әйтерсең, җирдәге төнге утлар, кояш булырга теләп, күккә сеңгән. Йолдызлар да, ай да күренми. Төнге күк аларны йоткан. Бүлмә тулы бушлык. Хастаханәнең ялгыз бүлмәсендә берәү ята. Бу ялгыз зур тәрәзә аша аның күзләре күк белән серләшә. Күк йөзе ялгызакның бердәнбер сердәше, дусты хәзер.

Бүлмәдә авыр дару исе, төн кара канга баткан, шул кара куемтыдан чыга алмый интегә. Хәрәкәтсезлек. Шыксыз диварлар да, аны үртәгәндәй, тын. Аларның кешеләрдән кала үз теле, үз серләре. Дивар телләрен өйрәнеп беткән бу адәмнең күктән башка аңлар кешесе юк. Кирәкми дә. Ул бит селкенә дә, сөйләшә дә алмый.

Дөнья миңа каршымы, мин дөньягамы? Җир мине үзен таптап йөрүне кимсенү дип белдеме? Мин йөри алмыйм. Мин йөгерә алмыйм. Чыклы үләннәренең салкынын, карның суыгын, яңгырның юешен, ташларның катылыгын тоя алудан мәхрүм. Мин сезнең белән тагын очрашырмынмы? Мин сезгә кирәкме әле? Сез миңа бик кирәк. Чишмәм, мин синнән саркып аккан суны, учларыма тутырып, салкын дулкыннарга чумасым килә. Елгам, синең яныңнан тагын атларның билләренә атланып, вакыт түшәлеп яткан болыннар, кырлар буенча үтәсем килә. Җил. Син мине үз кочагыңа кабул итәргә әзерме? Үйна минем чәчләрем белән, күренмәс зәңгәр кулларың белән сыйпа минем кулларны, назла минем йөрәкне. Җирем, мин синең буенча тагын бер тапкыр гына булса да атлап үтимче. Үтенеп сорыйм. Ташлама. Калдырма мине ялгызым. Синең кара туфрагыңны учка алып, шунда тәгәрисем килә, кырларыңа чумып йөзәсем килә минем. Бер мөмкинлек кенә бирче миңа. Мәхрүм итмә мине үзеңнән.

Бүлмәдә тын. Диварларга кагылып үткән тынлыкның гына пышылдавы ишетелә. Ул шуыша, чорный, буа. Бу бүлмәдә алар икәү генә. Ул һәм тынлык.

Син мине үзеңә кабул итәргә әзерме? Күрәм, әзерсең. Бәлки син мине инде үзеңнең колы дип уйлыйсыңдыр? Ә, юк, мин әле тере. Йөри, сөйләшә, хәрәкәтләнә алмасам да, уйлый алам. Уйлар, бетмәс-төкәнмәс уйлар минем ирегем һәм төрмәм дә. Әйе, тормыш мине сынап карарга уйлаган бугай. Ят, кара, уйла. Нәрсә уйларга, нәрсә уйларга тиеш мин? Ялгыз, караңгы, салкын дөнья минем дөньяны йотмасмы, минем ватылган күңелемне, тагын да кечкенәрәк кисәкләргә ватып, киптермәсме? Киптерелгән җаннарны кая асрыйлар икән? Берәм-берәм җепләргә элеп кояшка ашаталар микән? Хм, бәлки минем җаныма миһербанлырак булып, аның кисәкләрен күбәләкләргә өләшерләр? Бер көнлек гомерләре бераз озынаер иде. Мин дә чәчәкләрнең түмен тоеп, дөньяны нәни күзләр белән зу-у-ур итеп күрер идем. Канатларым булыр иде минем.

Мин йөри алмыйм. Мин хәрәкәтләнә алмыйм. Мин сөйләшә алмыйм. Тик мин оча беләм. Әйе. Минем канатларым бар.

Тәрәзә җанын тишкәләп бүлмәгә ай нурлары саркыла. Серле, хәйләкәр ай кызы. Хәзер бүлмәгә бер күз йөртеп чыгар да, тик кенә ятучы егетнең өстенә зур ялыгын салыр. Аннары уйларына керергә теләр. «Сиңа бүген яна төшләр алып килдем. Әйдә, сыен минем учларга, – дияр. – Мин сине син белмәгән, күрмәгән галәмнәргә алып барам. Син булдырасың. Бир кулыңны. Бир инде. Күзләреңнән күрәм: минем белән китәргә телисеңме...»

Диварлар серләшә, тынлык шуыша. Бүлмәдә хәзер өчәү. Ай, ул һәм чиксез тынлык чәе. Шул чәйне эчеп туйган бу күңел. Шикәрсез, тәмсез, төссез чәй. Чәйнегең кая соң синең? Бүлмәдә хәзер берәү генә. Тынлык. Ул тула бара, бүлмәне тутыра, иңли, кайната, сусата һәм янадан эчерә. Чәйнеге бар. Әнә хәрәкәтсез гәүдәдән төссез, шикәрсез, салкын чәй ага. Ул йоклый. Аның уйлары җаны белән бергә куллар тотышып ай кызы артыннан киттеләр.

Коч мине салкын җылылыгың белән, ай кызы. Тутыр минем күңелне. Тукта әле. Мин бит чынлап та күңел генә. Минем хәзер тәнем кая? Мин җан булып ай салган юлдан гизәм икән бит. Йолдызларга очасы иде. Тик күктәге йолдызларга карап җирдәгеләрне онытам бугай. Минем йолдызларым бер җепкә тезелеп мине өй каршында ук көтеп торалар. Минем юлыма да синең күз яшьләрең чык булып сибелгәндер, әнкәй. Синең бишек җырларыңнан минем канатларым үрелгәндер. Синең сүзләр белән минем җанымның ертык урыннарына бик күп ямау салынган. Бу җанны ничек итеп күбәләкләргә бирер идем мин? Синең кулларың кагылган урыннарда хәзер кояш күзәнәкләре. Мин кояш баласы, димәк. Ә нишләп сон мин моны иртәрәк, сәламәт вакытта анламадым. Мин бит табигатьне яратып, аның атларына атланып үз табигатемдә сәяхәт иткән кеше. Тик синең табигатең, әни, минекенән меңәр тапкыр матур һәм сокланггыч. Хәзер, ай кызына ияреп, мин кая барам? Бу минем күңелемне үзенең үләннәре белән бергә үстергән болыннар, минем күз яшьләремне үз яшьләре белән кушкан елгалар, кочагында минем күңелемне бишектәге шикелле тибрәткән кырларым. Сезнең җирләрегез буенча тагын чабып үтәсем килә.

Шәһәрнең салкын урамнарын күп таптаган аякларым җылы салкынлыкка тиделәр. Бармакларым туфракка күмелде. Суык булса да, рәхәт суык. Минем туган җиремнең рәхәтлеге. Тәнемне сыйпап җил җылымны кыр өстенә таратты. Минем җанымның бер өлеше хәзер кыр өстендә очып йөри. Ә мин башаклар арасында. Сары, тулган. Алтын башаклар минем аякларга үрелә. Алар минем белән бергә атлый. Минем адымнарга кушылып җир дә сулый бугай. Ә җир сулышына кушылып атларга җиңел миңа. «Кырым минем!» – диясем килә. Кочасым килә мин сине. Күңелем, йөрәгемнең чиксез куллары белән кочасым килә. Синең буенча йөгереп үтәргә миңа тагын бер рөхсәт бирерсеңме? Тәнеңдә кояш нурларының җылысын саклаган башакны яратам. Синең исең мине кытыклый. Мәңгелегем синең мәңгелек белән тоташа. Чикле дөньям синең чиксезлегеңне җиңәргә омтыла. Җүләр мин. Башаклар өстендә торган йолдыз кызлары миңа рөхсәт бирмәс. Үз мәңгелеңдә кал, үз чиклелегеңнең чикләрен җиң. Кырның төнгә буялган һавасы минем күкрәкне тишкәли. Ә миңа рәхәт. Хастаханәнең якты бүлмәсенең кара төсләрен, исләрен юып чыгар. Йөрәгемне пәрәвездән арындыр. Арындыр. Чистарт. Төнге йолдызлар таң йолдызын каршы алырга әзер. Мизгеллек очрашу. Пәрдә ачылырга бик аз вакыт калып бара. Болыннарга чык төшә. Кояш белән очрашырга теләгән йолдызлар бит болар. Менә бит кырларым, болыннарым, урманнарым яктырып китте. Җирдә меңләгән кояшлы йолдызлар. Шулар арасында мин – бердәнбер сүнәргә яткан йолдыз. Сүнәргә теләмим мин. Мин торачагыма ышанам. Ник? Төндә сүнгән йолдызлар иртән яңадан кайтты бит. Мин дә яңадан аякка басачакмын. Мин моңа ышанам. Чөнки миндә әнием биргән кояшлы җан, табигать салган чәчәкле күңел. Миндә – галәмнең үзе.

PRESSA.RU

Бүлмәгә шәфкать туташы керде. Тынлык шыпырт кына почмакка посты. Әфлисун төсе көндәлекнең соры төсе белән алмашынырга әзерләнеп бара. Бүлмәгә кояшка керергә тәрәзәнең киемнәре комачаулый. Нурлар аны тишкәли, тик диварларга җан кертә алмый инде. Аларда бихисап җаннарның соңгы сулышларының сурәте, соңгы сүзләр кайтавазы, соңгы караш буявы. Галәмгә күпме әйтелмәгән сүзләр, яратылып бетмәгән җаннар, кыйналып туйган йөрәкләр бу кечкенә дөньяның төрмәсендә калган. Шәфкать туташы үз эшендә. Бу авыруларны күреп күпме әрнегән йөрәге хәзер таштай каткан. Бу хатын диварлар шикелле. Диварлар.

Бүлмәдә өчәү. Шәфкать туташы, авыру һәм бушлык. Шәфкать туташы урынында яткан авыруга карады һәм бары йөри алмый торган авыруны гына күрде. Диварлар бары бер корбанны таныды. Бушлык беркемне дә тоймады. Чөнки бүлмәдә беркем дә, бернәрсә дә юк. Бушлык. Бары чиксез, аңлашылмас, тум-тулы бушлык.

Мин бит әле тере, мин бит әле уйлый, күрә, сулый алам. Минем канатларым бар хәзер. Мин үзем теләгән җирдә теләсә кайчан пәйда була алам. Дүрт дивар кочагында мин елмая алмыйм, ә монда елмаям да, көләм дә. Ә тормышта мин яңа көнгә, яңа төнгә җитәрлек елмайдыммы? Һәр мизгелгә рәхмәтле идемме мин? Хәзер барысын да аңлыйм. Күп кешене кыерсыттым, кыерсытылуым да җитәрлек. Гафу үтенәм. Хәзер гафу үтенәм. Соңга калдыммы? Соң түгел, әле яшибез икән, бер дә соң түгел. Мин түзем булдым. Миңа карата да түзем булуыгызны сорыйм. Үтенәм. Мин бит рәсем ясарга ярата идем. Нигә ташладым ул шөгылемне? Ә, миңа зур түләүле эш тәкъдим иттеләр. Тик ул мине бәхетле иттеме? Юк. Мин бары үз дөньямны сусаттым, корыттым. Акча бәхет бирмәде. Шуның аркасында монда эләктем дә мин. Хәзер пумаланы аласы һәм ак болытларда биетәсе иде.

Бушлыктан галәм ясыйсың. Тынлыктан көйләр үрәсең. Төссезлектән төсләрне сорасың. Синең күңелдән дөнья үз төсе, исе, тәме белән ага. Тәмләп ага. Йөрәгеңне үз күңеленә төрергә дип ага. Төсләре белән сине буйый, исләре белән сине тибрәтә, тәме белән сине татып карый. Карасаң, үз сурәтеңне, күңелеңне болытларның йөзенә ясап куйгансың. Кызык. Хәзер мин болытлар аша карап торам, яңгыр булып җиргә явам. Мин күкрим, мин яшьним. Мин – яшим.

Яңгыр булып мин күбәләкләр канатына явам. Хәзер мин дә күбәләк була алам. Зур җанның кечкенә кисәге. Менә кайда ирек, менә кайда тормышны аңларга омтылу. Үзеңнең тормыш җебең бары ике көнлек икәнлеген генә белү булган вакытны файдалы үткәрергә этәрә икән. Шуңа күрә күбәләкләр чәчәкле дөньяда яшиләр ахрысы. Тормышның матурлыгын татып, татлы сулар эчеп көн итәләр. Күбәләкләр үлер өчен туалар дигәнне ишеткәнем бар. Юк, алар дөньяны ямьләндерү өчен туган. Алар – җанның үлемсезлеге. Кошлар сайрый, хайваннар да үзенчә сөйләшә, ә менә күбәләкләр тавыштан мәхрүм. Бәлки шулай җиңелрәктер дә. Артык сүзләр нигә кирәк. Йөрәк белән дөньяны күрергә, тоярга омтылу, сүзсез ярату. Бар нәрсә дә дөрес, бар нәрсә дә үз урынында. Алар кебек яши, ярата белсәк иде.

Күбәләкләр бии... Һәр мизгелне кадерләп, һәр чәчәк таҗына басып, алар белән исәнләшеп бии. Назлы, нәзакатьле, самими. Тик көчле. Үзеңнең берничә көн генә бу кояш белән булуыңны белеп яшәү өчен нинди көч кирәк аларга. Миңа да шундый көч кирәк. Минем җанымны күбәләкләргә бирерсез. Эчкерсез сипкелле бер күбәләккә. Бер тәндә бергә яшик. Нечкә җанның нечкә кыллары. Саф йөрәкнең саф хыяллары. Яшәргә омтылыш. Яшәү теләге. Ярату көйләре. Ямьлелек рәхәте. Бергә үрелик аның белән. Минем сүзләр, күбәләк хыяллары. Минем көчсезлек һәм күбәләк көче. Минем көчем һәм күбәләкнең нечкәлек катыш йомшак күңеллелеге. Мин – оча торган чәчәк.

Кояш бүлмәләрне җылытырга омтыла. Салкынга туенган кечкенә галәмне белми әле ул. Ничә еллар буе җылынмаган бүлмәне бүген генә җылытуы икеле. Шуны аңлап бугай, кояш нурлары тәрәзә янына таба шуыша башладылар. Көн буе бушлык белән көрәштеләр бит. Тик тышкы нурлар гына җылытмас дөньяны. Бушлык карашын да, тынлык сулышын да, диварлар серләрен дә.

Бүлмә тула башлады. Нindидер үзгәреш бар. Тынлык шикләнә, бушлык курка, диварлар тына.

Бүлмә көй белән тулды. Чәчәкләр көе. Оча торган күбәләкләр көе. Ябык тәрәзәләрне җил ачты. Тынлык та, бушлык та чыгып качтылар. Диварлар да качар иде, үз-үзеңнән качып булмый шул. Аларга күңелләрен бикләргә генә кала.

Тәрәзә пыялаларын эретеп бер күбәләк килеп мендәр янына кунды. Канатларында әллә яңгыр, әллә чык, әллә яшь тамчылары. Төссезлектән барлык төсләр савылып бетте. Алар бүлмәне күбәләк канаты төсенә буядылар. Караватта ятучының иреннәрен күбәләкнең төсләре көйдерде.

Бүлмә туп-тулы. Монда ничә, күпме дигән сорау урынлы түгел. Кайнар, тәмле, төсле чәй кайнап чыгарга тора. Тынлык та рәхәт, җылы.

Күбәләкләр бии, чәчәкләр әйләнә бүлмәдә. Галәм бүген үз чиксезлеген бүлмә чиклелегенә сыйдырган. Йолдыз кызлары да чиксез булырга рөхсәт иткәндәй күбәләк канатына кунган. Ә ул яткан. Хәрәкәтләр сизелми. Бары сулышы гына күбәләкләрне биергә мәҗбүр итә.

Мин әле яшим, биим, уйлыйм, сулыш алам, яратам. Мин әле кайтам синең янга, кояшлы әнием, очрашабыз әле без болыннарым, кырларым, елгаларым. Мин хәзер аңлыйм. Күбәләкне. Бушлык һәм тынлыкны. Мин оча беләм. Һәм очам.

Күбәләкләр бии, чәйнек кайнап бүлмәне тәмам тутыра башлады. Шәфкать туташы кереп көндәлек эшләрен башкарды да һәркөндәгечә хиссез, игътибарсыз чыгып та китте. Ул сизмәде. Ятакта ул бары тормышның явыз карары буенча хәрәкәтләнә алмаучы мескенне күрде. Тәрәзәдән соры көндәлек аңа акайды. Шул ук диварлар, пыяла, ятак. Бәхет көткән бу ханым бәхетен табуга өметен өзә башлаган күрәсең. Битараф. Көндәлек тормышы аның күңелен кимереп, калдыгын ялгамыйча, ташлап калдырган. Бәрәкәт таба алмый ул. Җаны сәяхәт итә белми.

Ә бүлмә исә... ятактагы мескеннең күңеле белән тулган. Ә бүлмәдә күбәләкләр бии. Ул бии. Ул яши. Йөзен бик күптәннән шәйләнмәгән самими бәхетле елмаю бизи аның.

Бүген күк тә зәңгәр төстә...

МАХСУС ПРОЕКТ

31нче чыгарылыш

Татарстан юбилярлары

PRESSA.RU

Рифнур СӨЛӘЙМАНОВ,
«Татэнергосбыт» АҖ директоры,
апрельдә 55 яшьлеген билгеләп үтә.

«АЧЫКЛЫК» – АҢЛАШУ ГАРАНТИЯСЕ

Барысына да ничек өлгерүен аңлатыр өчен, «Татэнергосбыт» АҖ директоры Рифнур Сөләйманов һәр сәгате бүленгән атналык планын күрсәтә. Таңнан тору гадәте авылда үткән балачактан калган. Эш көне башланганчы ук, директор кабинетында почтасын тикшерә, бүген эшләнергә тиешле бернәрсәне дә иртәгә калдырмыйча, көн тәртибенә төзәтмәләр кертә һәм, һичшиксез, әнисенә шалтырата – аның да хәлләрен белешә, үзе турында сөйләп тә тынычландыра.

БАЛАЧАКТАН СЕҢГӘН КЫЙММӘТЛӘР

Йомшак, салмак тавышын һәм аралашуда ачыклыгын, ярдәмгә мохтаҗларга булышу омтылышын ул туган авылы Акъярдан ук алып килгән, матур җирдә эшләүче гүзәл кешеләрне ул әледән-әле юксынып исенә төшерә. Якташларын ул «хезмәт сөючән һәм намуслы» халык дип тасвирлый.

Ярты гасыр буе мөгаллимлек иткән мәктәп директоры Әсхәт абый Шәриповны, республика прокуроры урынбасары авылдашы Газинур Галимовны «дөрес, принципиаль кешеләр», үрнәк алырлык шәхесләр дип искә ала: «Мин Казан финанс идарәсе башлыгы булган чакта ул миңа һәр квартал саен күрсәтмәләр җибәрә иде, мин исә, депутатларга һәм администрациягә болай эшләргә ярамаганлыгын аңлатып, хилафлыкларны төзәтәм. Әлеге күрсәтмәләр булмаса, бәлки, житдирәк финанс бозулар килеп чыгар иде». Ул үзе дә шулай эшли, төрле төгәлсезлекләрне вакытында ачыклап, үзе тикшергән бөтен кеше, бөтен оешмалар белән дустанә мөнәсәбәтләрне саклап калырга тырыша: «Дөреслекне дусларның да, җитәкчеләрнең дә йөзенә бәреп әйтергә кирәк, ялган исә барыбер кайчан да булса фаш ителә», – ди ул.

Ул тормыш юлын этапларга бүлми: һәр вазыйфасында кыенлыклар да, казанышлар да җитәрлек булган. Казандагы бер зур предприятиенең вакытында салым түләмәгән генераль директоры белән ничек танышуын болай исенә төшерә: «Мин аңа дәгъва белдердем. Ул Сабан туенда башлыкка миннән зарланган, әмма салымны түләде. Әгәр барысы да закон буенча эшләнә һәм яхшылап төшендерелә икән, кеше бик тиз аңлый ул». Иң мөһиме, вөҗданына хилафлык китермәгән, һәм карьера баскычыннан һаман югарыга аннан сорап тормый гына күтәргәннәр: «Салым инспекциясендә инспектор булып эшли башладым, һәр елны бер баскычка күтәрәләр иде: өлкән, баш инспектор, бүлек мөдире урынбасары, бүлек мөдире, инспекция башлыгы. Күрәмсең, минем эш нәтиҗәләрем канәгатьләндергәндер».

Моннан алты ел элек «Татэнергосбыт» АҖ җитәкли башлагач, чирек гасыр буе финанслар белән идарә итү дәүләт структураларында эшләгән Рифнур Хәйдәр улы электр энергиясе һәм куәтләрен күпләп сату базарында катнашучыларның хокукларын һәм бурычларын өйрәнергә, үзкыйммәткә калькуляция ясарга тотына. «Ә башкача булмый бит. Салым инспекциясендә, Казан финанс идарәсендә, Финанс министрлыгында эшләү тәҗрибәмнең, әлбәттә, кирәге чыкты. Әмма мин бит энергетик та, бухгалтер да түгел, ә бәлки икътисадчы, шулыктан күпләп сату базары, челтәр схемага мөнәсәбәтле нигез, бухгалтерия – минем өчен яңа, таныш булмаган дөнья, шуңа мин барысына да өйрәнергә тырыштым», – ди Рифнур Хәйдәр улы.

Укый, өйрәнә белә ул. Балачактан калган иң җылы хатирәсе: «Кайбер сабакташларымның әти-әниләре җыелышка курка-курка гына барса, минем әнием исә, улын тагын мактаячакларын белеп, рәхәтләнеп бара иде». Аның бу турыда ничек сөйләвен ишетергә кирәк: сәләте белән мактанмыйча, әнисен кайгыга салмавына бүген дә сөенеп искә ала ул мәктәп елларын. Студент чакта да тырышкан, дуслары да күп булган: бергә күңел дә ачканнар, бергәләшеп төнлә акча да эшләгәннәр – Казан йортларының түбәләреннән кар көрәгәннәр.

Кешеләр белән эшли белү талантының салым инспекциясендә дә, мэриядә дә, министрлыкта да кирәге чыккан. Аны хәзер дә элек эшләгән җирләрендәге хезмәттәшләре корпоратив һәм юбилейларга еш чакыра.

«Татэнергосбытта» Сөләйманов, үз тәртипләрен кертеп, кадрларның үзгәнә үтмәгән. Анда кешеләр арасында урнашкан мөнәсәбәтләрне үзгәртмәгән. Барысын да сабыр гына тыңлаган, белмәгән нәрсәләрен сораган. «Мин процессның ничек баруын аңлатуны сораудан оялмыйм. Коллектив мине яхшы каршы алды, һәр бүлекнең эше, эшчәнлекнең һәр юнәлеше турында төпле итеп сөйләделәр...» – дип искә ала Рифнур Хәйдәр улы.

Аның үзенең дә контрагентка, кулланучыга, хезмәткәренә дәгъваларының асылын тәфсилләп һәм аңлаешлы итеп төшендерергә оялмавы мөһим, бу вакытта ул законга таянса да, кешенең хәленә дә керә белә.

Ул үзенең хезмәткәрләрен дә электр энергиясен кулланучылар белән шундый мөнәсәбәтләр урнаштыруга этәрә. Нәтиҗә – түләүләрнең 99 проценты җыелуы. Ә югыйсә бит әле алты ел элек кенә идарәче компанияләрнең электр энергиясе өчен бурычлары 500 миллион сумнан арткан була...

БАШКАЛАРДАН АЕРМАЛЫ

Бүген «Татэнергосбыт» АҖ 2017 елда «ЭнергоНьюс» МА конкурсы нәтиҗәләре буенча «Россиянең иң яхшы энергия сатучысы» исемен йөртә.

Фото «Татэнергосбыт» АҖнән алынды

Реклама

Директор кебек үк, кулланучылар белән багланышларында компания дә финанс мөнәсәбәтләренең мөмкин кадәр ачык булуын кайгырта. Электрон документ әйләнешен кертү белән 36 мең клиент-юридик зат барысы да диярлек шуңа күчкән. «Татэнергосбыт» – Россиядәге бушлай электрон-санлы имза алу мөмкинлеге бирә торган уникаль компания.

Кулланучылар әйтүе буенча, компания порталындагы Шәхси кабинет – шундый төрдәге сервисларның иң уңайлысы. Конкрет көндә һәм сәгатьтә файдалы бәяне мөстәкыйль билгеләргә теләүчеләр өчен сайтта калькулятор урнаштырылган, анда вак, урта һәм эре кулланучылар өчен электр энергиясе бәясен сәгатьләп исәпләп була. Аерма шактый. Мәсәлән, ял көннәрендә электр энергиясе шактый арзанрак. Һәм җитәкчеләр җитештерү графикларын шуңа җайлап төзергә омтыла – энергия күп таләп итә торган станоклар бәя кыйммәтлерәк чакта тик тора, арзанрак вакытта гына эшли.

Транспарентлыкны (мәгълүмати ачыклыкны) арттыру өчен, электр энергиясенә бәянең ничек билгеләнүен директор һәр кулланучы шәхсән үзе аңлатырга әзер: «57% – электр энергиясе һәм егәрләрне күмәртәләп сату бәясе, 41% – аның челтәрчеләр тарафыннан тапшырылуы, сату исә – 2%. Аны сата торган компанияләрне никадәр сайласаң да, файдасы юк диярлек, вакыт кына сарыф ителә». «Татэнергосбыт» тасату өчен өстәмә күләме республиканың тарифлар буенча комитеты тарафыннан көйләнә, һәм бу бүген Россиядә иң арзаннардан берсе.

Тәэмин итүче статусы «Татэнергосбыт»ны үзенә мөрәҗәгать иткән һәр кулланучы белән килешүләр төзергә мәҗбүр итә. Һәм аларның барысы да, зурлыгы-кечкенәлегенә карамастан, электр белән ышанычлы тәэмин ителә, югары дәрәҗәле сервис һәм тарифлар билгеләү шартларының ачыклыгы гарантияләнә.

Бурычлылар белән эшләү – аерым тема һәм шулай ук үзара аңлашуга нигезләнә: «Без 2–3 айдан артыграк түләмәүчеләргә генә пеня билгелибез, – ди директор. – Кешегә бурычын түләр өчен вакыт бирәбез». Законда каралган штрафларны, өзүләрне һәм мәҗбүри түләтү буенча судлашуларны кулланыр алдыннан (соңгы чара буларак кайчак алар да файдаланыла) бурычлыларга SMS җибәрәләр, бурыч күләмен исенә төшереп һәм җәза турында кисәтеп шалтыраталар, өлешләп түләүне, гарантия хаты тәкъдим итәләр. Әңгәмәдәшебез фикеренчә, килешеп була: «Элегрәк, өзәрләрме-юкмы, дип көтәләр иде, хәзер беләләр – түләмәгән очракта өзәргә тулы хакыбыз бар. Әмма кеше түли алмау сәбәбен аңлатып хат яза икән, хәленә керергә тырышабыз».

Сөләймановның иманы камил: күпфатирлы йортта гомумйорт ихтыяҗларының (ОДН) нәрсәдән җыелуын хәтта әбиләргә дә аңлатып була, тик хокукый формулировкалар белән түгел, гади телдә төшендерергә кирәк. «Таләпләрнең асылын һәм законлылыгын аңласа – түләячәк. Әгәр карардан өземтә белән хат кына җибәрсәң – укып та тормаячак».

ПЛАНЛАШТЫРУ ОФЫКЛАРЫ

«Татэнергосбыт»ның партнёр буларак ышанычлылыгы кулланучыларда да, республика җитәкчелегендә дә шик тудырмый. Шунлыктан ТР Президенты тәкъдиме белән 1 гыйнвардан аның нигезендә республика Бердәм исәп-хисап үзәге эшли башлаган. ТР Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар комитеты әгъзасы буларак, Рифнур Сөләйманов түләүләр системасын унификацияләү зарурлыгын күрә һәм моны ничек эшләргә кирәклеген белә.

Бүген 43 район кулланучылары (Чаллы һәм Казанны гына колачлыйсы калган) бер сервердагы бердәм клиентлар базасына берләштерелгән. Хәзер бер фатирга төрле идарәче компанияләрдән элекке кебек икешәр квитанция килми. Бердәм квитанция буенча электр энергиясе, су белән тәэмин итү, канализация, җылылык өчен түләүләр, идарәче компаниягә эләгеп тормыйча, махсус программа буенча шундук товар яки чимал белән тәэмин итүченең счетына бара.

Бердәм исәп-хисап үзәге аша түләүләр казначылык аша үткән кебек булена – көн саен турыдан-туры үзләре барырга тиешле җиргә китә, әмма шул ук вкытта контрольдә дә тотыла: башкаручы акчаны хезмәт күрсәтелгәч яки товар яки чимал белән тәэмин ителгәч кенә алырга мөмкин. Бердәм исәп-хисап үзәге исә хезмәт күрсәткән өчен үзенең процентын гына ала.

Процесс ачык, һәм, директор әйтүенчә, кулланучылар да, тәэмин итүчеләр дә, тиешле программага кереп, акча үткән юлны күзәтә ала.

«Гомумән алганда исә, – дип хыяллана әңгәмәдәшебез, – электрон түләүләр системасын болай үстерү яхшырак: һәр клиентның үзенең аңлаешлы интерфейслы шәхси кабинеты булсын, шуның аша ул финанслары белән бәйле барлык компания һәм хезмәтләргә чыга алсын. Төрле ведомство сайтларына күчеп тормыйча, барлык түләүләрне, шул исәптән, мәсәлән, салымны да бер кабинеттан башкарырлык булсын иде ул».

Сөләйманов фикеренчә, бүген компания өчен иң мәшәкатьлесе һәм иң кирәклесе – исәп-хисап үзәкләре кушылу белән икеләтә арткан персоналны укыту: «Сайт аша да, биредә дә кварталга бер тапкыр персоналны укытабыз. Аралашу психологиясенә дә, шул исәптән корпоратив рухына да өйрәтәбез. Биредә хезмәткәрләребез таныша, аралаша, чөнки хәзер алар – зур коллективның бер өлеше бит».

Хезмәткәрләр өчен директор кабинетының ишеге киңәшмәләр вакытында гына түгел, гел ачык. Анда ул үзе сөйләргә яратмый, тыңлауны артыграк күрә, аннары ишеткән идеяләреннән аеруча дәлилләнгәнен хуплый.

ТР һәм РФ атказанган икътисадчысы Рифнур Сөләйманов хезмәт юлында күп тапкыр медальләр, Президент, Премьер-министр һәм республика хөкүмәте, Казан мэрының рәхмәт хатлары белән бүләкләнгән. Ул – «Ел җитәкчесе» бәйгесе җиңүчесе.

55 ел гомер артта калган. Нәтиҗәләре белән горурланырлык эше, тату гаиләсе, ышанычлы фикердәш дуслары бар... Алда – өметле киләчәк. Компаниянең урыннардагы белгечләрдән ай саен икешәр-өчәр йөз тәкъдим кергән идеяләр банкы – эшне яхшырту, камилләштерү, оптимальләштерү өчен тормышка ашыруны көткән яңа бурычлар ул.

PRESSA.RU

Эдвард Абдуллаҗанов,
КДЭУ ректоры

Уңышыгызның нигезе – тәҗрибә һәм зирәклек

Хөрмәтле Рифнур Хәйдәрович!

КДЭУ җитәкчелеге һәм коллективы Сезне чын йөрәктән юбилеегыз белән котлый! Сезгә чын күңелдән тормышыгызда һәм эшегезгә һәрвакыт уңышлар юлдаш булуын телибез.

Сез бүген гомерегезнең тәҗрибә, зирәклек һәм тормышны белү белән гармонияле рәвештә ярашкан иң нәтиҗәле баскычында торасыз – инде бик күп эшләр эшләнгән, ә киләчәк өр-яңа планнар белән тулы.

Тормыш тәҗрибәгез һәм һөнәри эшчәнлегегез сайлаган юлыгызда максатчанлык һәм тугрылыкның ышанычлы билгесе булып тора. Сез җитәкчелек иткән зур предприятие энергетика өлкәсендә әйдәп баручы позицияләрне били. Сезгә хас профессиональлек һәм бай тәҗрибә мөһим оештыру эшләрен хәл итәргә булыша, һәм башлыча Сезнең компетентлылык һәм энергия нәтиҗәсендә предприятие динамик үсештә исәпләнә һәм үзенең данлы традицияләрен арттыра бара.

Күп еллар дәвамында Сезнең предприятие базарда әйдәп баручылардан берсе булып тора. Профессионалларның биниһая зур тырышлыгы, җитәкчелекнең таланты һәм тәҗрибәсе, уртак хезмәт фидакарьлеге лаеклы танылу өчен нигездер. Безне үзара ныклы партнёрлык мөнәсәбәтләре бәйләп тора, моның белән чиксез горурланабыз. Мондый мөнәсәбәтләр Россия энергетикасын үстерүгә, аның дөнья базарындагы позицияләрен ныгытуга ярдәм итә. Сезгә чын күңелдән ныклы сәламәтлек, какшамас оптимизм, бетмәс-төкәнмәс физик һәм иҗади куәт, уртак эшебезнең иминлеге һәм чәчәк атуы хакына яңа казанышлар телибез. Сезгә ихлас күңелдән ныклы сәламәтлек, яңа һөнәри уңышлар һәм иҗади табышлар теләп калабыз!

Фото КДЭУ матбугат хезмәтеннән алынды

Реклама

Азат Җаббаров, Федераль дәүләт теркәве, кадастры һәм картографиясе хезмәтенең (Росреестр) ТР буенча идарәсе җитәкчесе – ТРның баш дәүләт теркәүчесе, апрельдә үзенең 60 яшьлеген билгеләп үтә.

Фото «Грань» ЖЧЖнән алынды

Леонид Анисимов,
«Грань» ЖЧЖ
генераль директоры

Сезнең хезмәт эшчәнлегегез – югары профессиональлек үрнәге

Хөрмәтле Азат Галимҗанович!

«Грань» төзелеш компаниясе коллективы һәм шәхсән үз исемемнән юбилеегыз уңаеннан ихлас котлавыбызны кабул итегез!

Сезнең югары профессиональлегегез, оештыру сәләтегез, командада эшли белүегез белән бәйле таләпчәнлегегез һәм тәвәккәллегегез, җир законнары мәсьәләләрендәге тирән белемегез Федераль дәүләт теркәве, кадастры һәм картографиясе хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән уңышлы җитәкчелек итәргә мөмкинлек бирә, күзгә күренерлек үсеш нигезе булып тора.

Сезнең тырышлык нәтиҗәсендә гариза бирүчеләргә хезмәт күрсәтүдә максималь уңайлы шартлар тудырылган, эшнең заманча ысуллары кертелгән, күчемсез милеккә һәм аның белән эш йөртү хокукын теркәү процессын гадиләштерүгә юнәлтелгән өстәмә хезмәтләр барлыкка китерелгән.

Җиргә хокук мөнәсәбәтләрендә катнашучыларның хокукларын тәэмин итүне югары дәрәҗәдә оештыру Татарстанда тормыш сыйфатын һәм дәрәҗәсен күтәрүгә, Россиянең перспективалы эшлеклелек һәм мәдәни үзәкләреннән берсе буларак, субъектның статусын ныгытуга һәм шулай ук киң җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итүгә булыша.

Хөрмәтле Азат Галимҗанович! Сезгә чын күңелдән сәламәтлек, җаваплы хезмәтегездә уңышлар, бүгенгедәй нәтиҗәле хезмәт, энергия, позитив һәм билгеләнгән проектларыгызның тормышка ашуын телим. Сезнең эшлеклелек сыйфатларыгыз алга таба да катлаулы һәм мөһим бурычларны уңышлы хәл итәргә булышсын, янәшәгездә һәрвакыт тугры дусларыгыз һәм фикердәшләрегез булсын!

«Инженер-төзелеш эзләнүләре» ЖЧЖнән алынды

Юлия Хәмитова,
«Инженер-төзелеш эзләнүләре» ЖЧЖ
генераль директоры

Республика халкының уңайлыклары өчен

Хөрмәтле Азат Галимҗанович!

«Инженер-төзелеш эзләнүләре» ЖЧЖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне 60 яшегез тулу уңаеннан чын күңелдән котлыйм! Сезнең Татарстан белән аерылгысыз бәйләнештә булган тормыш юлыгыз зур ихтирамга лаек. Сез җитәкчелек иткән Федераль дәүләт теркәве, кадастры һәм картографиясе хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе эшчәнлеге республиканың һәр кешесенә һәм предприятиесенә кагыла, дисәң дә була. Бу гражданнар алдындагы зур җаваплылык турында сөйли. Һәм, әлбәттә инде, Сезнең һөнәри осталык, булдыклылык һәм инициативалылык турында да. Бүген Федераль дәүләт теркәве, кадастры һәм картографиясе хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан, башлыча Сезнең тырышлык нәтиҗәсендә, республика халкына хезмәт күрсәтү өчен максималь уңайлылыклар тудырылган, күчемсез милекне һәм аның белән эш йөртү хокукын теркәү процессын гадиләштерергә һәм хәвефсез итәргә мөмкинлек бирүче заманча яңа эш методлары кертелә бара. Ведомствоның төгәл, профессиональ эше республика халкына һәм предприятиеләренә күрсәтелә торган хезмәтнең сыйфатын тагын да яхшыртырга мөмкинлек бирә.

Сезгә барлык башлангычларыгызда да уңышлар телим. Яңа проектларны тормышка ашырганда бетмәс-төкәнмәс энергия юлдаш булсын, эшегезнең лаеклы нәтиҗәләренә ирешегез. Шәхсән үзегезгә һәм гаиләгезгә иминлек телибез!

PRESSA.RU

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

Реклама 16+

WWW.PROTATARSTAN.RU

Фото: Ната Смирнова, Илдар Мөхәтдинов

«Татарстан» журналы үзенең апрель фототезислары белән озакка сузылган кыш тудырган канәгатьсезлекне куып таратырга ашыга. Һәр елның апрелендә без Татарстанның «апрель» авыллары, ягъни үзенең исеме, кайчандыр булган мөһим вакыйгалары белән нәкъ менә апрель аена бәйле салалар буйлап сәяхәт итәбез.

Бүген алар барысы да сезнең хозурыгызда – карлы апрель аенда муеннан карга чумган мәлләрендә.

ТАТАРСТАННЫҢ АПРЕЛЬ **ФОТОТЕЗИСЛАРЫ**

PRESSA.RU

2011 ЕЛНЫҢ 12 АПРЕЛЕ

ИСКЕ ТӘКМӘК. ЗӘЙ РАЙОНЫ.

Космик нокта. Татарстан тарихына «космонавтлар» – Чернушка исемле маэмай һәм тычкан белән бакаларның тулы бер компаниясенең төшеп утырган урыны буларак кереп калды. 1961 елның мартында, Юрий Гагаринның галәмгә очышына бер ай кала, Самара өлкәсенә төшәсе урынга алар бирегә ялгыш төшеп утыра.

Шуннан бирле һәр апрель саен Иске Тәкмәккә халык агыла. Журналистлар – Чернушка дигән космонавт турында тыңларга, ә түрәләр һәм ГТХМ коткаручылары – алда торган язгы ташуны кисәтү максатыннан.

«Татарстан», №4, 2011

PRESSA.RU

2010 ЕЛНЫҢ 22 АПРЕЛЕ

ЛЕНИНИЗМ. МИНЗӘЛӘ РАЙОНЫ.

Апрель аенда, күңелгә «язлар килә, язлар, кайта киек казлар» дигән җыр юллары килгәндә, СССРда туып-үскәннәрдә сагыну хисләре бигрәк тә көчәя. Ни өчен дигәндә, табигатьнең кышкы йокыдан уянган мәлендә бар халык дөнья пролетариаты юлбашчысы – Владимир Ленинның туган көнен бәйрәм итә иде. Удар хезмәт белән – шимбә өмәләре һәм торак пунктларга яңа атамалар бирү кебек чаралар уздырып. Владимир Ленин исемен йөртүче авыллар бөтен ил буенча иксез-чиксез иде. Менә, мәсәлән, Ленинизм... Әмма без аны таба алмадык. Аның эзе Тупач авылында югалган. Безнең эзләнүләребез белән кызыксынган бер төркем авыл ирләре Ленинизмның кайчан юкка чыгуын исләренә төшерергә тырыштылар.

– Ленинизм коммунизм вакытында таралды бугай, – дип, безне ышандырырга тырышты арадан берсе.

– Кит инде, социализм вакытында ук юк иде инде ул, мин әле яхшы хәтерлим, – дип бәхәсләште икенчесе.

– Сталинизм вакытында оешты, социализм чорында таралды, ә менә Маёвка социализмга кадәр түзде, – дип төгәллек кертте өченчесе.

– Ленинизм сталинизмга кадәр булды бит! – дип ярсыды дүртенчесе.

Менә шулай, эпохаларны уңга-сулга йолыккалап, без бүген эзләгән торак пунктны искә алдык: авыл юк, Ленинизм юк, кайтыр юлга борылыр вакыт җитте. Кызганыч.

«Татарстан», №4, 2010

PRESSA.RU

2017 ЕЛНЫҢ 22 АПРЕЛЕ

ЛЕНИНО-КОКУШКИНО. ПИТРӘЧ РАЙОНЫ.

Совет чорында әлеге очсыз-кырыйсыз юл буйлап октябрятларны автобусларга төяп алып килгәннәр дә кире алып китмәгәннәр, дип сөйлиләр. Ләкин мәктәп укучыларының әлеге төренең массакүләм рәвештә юкка чыгуы турында бер генә ата-ана да милициягә хәбәр итмәгән. Бәлки, шәһәргә кире автобус тулы кызыл галстук таккан пионерлар кайткангадыр, ә алмаштыруны абайламый калган ата-аналар әлеге төр мәктәп укучыларын үзләренеке дип кабул иткәндер.

Совет чорының бу күптәнге серен ачу теләге белән без аның үзәге – бөтендөнья пролетариаты юлбашчысы Владимир Ульяновка бабай туры килгән алпавыт Александар Дмитриевич Бланк йортына юл тотабыз. Әле Ленин булып өлгереп җитмәгән яшь Ленин биредә бик еш кунак булган, хәер, беренче сөргене дә шушы утарда үткән аның.

Бланк утарында яшәүчеләр инде күптән бакыйлыкта. Ә Ленино-Кокушкино алар турындагы истәлекләрне һаман саклый. Сакларлыгы да бар. Совет чорында аерым пионер игътибары булганга, авыл бүген дә зур һәм бай булып яшәвен дәвам итә.

«Татарстан», №4, 2017

ЧҮТИДӘ БУЛДЫМ ӘЛЕ!

Язгы сәфәрләрне аеруча яратам: юл буе йокыдан яңа уянган табигатькә сокланып барасың. Ә өер-өер очып кайткан кыр казларын күрсәң, сабый бала кебек сөенәсең. Кайбыч районы Чүти авылына барганда да әнә шундый күңелле, гаҗәеп манзараны күреп кәефләндем. Яз исе сеңгән авылга килеп кергәч, бер биш минут күкрәк тутырып саф һава суладым. Әйтеп, аңлатып бетергесез рәхәтлек!

Автор:
Руфия Фазылова

ЧҮТИ КЕМНӘРЕ БЕЛӘН ДАНЛЫКЛЫ?

Чүти авылына баруыбызның төп сәбәбе – Шәкүр карак булды. Данлыклы ат карагы, татар риваятьләренең каһарманы булган бу кеше турында күпләр хәбәрдар дип уйлыйм. Бөтен тирә-як районнарны, Ульяновск, Түбән Новгород өлкәләрен дер селкетеп торган ул. Ат урлаудан кала, кибетләр, складлар да баскан. Әлбәттә, Шәкүр карак үзе генә эш йөртмәгән. Аның өерендә йөзләп кеше булган. Шуларның берничәсе бик якыннары саналган.

– Шәкүр карак Чүти авылында туган. Ә менә бабалары чыгышы буенча Мордовия якларыннан, – дип сөйләде әлеге авылның тарихын өйрәнгән Василий Уткин. – Шәкүрнең нәселе дә, ягъни ата-бабалары да гомер-гомергә ат урлап сатып көн күргән. Мордовиядән безнең якларга килеп чыгуларының да сәбәбе шуның белән бәйле. Атларны алар бу тирәләрдә саткан. Мордовиядә кыса башлагач, алар Чүти авылына күченгән. Зур татар авылы, Чувашия белән чиктәш, Мәскәү юлына да якын бит.

Шәкүр каракны чүтилеләр аерым бер горурлык белән дә искә ала: «Безнең авыл кешеләренә тимәгән ул», – диләр. Бүгенге көнгә кадәр авылда, Шәкүрнең төп нигезендә, зур булмаган йорт тора. Аны үз вакытында, Шәкүр каракның нигезе югалмасын дип, колхоз салдырган. Йортка әле дә Шәкүрнең туганнары кайтып йөри икән.

Бүген Шәкүр карак турында төрле фикерләр йөри: кемдер аны ярлыларга тимәгән, байларны гына баскан, дип сөйли. Ягъни ул, әгәр шулай әйтергә мөмкин булса, намуслы карак булган, ди. Ә менә Василий Уткинның үз фикере:

– Ә ул чорда байлар булмаган да, – ди ул. – Атлы кеше инде хәлле саналган. Имана җирен үзе эшкәрткән. Атсыз калу крестьян өчен бөлгенлеккә төшү белән бер булган. Ул аннары үзе дә кешегә ялланып эшләргә мәҗбүр ителгән. Юк, Шәкүр карак карап тормаган: сигез балаң бармы, авыру хатыныңмы... Шулай булгач, XX йөз башында яшәгән әлеге данлыклы



Бүгенге көнгә кадәр авылда, Шәкүрнең төп нигезендә, зур булмаган йорт тора.

Фото: Александр Ефремов

Авыл тарихын өйрәнүче Василий Уткин.

каракны берничек тә уңай герой дип әйтеп булмый...

Чүтиләләр бүген дә Шәкүр каракны кулга алу вакыйгасын искә алып сөйли. 1925 ел була ул. Мәскәүдән әлеге максат белән махсус төркем килә. Шәкүр каракны, аның ике улын, тагын 13 ярдәмчесен кулга алалар.

– Әни еш искә алып сөйли иде, – диде Чүтидә яшәүче Тәскирә апа. – Банда башлыкларын Мәскәүгә алып киткәч, авылга берничә «шәкүрче» килә. Алар ике йортка урнаша. Халык бу турыда белеп алып, тәртип сакчыларына хәбәр итә. Качаклар, үзләрен кулга алырга килүләрен белгәч, тәрәзәдән ут ача. Авылның өч ир-аты да очраклы рәвештә шунда туры килеп һәлак була. Качаклар барыбер тотсырмый, чыгып ычкына. Шуннан соң «шәкүрчеләр» авылны башка борчымый.

Чүти авылының данын Шәкүр карактан кала тагын бер кеше дә таныта. Бу очракта инде негатив яктан түгел, ә, киресенчә, яхшы итеп. Ул – XX йөз башының беренче яртысында иҗат иткән татар шагыйре, язучы, публицист, журналист Зариф Бәшири. Чүтиләләр әлеге авылдашлары турында бик горурланып сөйләде.

ТАМЫРЛАРЫ – ЧУВАШИЯДӘН

Биредә мишәрләр яши. Дөрес, аларның сөйләм теле чистайлылар, чүпрәлеләрнекеннән аерыла. Кайбыч районындагы бердәнбер мишәр авылы булгангамы, сөйләмнәре күбрәк татарларга тартым. Авылның тарихына килгәндә, аның оешуын күрсәтүче төгәл дата билгеле түгел. XVI гасырда оешкан булырга тиеш, дип фаразлыйлар.

– Һәрхәлдә, тарихи фактлар шуны күрсәтә, – диде Василий Уткин. – Архив документларыннан күренгәнчә, XVI гасыр урталарында, Чувашиянең Сундырь авылыннан (хәзерге Мари-Посад шәһәре) 11 гаилә якындагы буш җирләргә чыгып китә. Шуларның өчесе Чүтигә килеп утырган булырга тиеш. Чувашия милли музеенда саклана торган энциклопедия бар. Анда борынгы чуваш авыллары турында күп мәгълүмат теркәлгән. (Чүти Чувашия белән чиктәш дип язган идек югарыда – авт.) Анда мишәр авыллары да байтак. Чүтидә мишәрләр яшәве дә менә шуның белән аңлатыла.

Василий Уткин Чүтидә аерым кешеләр христиан динендә булган дип саный. НКВД архивында сакланган документларның күчермәсен алган ул. Шунда дистәләгән кешенең фамилиясе янына «Принял христианство» дип язылган.

– Тик бу ул кешеләр ислам диненнән ваз кичкән дигән сүз түгел, – ди Василий Уткин. – Христиан динен кабул иткән кешеләргә имана җире бирелгән, алар салымнардан азат ителгәннәр. Шуңа кызыгып, халык үз теләге белән чукынган. Тик, атакай китү белән, янә намазына баскан. Моны бабайлар да шулай дип сөйли. Һәм документлар да раслап тора. «Чүти халкы христиан динен тотмый, күз буяу өчен генә чукынган булдылар», – дигән шикаятьләр күп була. Тик илдә сәясәт үзгәрә, күпмедер вакыттан халык, курыкмыйча, янә үзенең мөселман диненә күчә.

Ни өчен бу җирләрдә алдарак, мисал өчен XIV–XV гасырларда кеше яшәмәгән соң? Сәбәбен Василий әфәнде гади генә итеп аңлатты:

– Монда яшәү куркыныч булганга. Мәскәү юлына якын җир бит. Димәк, тынгысыз урын. Юлбасарлардан, ягъни начар ниятле кешеләрдән куркып, кешеләр биредә төпләнеп утырмаган. Ә географик яктан караганда, Чүти – яшәр өчен уңайлы, әйбәт урын.

Зариф Шәрәфетдин улы Бәшири – XX гасырның I яртысында иҗат иткән татар шагыйре, язучысы, публицисты, журналисты, тәрҗемәчесе.

Ул 1888 елның 5 маенда хәзерге Кайбыч районы Чүти авылында туа.

Зариф Бәшири – беренчеләрдән булып татар халкын күрше милләт халыклары мәдәнияте белән таныштыра башлаган кеше. Чүтинең тирә-ягында чуваш авыллары булганга, аңа чувашлар белән еш аралашырга туры килә. Зариф Бәширинең күрше халык әдәбиятын өйрәнүдә «Чуваш әдәбияты» дип исемләнгән беренче җыентыгы 1928 елда Казанда басылып чыга. Җыентыкта чуваш язма әдәбияты тарихы турында кыска очерк урын алган, чуваш әдипләренең шигырьләре һәм хикәяләре татар телендә бирелгән. Ул татар җәмәгатьчелеген беренчеләрдән булып К. Иванов иҗаты белән таныштыра.

Аннан соң ул Урта Азиягә китә, анда җирле вакытлы матбугатта да берникадәр эшләп ала. 1931 елда Бәширинең «Уйгыр әдәбияты» дип исемләнгән җыентыгы дөнья күрә. 1930–1931 елларда Сталино (Донецк) шәһәрендә «Пролетар» газетасының әдәби бүлеген җитәкли.

1933 елдан Бәшири Уфада яши. 1938 елның 29 апрелендә кулга алына һәм, биш елга хезмәт белән төзәтү лагерена җибәрәләр. Срогын тутырып чыккач та, ул матбугатка якын китерелми. Партиянең XX съездыннан соң тулысынча реабилитацияләнә.

«Чуваш кызы Әнисә» повестен яза. Повесть С. Рәмиев киңәше буенча языла һәм 1910 елда басылып чыга. Соңрак укучыларның сораулары буенча тулыландырыла. Чуваш кызы белән татар егетенең көчле һәм фаҗигале мәхәббәтен романтика катыш реалистик буяулар белән сурәтләнә. Әсәрдә чувашларның гореф-гадәтләрен, көнкүреш тормышларын, татар һәм чуваш халыклары арасында үзара җылы мөнәсәбәтләрен күрсәтә. 1960 елда чуваш теленә тәрҗемә ителә.

Зариф Бәшири этнографик очерклар авторы да. Аның «Чувашлар» дип аталган хезмәте – XX йөз башы татар мәдәниятендә уникаль күренеш. Әдип чувашларның телләрен, гореф-гадәтләрен өйрәнә, борынгы ышануларын, әйтемнәрен барлый. Ул шулай ук үзбәк, уйгыр әдәбияты, тарихы белән таныштыра, шигырьләрен, хикәяләрен татарчага тәрҗемә итә, төрки халыклар әдәбияты тарихын өйрәнүгә зур өлеш кертә.

«КҮҢЕЛ ХАКЫ ӨЧЕН ЭШЛИМ»

Чүтидә бүген 645 кеше яши, 200 хуҗалык бар. Авылда урта мәктәп, мәдәният йорты, фельдшер-акушерлык пункты эшли. Кыскасы, авыл аягында нык басып тора. Биредәге төп үзенчәлек – халык күпләп хайван асрый. 200 хуҗалыкның 91е ШЯХ программалары буенча дәүләттән субсидия алган. Арада мини-ферма булып эшләүчеләре дә байтак. Без Нас-

PRESSA.RU

Лилия белән Дамир Насретдиновлар гаиләсендә эш һәркемгә дә җитә.

ретдиновлар гаиләсенә кереп чыгарга булдык. Аларның ике катлы йортларын, каралты-кураларын күргәч, башта монда берәр фермер, эшмәкәр яшидер, дип уйлаган идек. Юк, гап-гади кешеләр икән. Хәләл көчләре белән биш-алты ел элек йорт җиткергәннәр, ике ел элек каралты салганнар.

– Шабашкага йөрдем, Мәскәүгә кадәр барып эшләдем, – дип сөйләде Дамир Насретдинов. – Җәй буе кайтып кергән юк иде. Балалар үскәнен дә күрми калам, дип, читкә йөрмәскә булдым. Авылда әллә ни эш тә юк бит. Уйлаштык та маллар үрчетә башладык.

Насретдиновлар хуҗалыгында ундүрт баш сыер бар. Әмма фермер булып теркәлмәгәннәр, кәгазь эшеннән куркалар икән.

– Болай ичмаса ай саен хисап тотасы юк, – дип тә өстәделәр.

Лилия белән Дамир Насретдиновларны яшь гаилә дип әйтеп була, хатынга 34 яшь, ире чак кына олырак. Өч кыз үстерәләр. Олы кызлары Чүти урта мәктәбенең 7 нче сыйныфында укый, кечесенә әле яшь ярым гына. Тагын бер бала алып кайту ниятләре дә бар икән:

– Малай, нәсел дәвамчысы кирәк безгә, – ди ата кеше.

Хәләл көч белән биш-алты ел элек йорт җиткергәннәр.

Насретдиновлар хуҗалыгында ундүрт баш сыер бар.

Ир белән хатынның гадилеге гаҗәпләндерде. Таң белән дүрттә торып, көне буе аякта булсалар да, зарланмыйлар. Сөтнең литрын 12 сумнан саталар. (Югыйсә кышын гына әле 15 сум иде аның бәясе.)

– Сыер асрауның файдасы бармы соң, болай булгач? – дип сорамый булдыра алмадым.

– Бер тиен файдасы да юк...

– Соң алайса ник асрыйсыз?

– Күңел хакы бар бит. Малларга ияләнәсең, алар гаилә әгъзасына әйләнә, дисәң дә була. Аның файдасы турында уйлап утырмыйсың инде шуннан соң. Сыерның бозавы була, төп файдасы шул. Кыш буе ит саттык. Акмаса да, тама...

Насретдиновлар малларга азыкны сатып алмый, үзләре әзерли. Берничә ел элек колхоздан шәхси пай җирләре алганнар. Дамирның

тракторы бар. Шуның белән язын җир эшкәртә, чәчә, җыя дигәндәй.

– Ирем җәй көне кырдан кайтып та керми, – ди Лилия. – Печәнне вакытында җыеп, тюклап алып кайтырга кирәк. Иртән сыерларны машина белән савам да көтүгә куам. Тик тормыйбыз инде…

Бу гаиләдә кызларга да эш җитә. Узган ел, унар көн рәттән, әтиләре белән көтү көткәннәр. (Чүтидә көтү чиратлап икән.) Мәктәптән кайткач, хәзер дә кызлар әтиләренә булышырга чыга. Күршедә генә Дамирның 78 яшьлек әнисе – Сәлимә апа яши, балаларга күз-колак булып ул тора икән.

Насретдиновлар – матур гаилә. Тырышлыклары турында әйтеп тә торасы түгел: май чүлмәге тышыннан күренә. Авыл кешеләренә хас булганча, якты бер нур бөркелә алардан.

«ӘТИ ДӘ, ӘНИ ДӘ БУЛДЫ...»

Чүтидә кызык фамилияле берәү – Касыйм Козлов белән таныштык. Бабай бүгенге көндә Чүти авылындагы бердәнбер исән сугыш ветераны. 93 яшьне тутырган. Дистәләгән медальләре арасында II дәрәҗә Дан ордены да бар. Касыйм бабайның яшенә карата зиһене бик яхшы, сәламәтлеге дә әйбәт. Дөрес, алты ел элек сул аягын кисканнәр.

– Сугыш ярасымы әллә? – дигән идем, юк икән, аягы бәрелеп, җәрәхәтләнгән булган. Төзәлми интектергән. Кызганыч, саклап кала алмаганнар…

Касыйм бабай сугышка 1943 елны алына. Украина фронтына җибәрәләр. Шунда контузия алып, озак кына хәрби госпитальдә ята. Аннан яшь солдатны Эстония чикләрен сакларга озаталар. Җиңү көнен ул Германия җирендә каршылый. Шул вакытларны аерым бер горурлык белән искә алып сөйли:

– 1945 елның маенда немец авылларында йөрдек. Безнең солдатларны күрүгә, җирле халык ике кулын күтәрә иде, янәсе, биреләләр. Ә безгә нәрсә, ашапэчәбез дә китәбез. Идән асларында нинди генә ризык юк: төрле консервалар, тәм-томнар. Безнең, ач солдатларның, мондый әйберне ашаган түгел, күргән дә юк! Совет солдатларының намусы чиста: бер генә немец картына, хатын-кызына, бала-чагасына тимәдек, – дип дәвам итә сүзен Касыйм бабай. – Ә алар безнекеләрне изде! Немецлар безгә

Чүти авылындагы бердәнбер исән сугыш ветераны – Касыйм Зиннәт улы Козлов.

карата бик усал, рәхимсез булды. Моны бүген күпләр онытты гына…

Касыйм бабай туган авылына 1950 елда гына әйләнеп кайта. Польша елгалары аша күперләр салуда катнаша ул.

Касыйм бабай сугыштан кайткач, ун елдан соң гына – 34 яшендә өйләнә. Башта әле аякка басарга, ял итәргә, көч тупларга уйлый. Тормыш корып җибәргәч, бер-бер артлы ике кызлары – Фәридә белән Рамилә туа. Тик сугыш кичкән иргә балаларын тигезлектә үстерергә насыйп булмый – җиде ел гомер иткәннән соң, хатыны үлеп китә. Касыйм бабай башка өйләнми. Кызлары дип яши.

– Әти безгә әни урынына да булды, – дип сөйләде кызы Фәридә апа. – Мин әнидән алты яшемдә калганмын, сеңлемә бары өч кенә тулган булган. Өйдәге бөтен эшкә безне әти өйрәтте. Беребез мич якса, икенчебез ашарга пешерде, эш бүленгән иде. Әти кырык ел колхозда механизатор булып эшләде. «Хатыны юк, шуңа пычрак йөри», – дип әйтмәсеннәр дип, әтинең киемнәрен кайнатып юа идек. Әти без дип яшәде. «Укып кеше бул», – дип, мине Казанга – КДПИга җибәрде. Биш ел физика факультетында белем алдым. Кулга диплом алгач, Чүти урта мәктәбенә эшкә кайттым. Лаеклы ялга чыкканчы, мәктәптә физика укыттым. Әти минем бу һөнәрне сайлавыма бик сөенде. Кыяфәтем буенча мин – аңа, ә сеңлем Рамилә исә әнигә ошаган. Ул гаиләсе белән Чебоксар шәһәрендә яши.

Фәридә апа студент елларында гына әтисе белән аерылып торган, калган гомере – гел аның янәшәсендә. Төп нигезләренә терәтеп дигәндәй, ире белән яңа йорт салганнар. Иртән биштә кереп, күршедә яшәүче әтисенә кайнар чәй куя, ризык хәстәрли. Ә кичен, сәгать унда, бабайның ишеген бикләп чыгып китә икән.

– Мин 36 яшемдә генә кияүгә чыктым, – ди Фәридә апа. – Аллага шөкер, бала табарга да өлгердем. Кызыбыз бар, Казанда югары уку йортында белем ала. Сугыш ветераннарына торак алу өчен бирелгән акчага Казаннан бер бүлмәле фатир алдык, кызыбыз шунда яши. Бу да әти ярдәме. Исән генә булсын! «Үзең өчен яшәдең, хәзер әнинең гомере өчен яшәргә тиешсең», – дим мин аңа. Аннан башка тормышымны күз алдына да китерә алмыйм. Әтисез калудан бик куркам, гәрчә моның котылгысыз әйбер икәнен аңласам да…

Козлов фамилиясенә килгәндә, ул кушаматтан ясалган икән.

– Безнең фамилия Гыйниятуллин булган, – диде Касыйм бабай. – Ә кушаматыбыз кәҗә булган. Руслар «Козлов» дип атап, шуннан ул фамилиягә әйләнгән. Безнең авылда андый кешеләр бар ул, берәүләр, әнә, үрдәк кушаматыннан Уткиннар булып киткән.

…Чүтидә умарта асраучылар күп икән. Кояш җылысына бал кортлары уянган иде: гөжелдәп очалар. Чүтиләрне мин әлеге кортларга охшаттым: шундый ук тырыш, тиктормаслар. Кирәк булса, чагып алырга да күп сорамыйлар.

Без Татарстан риваятьләрен җыюыбызны дәвам итәбез, ә алар безнең якларда бик күпләп «яши». Бүгенге риваять Тәтеш районыннан.

ТАТАРСТАН РИВАЯТЬЛӘРЕ:
ҖИР ҮЛЧӘҮЧЕНЕҢ КҮПТӘНГЕ ҮПКӘСЕ

Дөньяда гаҗәеп исемле авыллар бик күп, әмма нинди дә булса Иске Козявкино яисә хәтта Лысая Балда авылын да безнең Пролей-Каша белән чагыштырып буламы соң! Эш бу атаманы килешләр белән төрләндереп булмауда гына да түгел, ә бәлки Пролей-Каша авылындагы һәр кешенең сезгә риваять сөйләвендә – бер уйласаң, шул ук нәрсә турында кебек, әмма һәркайсы шул дәрәҗәдә үзенчә сөйли ки – риваять берәү генә түгел, әллә ничәү шикелле тоела башлый.

Бер версия буенча бу авыл 1611 елда, Зөя өязеннән берничә чувашның, бирегә килеп чыгып, мондагы «ялан кыр»ны ошатуы сәбәпле барлыкка килә. Алар бу урында төпләнеп тә калганнар. Авылның ул чакта исеме булмый әле. «Ә менә Иделдә сугышлар барганда, – дип сөйли тәрәзә йөзлекләре зәңгәргә буялган матур агач йортта яшәүче Шура әби Полянина, – бирегә әллә чехлар, әллә монахлар килеп тукталган… Кемнәр икәнен хәтерләмим инде. Алар нәкъ менә шушы урында учак ягып, ботка пешерергә тотынганнар гына – өсләренә дошман килеп чыккан! Көтелмәгән хәлдән ботканы түгеп җибәргәннәр!»

Пенсиядәге химия һәм биология укытучысы Таисия Васильевна Баклушина сөйләвендә риваять мондыйрак төсмер ала: «Безнең Пролей-Каша – илдә берәү генә ул. Бердәнбер! Ивановка, Петровка, Сидоровка ишеләре җитәрлек, ә Пролей-Каша бүтән юк! Без үзебез ияләшкән инде, ә бөтенесе көлә! Ничектер шулай Әрмәнстанда ял иткән идем, курортта. Почтадан, әйбәт килеп җитүемне әйтеп, өйгә телеграмма сугарга булдым. Адресны әйткәч, әрмәннәр бөтен почтамтны яңгыратып кычкырып көлде. Нәрсә анда әрмәннәр! Казанда да бөтенесе көлә. Ә кем аркасында? Барысына да ниндидер җир үлчәүче сәбәпче, имеш, ул биредә җир бүлеп йөргән, тик аны соңыннан ботка белән сыйламаганнар, чөнки түккән булганнар ботканы… Үпкәләгән җир үлчәүче, шуңа да авылга Пролей-Каша дип исем биргән».

Мәктәпнең туган якны өйрәнү музеендагы ак кәгазьгә бастырып алынган риваять мондый рәвештә саклана: «…Авыл юлбасарлардан яшеренгән качаклар тарафыннан оештырылган. Идел ярларына урнашкан авылларына тынгылык бирмәгән юлбасарлардан алар шулай эчкәрәк, урманга таба кача торган булганнар. Бара торгач, карыннары ачкан. Учак ягып, ботка пешерергә керешкәннәр. Һәм кинәт каяндыр юлбасарлар килеп чыккан! Качаклар тауга таба йөгергәннәр һәм ашыгычлык белән боткалары да түгелгән. Менә шул ботка хөрмәтенә…»

Бу тарихны дәүләт архивыннан Санкт-Петербург рәссамы Борис Кириллович Яфаркин эзләп тапкан, диләр, тумышы белән – Пролей-Каша авылыннан ул да.

PRESSA.RU

ТАССРның 100 еллыгына

багышланган уникаль открыткалар коллекциясен җый

Алабуга. 2017 ел.

Фото: Ната Смирнова

ТАССР 100 лет ел

PRESSA.RU

ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА БАГЫШЛАНГАН УНИКАЛЬ ОТКРЫТКАЛАР КОЛЛЕКЦИЯСЕН ҖЫЙ

Алабуга. 1952 ел.

Фото «Татарстан» журналы архивыннан